Безнен МИРАС

НАШЕ НАСЛЕДИЕ

9

сентябрь 2021

ISSN:2500-011X

КЫЗЫКЛЫ ТАБЫШЛАР ● КАДЕРЛЕ ИСТӘЛЕКЛӘР ● ГЫЙБРӘТЛЕ ЯЗМЫШЛАР

«Сары умырзая эзләдем»
50 бит

Мин сездән, авылдашлар...
55 бит

ИЛДАР ЮЗЕЕВ

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Дәрдемәнд

Безнең МИРАС
12 +

9
(333)
сентябрь 2021

Фәнни-популяр, әдәби-нәфис
һәм документаль журнал

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ (Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-92)

Баш мөхәррир урынбасары
Фирдәвес Зарифуллин (Фирдәвес Зариф)
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә

Ирада Әюпова
(ТРның мәдәният министры)
Айрат Зарипов
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Айдар Сәлимгәрәев
(«Татмедиа» Республика Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе)
Васил Шәйхразиев
(ТР премьер-министры урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)

Редколлегия

Альберт Борһанов
Разил Вәлиев
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ильяс Җиһаншин
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Хатыйп Миңнегулов
Ким Миңнуллин
Рүзәл Мөхәммәтшин
Григорий Родионов (Гәрәй Рәхим)
Данил Салихов
Индус Таһиров
Данис Шакиров
Илдар Шәфыйков

Җаваплы мөхәррир
Ленар Гобәйдуллин
89196911406

Дизайнер һәм биткә салучы
Алмаз Фәйзуллин
(843) 222-09-83 (17-92)

Мөхәррир
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-91)

Сайт мөхәррире һәм корректор
Энже Хөсәенова
(843) 222-09-83 (17-93)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта: **yanamiras@mail.ru**
Сайт: **beznenmiras.ru**

«Безнең мирас» (Наше наследие)
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал
(на татарском и русском языках)

Эчтәлек

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 Илдар Юзеев

ТАРИХИ МИРАС

4 Җүчи ханның шәҗәрәсе
9 «Бу бик ышанычлы кеше...» *Г.Ханнанова*
14 «Япон дигән патшага плин булдык...» *Р.Мәрданов*
20 Нарва ислам җәмгыяте. *И.Мифтахов*
29 Коточкыч ачлык. *Н.Гариф*
32 «Күңелемне тартып калды». *М.Фәйзи*
40 Шәҗәрәбез тарихы. *Ә.Маликов*

ТАТАР ГАМЕ

46 «Әтрәч укулары»нда Туфан Миңнуллинны искә алдылар
50 «Сары умырзая эзләдем». *М.Вәлиев*
55 Мин сездән, авылдашлар... *И.Юзеев*

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны һәм фотоларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми.
Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм «Татар-информ»нан, Татарстан Милли музееннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан, җиде томлык «Татар тарихы»ннан алынган фотосурәтләр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

59 Чүпрәледә – «Мунчәли укулары»
63 Акыл – мидәге сырлар... *Ф.Нәфиев*
64 Хәкимов. *И.Таһиров*
71 «Безнең мирас» котлый!
72 Калининградка сәфәр. *Л.Лерон*

ДИНИ МИРАС

83 Ислам дөньясы. *Габдерәшит Ибраһимов*
89 Исмәгыйль хәзрәт Сәлимшин нәсыйхәтләре
92 Дин дәресләре. *С.Бикбулат*

ХӘТЕР САНДЫГЫ

94 Гамьле затлар онытылмый. *Т.Галиуллин*
98 Нәсел. *Л.Закиров*
100 Кара тәкъдир. *Р.Батулла*
102 Истә, һаман да истә!

СӘНГАТИ МИРАС

104 Арчада «Җыр бәйрәме». *К.Филиппова*
108 Татар җырчылары. Кадерле мизгелләр. *З.Гыйльметдинова*
110 «Көзге ачы җилләрдә» җыры

ШАЯН МИРАС

112 Көлке куа килә...

БАЛАЧАК МИРАСЫ

114 Без барыбыз да – балачактан

116 «Безнең мирас» хәбәрләре
118 Мирасворд
119 «Безнең мирас» елъязмасы. Сентябрь

Заказ №Е-2961. Тираж – 2690 данә. Формат 70x100 1/16
Басарга кул куелды: 31.08.2021. Чыгу көне: 03.09.2021.
Айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Тышлыкның беренче битендә:
Илдар Юзеев – Ямады мәктәбе укучысы. 1947 ел

Җиргә яңа туган сабый мин
Һәм сугышта үлгән абый мин.

Илдар Юзеев

Илдар Юзеев әнисе Шәкүрә белән. 1961 ел

Безнен мирас №9 сентябрь 2021

ИЛДАР ЮЗЕЕВ

(3.01.1933-21.12.2004)

***

Уйлама үзеңне халык дип,
Шул халык эчендә Алып дип.
«Ул – халык эчендәге Алып», – дип
Әйтергә хаклыдыр халык тик...

***

Үз-үзеңне эзләп табыйм диеп,
Айлар-еллар үтә.
Үз-үзеңне югалтырга
Бер минут та җитә.

***

Бала-чага олы булсын,
Бала булсын олылар,
Олыны да, кечене дә
Шулчак һәркем олылар.

***

Соң булса да, белә акыл, тоя йөрәк:
Дошман юктыр иске «дус»тан
мәкерлерәк.

***

Чын шагыйрьне үз телендә уку –
мәхәббәткә, ә тәрҗемәдә уку мәхәббәт
белән шөгыльләнүгә тиң.

***

Утлар-бозлар йотып егылсаң да,
Гомер юлын узып,
Йөрәгеңне тотып егылсаң да, –
Яшәү – барыбер кызык!

***

Башта эшафотка мендерәләр,
Үзе үлгәч – шөһрәт таҗына...
Шагыйрьләрнең соңгы адымнары –
Йә батырлык, яки фаҗига.

***

Шагыйрьлекнең «чишмә башы»
кайда? Әнкәйнең бишек җырында.
Мандолинада көйләр уйнап, ул ритмны
тоярга өйрәтте. Шигырьнең башы –
ритмда. Ритм ул – шигырьнең йөрәк
тибеше. Йөрәк туктаганда да аның
ритмы шигырьләрендә кала.

Текстны журналга
***Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Безнең мирас №9 сентябрь 2021

Җүчи ханның шәҗәрәсе[1]

(Рәшит әд-Диннең елъязмасыннан кыскартылган вариант)

Җүчи хан. ***Рәссам Ч.Дорждэрэм эше***

Нугай ул – Татар улы

Җүчи хан – Дәште-кыпчак, ягъни Алтын Урда империясенә нигез салган дәүләт эшлеклесе. Ул – Чыңгыз ханның иң олы улы. Җүчи хан 73 яшьлек әтисеннән берничә генә ай алдан дөнья куя. Шунысы гыйбрәтле: кайбер галимнәр Алтын Урданы монголлар төзегән дәүләт дип расламакчы булалар. Әмма Җүчи хан шәҗәрәсендә дистәләгән уллары һәм оныклары арасында бер генә монгол исеме дә юк. Барысы да кыпчак-татар исемнәре. Җүчи ханның төрле хатыннан унсигез улы була. Аның уллары һәм оныклары арасында тарихта эз калдырган бөек ханнар, илбашлары шактый.

Сүзем нугайлар турында.

Татар кавеменең бәкләр бәге Нугай карамагындагы күчмә өлеше мал үрчетү, затлы токымлы ат табуннары тоту белән шөгыльләнә. Нугай морзаның үз гаскәре дә була. Ул Иделнең көньяк өлешен, төньяк Кавказны, Кырымның

[1] Тизенгаузен төзегән җыентыктан алынды. Кара: Золотая Орда в источниках. – Т.1. Арабские и персидские источники / сост.вводная ст. и коммент. Р.П.Храпачевского. – М., 2003. – С.410-418.

төньягын, хәзерге Молдава җирләрен биләп тора. Монда яшәүче халык үзен нугайга буйсынган яки нугай татарлары дип йөртә. «Бүлгәлә һәм хакимлек ит!» дигән кагыйдәне нигез итеп алып, рус тарихчылары нугайны татардан аерып карауны алга сөрә.

Шәҗәрәдә Җүчи ханның җиденче улы – Буал. Буалның беренче улы – Татар, аның улы – Нугай. Нугайның Җүкә, Мүкә, Туры исемле өч улы була. Җүкәне ул Балкандагы Болгар дәүләтенең тәхетенә 1283 елда утырта. (1301 елда аны үтерәләр.)

Мин шуны беләм: меңнәрчә еллык бай тарихы, әдәби мирасы, легендар шәхесләре булган бөек татар арбасыннан, мин аерым халык, дип төшеп калган нугайлар, бернигә дә ирешә алмыйча, онытылырга дучар булачак.

Марсель Галиев

Урда – [*Җүчи ханның*] беренче улы.
Бату – икенче улы.
Бәркә – өченче улы.
Бәркәчар – дүртенче улы.
Шәйбан – бишенче улы.
Таңгут – алтынчы улы.
Буал – җиденче улы.
Җылаукөн – сигезенче улы.
Шоңкар – тугызынчы улы.
Чимбай – унынчы улы.
Мөхәммәд – унберенче улы.
Удур – уникенче улы.
Тукайтимер – унөченче улы.
Синкем – ундүртенче улы.

Урданың беренче улы – Сартактай. Аның улы – Куянчы. Куянчының уллары – Баян, Бoҗыртай, Чаганбуга, Мәкүдәй.

Куянчының беренче улы – Баян. Аның дүрт улы була: Шади, Сатыбуга, Текә, Салчыкутай.

Куянчының икенче улы – Боҗыртай. Аның улы – Биратай.

Куянчының өченче улы – Чаганбуга. Аның улы – Текә.

Куянчының дүртенче улы – Мәкүдәй. Аның уллары юк. Шуның белән Урданың беренче улы Сартактайның тармагы тәмамлана.

Урданың икенче улы – Күли. Аның уллары – Тумакай, Төмән, Миңкан, Аячы, Мөселман.

Күлинең беренче улы – Тумакай. Аның уллары – Җарык, Нугай, Саталмыш, Мөбарәк, Илбуга, Туры Тимер, Күчүк.

Күлинең икенче улы – Төмән. Аның уллары – Көек, Дәнешмәнд, Куртагачы, Котлыбуга, Котлытимер, Илтимер, Яйлак.

Күлинең өченче улы – Миңкан. Аның уллары – Хәлил, Башмак, Холкыту.

Күлинең дүртенче улы – Аячы. Аның улы – Газан.

Күлинең бишенче улы – Мөселман. Аның уллары – Җәүтү, Япалет, Хуҗа, Иляс.

Урданың өченче улы – Корумыш.

Урданың дүртенче улы – Көнкырын.

Урданың бишенче улы – Нурмакай.

Урданың алтынчы улы – Котыкуй.

Урданың җиденче улы – Хулагу. Хулагуның беренче улы – Тимербуга. Аның уллары – Кобылык, Тукайтимер, Җаңкут, Сасы, Ушанан.

Җүчи ханның икенче улы – Бату.

Батуның беренче улы – Сартак.

Батуның икенче улы – Тукан. Аның уллары – Тарбу, Мәңгүтимер, Тудымәңгү, Тактынугай, Үгәче.

Тарбуның уллары – Тулабуга, Күнчек, Йөзбуга.

Мәңгүтимернең уллары – Алкуй, Абачы, Тудыкан, Бүрекүк, Токтай, Сарайбуга, Хөләкәй, Кадан, Кудыкан, Тугрылчы. Тугрылчының улы – Үзбәк.

Тудымәңгүнең уллары – Үрменгү, Чичектү, Түбтай.

Тактынугайның уллары – Бабуҗ, Түгелбуга.

Туканның бишенче улы Үгәченең балалары юк.

Батуның өченче улы – Абукан. Абуканның уллары – Борак, Бүләр, Тотыҗ, Дагдага, Әхмәд, Сабир, Дүңгүр.

Батуның дүртенче улы – Улакчы.

Җүчи ханның өченче улы – Бәркә.

Җүчи ханның дүртенче улы – Бәркәчар.

Бәркәчарның уллары – Күкҗу, Йисубуга.

Күкҗуның уллары – Иҗилтимер, Балыкчы, Туктай, Туктимер.

Йисубуганың улы – Сарайбуга.

Бәркәчарның тармагы шунда өзелә.

Җүчи ханның бишенче улы – Шәйбан.

Шәйбанның уллары – Байнал, Баһадур, Кадак, Балакан, Черик, Меркан, Көртекәй, Аячы, Саилкан, Баянҗар, Маҗар, Көниче.

Шәйбанның беренче улы – Байнал. Аның уллары – Елактимер, Биктимер, Бишбуга.

Шәйбанның икенче улы – Баһадур. Аның уллары – Котлыбуга, Җүчибуга. Җүчибуганың уллары – Батакүл, Биктимер, Баянкеҗар, Йисубуга.

Шәйбанның өченче улы – Кадак. Кадакның бер улы – Тулабуга. Тулабуганың уллары – Моңкотәй, Төмәнтимер. Аның улы – Үҗүкан.

Шәйбанның дүртенче улы – Балакан. Аның уллары – Туры, Тукан, Токтай. Аның өч улы – Бакырчы, Күнчек, Үҗукан.

Шәйбанның бишенче улы – Черик. Аның бер улы – Туктимер.

Шәйбанның алтынчы улы – Меркан. Аның уллары – Тукайтимер, Илбуга.

Шәйбанның җиденче улы – Күрдекәй. Аның бер улы – Киңәш.

Шәйбанның сигезенче улы – Аячы. Аның бер улы – Учкартукай.

Шәйбанның тугызынчы улы – Сабилкан. Аның улы – Котлыгтимер. Аның җиде улы – Борылтай, Биктимер, Буралыги, Отман, Сабтак, Йисубуга, Тимертай.

Шәйбанның унынчы улы – Баянҗар. Аның бердәнбер улы – Әбүгантуркан. Аның улы – Туганчар.

Шәйбанның унберенче улы – Маҗар. Аның улы – Турчы.

Шәйбанның уникенче улы – Көничи.

Нәсел тармагы шушында өзелә.

Җүчи ханның алтынчы улы – Таңгут.

Таңгутның ике улы була – Сүбектай, Тугыз.

Сүбектайның беренче улы – Маҗар. Аның улы – Күрек. Икенче улы – Күнчек. Аның уллары – Бүречар, Көчтимер, Иштан, Турату.

Тугызның уллары – Калымтай, Арыслан, Буралыги.

Җүчи ханның җиденче улы – Буал.

Буалның беренче улы – Татар. Аның улы – Нугай. Нугайның уллары – Җүкә, Мүкә, Туры.

Буалның икенче улы – Миңкадәр. Аның уллары – Нүкәр, Бикдус, Әбукан, Сасык, Урус, Уруңкүртүкай, Туклуҗа, Илбасмыш.

Җүчи ханның сигезенче улы – Җылаукөн.

Җүчи ханның тугызынчы улы – Шоңкар.

Шоңкарның беренче улы – Йисубуга. Аның биш улы була: Буралычи, Кобылук, Тудыкан, Тудаҗу, Актаҗи.

Шоңкарның икенче улы – Ширамук. Аның уллары – Хәрәзми, Җакутуй, Бәйрәм.

Шоңкарның өченче улы – Маҗар. Аның өч улы була – Урусак, Бая, Байку.

Җүчи ханның унынчы улы – Чимбай.

Чимбайның беренче улы – Һинду. Һиндуның улы – Яку. Якуның уллары – Җалаиртай, Кундалан, Мангутай, Танаҗу.

Чимбайның икенче улы – Тудавыр. Аның уллары – Маҗар, Тарияҗи. Маҗарның уллары – Мәлик, Хуҗа, Кортыкачу.

Җүчи ханның унберенче улы – Мөхәммәд (аны Бүре дип тә атыйлар).

Җүчи ханның уникенче улы – Удур. Аның улы – Карачар. Карачарның уллары – Күрдекай, Түрче, Әбишкәй, Әмкен, Тәүәкәл.

Җүчи ханның унөченче улы – Тукайтимер.

Тукайтимернең беренче улы – Байтимер. Аның уллары – Туганчар, Билгечи, Күкәҗу.

Икенче улы – Баян. Аның уллары – Казан, Дәнешмәнд.

Өченче улы – Урынык. Аның дүрт улы була. Беренчесе – Ачык. Аның улы – Бәхтияр. Икенче улы – Арыклы. Арыклының уллары – Гадел, Сакриҗи, Анбарҗи. Өченче улы – Каракыр. Аның уллары – Никбай, Керәнче, Шабакуй. Дүртенче улы – Сарыча. Аның бердәнбер улы – Күнчек.

Тукай Тимернең дүртенче улы – Көнтимер. Аның уллары – Карахуҗа, Абай.

Җүчи ханның ундүртенче улы – Синкем. Аның уллары юк.

«Могыйз әл-әнсаб фи шәҗәрәт саләтыйн Могул» язмасыннан кайбер өстәмәләр[2]

«Могыйз...»дә Җүчи ханның сигез хатыны хакында әйтеп үтелә: Никтумыш фуҗин – Оң ханның туганы Җәкемби кызы; Саркыды хатын, коңгырат ыруыннан, бу инде Җүчи ханның иң өлкән хатыны, Урданың әнисе; Солтан хатын (ыруы билгесез), Бәркә, Бәркәчар, Бүренең әнисе; Котлуг хатын баргут ыруыннан, Чимбайның әнисе; Куйки (?) хатын кирәй ыруыннан, Таңгутның әнисе; Үкәй фуҗин – Анчы нойон кызы, Батуның әнисе; Нәсер (?) – Шәйбан, Чилауанның әнисе; Фарис (?) – Синкем белән Шоңкарның әнисе.

Җүчи ханның бик күп хатыннары арасыннан игътибарга алырлыклары шушылар. Бихисап кәнизәкләре арасыннан Буалның әнкәсе Карачин хатын, Тукайтимернең әнкәсе – меркит ыруыннан Кәһри хатынны әйтеп китәргә була.

Монда Җүчи ханның унсигез улы күрсәтелә. Рәшидеддин санап үткәннәренә тагын дүртәү өстәлә: Әсән, Бүре, Кугачы, Куадур.

«Могыйз...»дә: «Токтай хан 712 (1311/1312) елда Идел уртасында корабта җан бирде, тәхеткә Үзбәк хан утырды», – диелә.

Алтын Урданың бөек хакиме Үзбәк ханның нәсел тармагын карап китик: Җүчи – Бату – Тукан – Мәңгүтимер – Тугрылчы – Үзбәк.

Үзбәкнең уллары – Тулынбәк, Иринбәк, Тугрыбәк, Ширинбәк, Тимербәк, Җанибәк.

Тулынбәкнең уллары – Танибәк, Тубута, Хызырбәк.

Иринбәкнең уллары – Корычбәк, Килдебәк, Уручык, Татибәк, Дәүләтбәк, Иринбәк, Татлыбәк, Шаһбай, Батибәк.

Тарихта тирән эз калдырган Туктамыш ханның да нәсел җебен «Могыйз...»дән табарга була (Җүчи – Тукайтимер – Урнык – Сарычы – Котлык хаҗи – Туйхуҗа – Туктамыш).

Туктамышның унөч баласы була: Бәйрәмбәк ханша, Кадербирде, Искәндәр, Күчүк, Әбусәид, Җаббарбирде, Кепекхан, Кәримбирде, Җәләледдин, Бәхтебәк хуҗа, Сәидбәк хуҗа, Җаникә ханша, Мәликә ханша.

Урус ханның шәҗәрәсе өч тармакка бүленә. Уллары – Токтакия, Тимер Малик, Коерчак.

Токтакиянең уллары – Бахшиби, Сәүди, Татлы, Уникепулад, Бугучак, Тәңребирде.

Бугучакның дүрт баласы күрсәтелә: Мөхәммәд, Әхмәт, Алия, Имәнбия.

Тимермәликнең уллары – Сәидгали, Сәидәхмәт, Токтапулад, Туглыкпулад, Шүкүр, Туглубай, Ирәнбай, Сүбәдәй, Мәңликтуркан, Огланбай, Миңлебай, Котлыбуга.

Коерчакның балалары: Борак хан, Рокыя, Пәенде солтан. ■

---

[2] Кара: Золотая Орда в источниках. – Т.1. Арабские и персидские источники / сост.вводная ст. и коммент. Р.П. Храпачевского. – М., 2003. – С.437-442.

«Бу бик ышанычлы кеше...»

(Сәет Вахиди Баллыкүл авылы турында)

Гөлчирә Ханнанова

Сәет Вахиди

20 нче йөз башы татар дөньясының күренекле шәхесләре, татарның беренче профессиональ галимнәре Җ.Вәлиди, М.Корбангалиев, Г.Гобәйдуллин, Г.Рәхимнәр арасында тарихчы, археограф Сәет Габделмәннан улы Вахидовның (Сәет Вахиди, 1887-1938) да лаеклы урыны бар. С.Вахиди – татар халкы тарихына караган чыганакларны максатчан рәвештә эзләү, барлау һәм саклау өлкәсендә гаять зур, киңкырлы эшчәнлек алып барган галим. Ул – дистә елларга сузылган күпсанлы археографик эзләнүләр алып баручы, Болгар дәүләте, Казан ханлыгы тарихына, кулъязма һәм ташъязма мирасны өйрәнүгә караган күпсанлы мәкаләләр авторы.

Сәет Габделмәннан улы Вахиди (Вахидов) Казан губернасының Спас өязендәге Ташбилге авылында, урта хәлле крестьян гаиләсендә дөньяга килә. Башта туган авылы Ташбилгедә, соңрак күрше Иске Рәҗәп авылы мәдрәсәсендә, 1905-1911 нче елларда Казанның «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә белем ала. 1911 елдан Казан губернасы мәктәпләрендә мөгаллимлек итә. 1918-1920 нче елларда укытучылар хәзерли торган педагогик курслар оештыру эшендә катнаша, 1921 нче елларда Казан дәүләт университетының рабфагында татар теле укыта.

С.Вахиди 1925 елда ТАССР Үзәк музее каршында Көнчыгыш кулъязмалары бүлеген оештыру эшенә дә күп көч куя һәм 1926 елның 1 ноябреннән 1930 елның 1 сентябренә кадәр биредә бүлек мөдире вазыйфаларын башкара. Музейда эшли башлаганчы ук, 1911 нче еллардан башлап, С.Вахиди, халык арасында йөреп, тарихи чыганаклар, археология, этнография һәм фольклорга караган материаллар туплау эше белән шөгыльләнә. Әлеге эшчәнлек казанышларының берсе – 1912 елда табылган Сәхибгәрәй хан ярлыгы.

Нәкъ шушы вакытта, гади халык кулында саклана торган тарихи язмаларны, халык авыз иҗаты үрнәкләрен, татар мәдәниятенә караган башка мәгълүматны нәтиҗәлерәк ачыклау, тизрәк җыю һәм бер урынга туплау максаты белән, С.Вахиди тарафыннан махсус анкета төзелә[1]. Анкета Татарстанның Үзәк музее исеменнән төрле төбәк башкарма комитеты рәисләренә, комсомол һәм партия оешмаларына, мәгариф хезмәткәрләренә, укытучыларга, гомумән, үз мәдәниятенә битараф булмаган шәхесләргә юллана, татарлар яшәгән төрле төбәкләргә таратыла. Нәтиҗәдә, сакланып калган язма һәм матди мирасны җыйнау һәм туплау өлкәсендә җанлану күзәтелә һәм үзенең нәтиҗәләрен дә бирә. С.Вахидигә төрле төбәкләрдән хатлар килә башлый. Алар арасында Троицк өлкәсеннән юлланган Исмәгыйль Рәхмәтуллин (1891-?), Бөгелмә якларыннан килгән Ф.Туйкин хатлары һ.б. бар. Әлеге хатларда күрсәтелгән мәгълүматларга таянып, С.Вахиди максатчан командировкалар, экспедицияләр оештырып шактый бай материал туплауга ирешә. Мәсәлән, С.Вахиди төрле елларда Казан губернасының Мамадыш, Спас, Лаеш һәм Минзәлә кантоннары авылларында татар халкы тарихына караган язма һәм матди чыганакларны эзләү, туплау һәм өйрәнү эшен алып бара. Әлеге эшчәнлек нәтиҗәсендә борынгы кулъязма һәм басма мирасыбызның зур бер өлеше юкка чыгудан сакланып кала. Җыйналган әлеге байлыкның шактый өлеше ТР ФАнең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә, Сәет Вахиди (1887-1938) фондында саклана. Биредә XVII-XX гасырларга караган кыйммәтле чыганаклар бар. Алар арасында: гарәп, фарсы, төрки телдәге кулъязмалар, галимнең тәрҗемәи хәле һәм эшчәнлеге хакында үзе төзеп калдырган җыентык, галимгә язылган хатлар, фәнни-педагогик

[1] Анкетаның С.Вахиди кулы белән, гарәп графикасында татар телендә язылган төп нөсхәсе бүгенге көндә ТР ФАнең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты мирасханәсендә саклана (Ф.53, Тасв.1, 51 сак.бер.).

эшчәнлегенә караган төрле язмалар, документлар, бәяләмә-рецензияләр, халык авыз иҗаты үрнәкләре һәм башка бик күп материаллар бар. Анда галимнең 1928 елның июнь аенда Казан губернасының Спас кантоны авылларына оештырылган экспедиция материаллары да очрый. Шуларның бер өлеше көндәлек рәвешендә язылган дәфтәргә тупланган. Дәфтәр С.Вахиди кулы белән гарәп графикасында, татар телендә язылган. Галим китергән мәгълүматларга караганда, экспедиция барышында егермедән артык татар авылы, 5 чуаш һәм өч рус авылы барланган. Биредә ул төбәк, авыл тарихына караган һәм шул якның атаклы шәхесләре хакында мәгълүмат туплауга ирешә. С.Вахиди көнчыгыш телләрендә язылган кулъязмалар таба, Болгар ханлыгы чорыннан калган кабер ташларын өйрәнә. Укучылар игътибарына әлеге экспедиция дәфтәреннән, галимнең Иске Баллыкүл авылында тупланган[2] язмалары арасыннан Хәбибрахман Хөснетдин улыннан язып алынган мәгълүматлар тәкъдим ителә.

Иске Баллыкүл авылында

« ...Ул үз мәхәлләсенең Хәбибрахман Хөснетдин улы дигән бер бабайны чакыртып китерде. Аңар әүвәле мине тәгъриф итде *(таныштырды)*. «Бу кешедән бер дә курыкма, Хәбибрахман агай, бу бик ышанычлы кеше, белгәнеңне бер дә яшермә», – дип, бабайга минем турыда яхшы мәгълүмат бирде. Әүвәле мин: «Бабай, син Иске Баллыкүл авылы турында белгәнеңне сөйлә әле», – дидем. Хәбибрахман бабай шулай сөйли башлады: «Безнең Иске Баллыкүл авылы урынында әүвәле шәһре Болгарның бер авылы яки кечкенә бер шәһәре булган, дип, бездән алдагы картлар сөйли торганнар иде. Әнә, авыл янындагы иске кабер ташлары шуннан калган. Бу ташларның астында безнең ерак бабаларыбызның сөякләре ята, дип картлар сөйли торганнар иде. Бу Баллыкүлдә хан булган, аның торган шәһәре менә безнең Иске Баллыкүл авылында булган, дип әйтәләр иде. Әнә шушы Болгардан килгән нәселгә, Тәтеш өязе Күккүз авылыннан күчеп килеп, тагы берничә нәсел утырган. Шуннан соң теге – шәһре Болгар заманыннан калган нәсел белән Тәтеш өязеннән килгән нәселләр катышып, хәзерге Иске Баллыкүл авылы хасил булган. Менә безнең авылыбызның хәзерге кешеләре – борынгы Болгар нәселе белән Тәтеш өязеннән килеп утырган бабайлардан үрчегән халыклар инде», – диде. Мин: «Ни өчен Тәтеш өязеннән күчеп килеп утырганнар, шуның сәбәбен сөйләмиләр идеме?» – дидем. Хәбибрахман бабай җавабын да әйтә: «Беләсез бит, – ди, – элгәре урыс патшалары мөслеманнарны дингә бик каты кысканнар, авылы-авылы белән көчләп чукындырганнар. Чукынмаган мөселманнарны авылларыннан сөреп, икенче җирләргә таратканнар. Шулай итеп, бик күп мөселман авыллары әрәм булып беткәннәр. Менә монда авыр заманнар, безнең әбибабайлар өчен караңгы вә кайгы чоры булып, озак еллар шулай дәвам иткәннәр. Менә шундый дингә кыстау чакларында безнең бабайлар Тәтеш өязеннән күчеп килеп, Ыспас өязенең кап-кара куе урман белән чорналган бер почмагына, шәһре Болгар заманасыннан бирле дин исламны тотып килә торган бер авылга, әлеге

[2] Иске Баллыкүл авылында С.Вәхидигә авыл кешеләре белән очрашып, әлеге төбәк тарихына караган мәгълүматларны туплауда шушы авылның имамы – Габдессамад хәзрәт (Самад мулла) Габдерахман углы Габдерәхими ярдәм күрсәтә.



Сәет Вахиди кулъязмалары

Баллыкүл авылына килеп утырганнар. Бабайларның сөйләвенә караганда, безнең Баллыкүл авылы тирәсендәме яки шуның үзендәме шәһре Болгар ханлыгына буйсынган Гәрәй ханның шәһәре булган диләр[3]. Безнең авылдагы иске кабер ташлары әнә шул Болгар нәселеннән килгән Баллыкүлдәге иске нәселнең бабалары булган, дип сөйләшәләр. Безнең бабайлар күчеп килгәндә, әле бу шәһре Болгар заманасыннан бирле килә торган Баллыкүл авылының мөселманнары әле урысның законнарына бөтенләй баш имиләр, солдат бирмиләр, үзләре шәригать буенча хөкем итеп яшиләр икән, дип, картлар сөйләшә торганнар иде. Тәтеш өязеннән килгән соңгы нәселнең кайбер бабалары болай сөйли торганнар иде. Ул бабаларның берсе – Бәйкә баба, икенчесе – Боерган баба, өченчесен инде мин хәтерләмим. Шуларны сөйләшә торганнар иде. Хәбибрахман бабаның әйтүенә караганда, Баллыкүл авылының ике төрле дәвере бу көнгә кадәр кара тарихка мәгълүм: 1 нче дәвере Тәтеш өязеннән соңгы нәсел халык күчеп килгәнгә чаклы булган, шәһре Болгардан аерылып чыккан борынгы авыл булып яшәгән дәвер. Ул дәвер, кара тарихка караганда, рус законнарына буйсынмаган, патшалар хөкүмәтенә солдат бирми торган, элек-электән бирле үзләренең каршында мәкъбүл булып *(кабул ителеп),* варәсәт тарикы *(варислык юлы)* белән күчеп килгән шәригать хөкеме белән яши торган дәвер. Икенче дәвер, руслар Казан ханлыгын бетереп, бу тирәләрдәге татарлар арасына православие җиһангирлеген үткәзү юлында, татар авылларын таратып, ул авыл урынына урыс утырту, татарларны чукындыру, татарлар өстенә эшләнгән патшалар Русиясенең каты җәбер вә золым сәясәтен бөтен мәгънәсе белән иҗра иткән *(эшкә ашырган)* караңгылык дәвере. Менә шул дәвердә, икенче нәсел буларак, Баллыкүлгә Тәтеш өязеннән татарлар

[3] Янбакты авылының туксан ике яшьлек Гали мулланың сөйләвенә караганда, Гәрәй хан Иске Баллыкүлдән өч чакрым шәрыкта хәзердә тирән чокыр һәм үр белән әйләндереп алган һәм хәзердә дә бик күп алма агачлары сәламәт булып тора торган шәһәр хәрабәсе, Болгар ханына табигъ *(буйсынучы – Г.Х.)* Гәрәй ханның шәһәре булган икән. Бу турыда Янбакты авылындагы мосахабәдә мәгълүмат бар, шунда каралсын *(С.Вахиди искәрмәсе).*

күчеп килеп утыралар. Баллыкүлдә минем белән мосахабәдә *(әңгәмәдә)* булган бабалар, гомумән, ул авылда мин күргән кешеләр, ире һәм хатыны озын буйлы, мәһабәт кыяфәтле, үткен кара күзле, төреклек[4] канын, төреклекнең җисмани[5] җәһәттән булган бик күп хосусиятләрен саклап килгән кешеләр иде. Әгәр боларга яхшы мәктәп тәрбиясе бирелгән булса, боларның эченнән уйламаган эшлекле адәмнәр чыккан булыр иде дигән фикергә килдем.

Бу авылның Баллыкүл дип аталуы турында минем белән мосахабәдә булынган картлар мондый мәгълүматны сөйләделәр. Алар әйтәләр, иске заманнарда бу урын кап-кара калын урман, имәнлек икән. Имән агачлары әнә авылыбызның эчендәге күлгә егылып үсәләр икән. Ул заманда калын имәннәрдә умарта кортлары ил[6] булып бал җыялар икән. Хәтта ул заманда урманга умарта куеп, умарталык асрарга да хаҗәт юк икән. Кирәк вакытта халык шул имәннәрдән генә балны алып файдалана икән.

«Ул заманда калын имәннәрдә умарта кортлары ил булып бал җыялар икән. Хәтта ул заманда урманга умарта куеп, умарталык асрарга да хаҗәт юк икән. Кирәк вакытта халык шул имәннәрдән генә балны алып файдалана икән.

Менә шундый умарта кортлы калын карт бер имән, каты искән бер җил белән, әлеге безнең менә шушы күл өстенә ауган *(бу күл әле дә бар, Баллыкүл халкы шуның суын эчеп көн итә)* имән эчендә бик зур ил бал җыйган, төбеннән очына кадәр бал белән тулган булган. Имән күлгә аугач, аның эчендәге бал агып, күлгә чыккан. Халык шул суны эчкәннән соң, бу күл баллы күл икән, дигәннәр болар. Шуның соңында бу авылны Баллыкүл дип атаганнар. Болар, бу авылдан берничә йорт аерылып чыгып, Яңа Баллыкүл авылын нигезләгәч, бу авылны Иске Баллыкүл дип атаганнар», – ди.

Шуннан соң мин Яңа Баллыкүлгә якын шәһәр хәрабәсе хакында сөйләштем. Иске Баллыкүл кешеләре ул турыда миңа ошбу мәгълүматны бирделәр: «Яңа Баллыкүл янындагы кала өсте *(шәһәр хәрабәсе)* ул Нократ исемле урыс авылының басуында, моннан унбиш еллар алда әле ул кала урыны чирәм булып торадыр иде. Анда тәртип белән утыртылган бик күп алма агачлары бар иде. Бу алмагачлар – әче алмагачлар түгел, баг *(бакча)* алмагачларыннан татлы булган алмагачлар иде. Бу каланы шәһре Болгар заманында бер ханның крепосте булган дип сөйлиләр, хан үзе дә шушы шәһәрдә торган, аның шәһәреннән Янбактыга юл булган диләр. Ул урыннан мөселманча язулы әзгәрәй тәңкәләр табыла иде, анда чүлмәк ташлары да бик күп. Соңгы вакытта инде Нократ урыслары бу кала өстен сукалап, җир иттеләр, алмагачларын кискәләделәр. Кайсыберләре үзләре корыды. 1912 елда хөкүмәт акчасы белән күлләр казылганда бу каланың чокыры күмдерелде, аның чокырын күмгәндә байтак иске әйберләр тапканнар иде. Инде алар кайдадыр, белгән кеше юк, бәлки, Нократ урысларында әле дә бардыр», – диделәр. Бу кала урыны Иске Баллыкүлдән өч чакрым ераклыкта булган».

*Текстны басмага **Гөлчирә Ханнанова** әзерләде.* ■

[4] Биредә төркилек мәгънәсендә.
[5] Җисмани – гәүдәгә бәйләнешле.
[6] Ил – корт иле, бал кортларының корт анасы белән бергә аерым гаиләсе.

ТАТАР КИТАБЫ

«Япон дигән патшага плин булдык...»

Раиф Мәрданов

Ялуцзян елгасы буенда рус һәм япон яралылары. 1904 ел, апрель

Россия тарихындагы төрле сугышларда катнашкан һәм дошман әсирлегеннән кайткан татар солдатларының дәфтәрләре хәзер дә табылып-ачыкланып торуын моңарчы искәртеп язган идек[1]. Мәкаләбез нәкъ шундый дәфтәрләрнең күптән түгел генә табылган берсе турында. 1904-1905 нче еллардагы Рус-япон сугышында әсирлеккә эләккән солдат Ярулла Шаһиәхмәт улының утыз кәгазь күләмендә сакланып калган дәфтәрен 2016 елның җәендә Татарстан Милли китапханәсенең Арча районына оештырылган археографик экспедициясе вакытында Урта Сәрдә авылында яшәүче Яруллиннар Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге мөдире Айрат Заһидуллинга тапшырган. Дәфтәрне солдат Яруллaның оныгы – Кушлавыч авылында мәктәп директоры булып эшләгән Рамил Габделбәр улы Яруллин (1975-2012) башка истәлекләр белән бергә кадерләп саклаган.

Кызганыч, дәфтәр тулы түгел. Аның башындагы һәм ахыргы, шулай ук уртадагы берничә бите төшеп югалган. Әлеге дәфтәрдә шактый кызыклы, моңарчы текстлары фәндә билгесез бәетләр булганлыгы ачыкланды.

[1] Матрос Әхмәдулла дәфтәре: 1898-1906 нчы еллар/төз.: Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2017. – Б.4.

Тарихтагы иң дәһшәтле Рус-япон сугышын кыскача искә төшереп үтик. Төп сәбәбе төньяк-көнчыгыш Кытай (Манҗурия) белән Кореядә хакимлек итү булган империалистик сугыш 1904 елда Япония тарафыннан башланган. Бу сугышның иң зур вакыйгаларыннан дошманның Порт-Артурдагы рус флотын туздыруы; рус армиясенең Мукден шәһәре янында һәм флотының Цусима (Корея) бугазында тар-мар ителүе билгеле.

Мукден янындагы бәрелеш – Рус-япон сугышының 150 чакрымга сузылган фронттагы иң зур һәм иң канкойгыч вакыйгасы. 1905 елның 20 февраленнән 10 мартына кадәрге арада – өч атна дәвам иткән әлеге дәһшәтле сугышта генерал А.Н.Куропаткин җитәкчелегендәге рус гаскәрендә 280 меңләп солдат һәм офицер булган. Япон гаскәрендә исә 270 мең сугышчы исәпләнгән. Ике якныкын бергә кушып караганда, 2500 артиллерия тубы һәм 250 пулемет саналган, 24 меңнән артык сугышчы һәлак булган һәм 131 мең кеше яраланган. Шулардан рус армиясенең үлүчеләре 8705 кешене тәшкил иткән, 7109 сугышчы хәбәрсез югалган, 51 438 кеше яраланган һәм контузия алган. Рус армиясе гаскәриләреннән 21 мең кеше (шулардан 2537 яралы) әсирлеккә эләккән.

Рус-япон сугышы 1905 елның 23 августында (5 сентябрьдә) Портсмут солыхы белән төгәлләнгән, бик күп хәрби көчен югалтып, хурлыклы җиңелгән Россия кайбер биләмәләрен Япониягә бирергә мәҗбүр булган. Япон сугышы 1905 елгы Россия инкыйлабына да этәргеч биргән.

1904-1905 нче еллардагы Рус-япон сугышында, гомумән, рус армиясеннән – 79 454 хәрби әсирлеккә эләккән. Ә япон гаскәреннән 2104 кеше әсирлеккә төшкән. Япониядә рус армиясе әсирләре 29 лагерьда тотылган. Иң зурларында дистә меңнәрчә, мәсәлән, Осака шәһәре янындагы лагерьда 35 мең әсир (солдатлар, матрослар һәм офицерлар) тотылганлыгы мәгълүм. Офицерлар аерым һәм иркенрәк хәлдә булган. Әсирләрне диннәре буенча бүлгәннәр. Сугыш ахырына таба япон әсирлегендәге түбән чиннарга да бераз иркенлек бирелгән. Бөтен лагерьлардагы шартлар да бертөрле генә булмаган, әлбәттә. Япония белән Россия арасындагы солых килешүе буенча ике тараф та әсирләрне азат итеп, туган илләренә кайтарырга һәм алар өчен тотылган чыгымнарны түләргә тиеш булганнар. Россия армиясе һәм флотының японнар кулындагы хәрби әсирләре алтын белән 46 миллион сумга төшкән.

***

Солдат Ярулла Шаһиәхмәт улының хәзерге вакытта Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «2223т» шифры белән саклана торган дәфтәре тулаем диярлек бәетләр, мөнәҗәтләр һәм кыска җырлардан тора. Ике урында бәет-мөнәҗәтләрнең авторлары кем булганлыгы турында кыскача мәгълүмат теркәлгән. Дәфтәрнең 16б кәгазендә мондый юллар бар: *«Ошбу мөнәҗәтләрне чыгаргучылар Кытай патшасының җирендә гөрифтар вә интизар булып, үземезнең башларымызга килгән шәйләрдән (фәһем итеп укыгайсыз гыйбрәт алмак өчен) без, плиндәге адәмнәр, бернечә мөнәҗәтләр яздык... Язылды мең дә тугыз йөз дә алтынчы җылда, март числасының икенче көнендә. Кытай җирендә».* Дәфтәрнең 28а һәм 28б кәгазьләрендә дә дәфтәр иясе һәм бәет-мөнәҗәт авторларының Вильна (хәзерге Литва башкаласы Вильнюс) шәһәреннән сугышка чыгып китүләре, юлда узган губерна һәм шәһәрләрнең кайберләре теркәлгән. Алар эшелон белән Вильна, Минск, Орел, Уфа, Златоуст, Чиләбе, Курган, Тубыл һәм башка калалар аша узганнар. Беренче бәеттәге сугышка «декабрьнең унысында

чыгып киттек» дигән сүзләр 1904 елга туры килә. Икенче бәеттә 1905 елда: *«Килеп җиттек бу сугышка егерме алтынчы фибралда»,* – диелгән.

Әсирлектәге бу татар солдатларының сугышка эшелон белән барганлыгы бәетләрдәге юллардан да күренә:

«Утырттылар бер багунга
Кытай иленә барырга». (4б кәгазь)

«Без багунга утырдык,
Көне-төне барамыз». (5а кәгазь)

«Безләр киттек багун илән
Бик күп солдат утырып». (8б кәгазь)

Әлеге дәфтәрнең иясе мондый юллар белән белдерелгән:

«Бик сагынып яздым сезгә сәлам хатым,
Йад итүбән һәрбер сүздә Ходa атын.
Әгәр сөаль кыйлсагыз, бәнем атым
Ярулла бине Әхмәт угылы диер имди». (4а кәгазь)

Гомумән, кульязмада Ярулла Шаһиәхмәт улының исеме төрле битләрдә тугыз мәртәбә (әтисенең исеме Әхмәт рәвешендә кыскартылып яки Шаһиәхмәт дип тулы итеп) язылган. Аннан тыш, Казан өязендәге Бәрәскә авылыннан Мөхәммәтгариф Габделлатыйф улы турында да мәгълүмат теркәлгән. Күрәсең, Ярулла үзенең иптәше дәфтәреннән кайбер бәет-мөнәҗәтләрне күчергән чагында Мөхәммәтгарифның исемен дә язып алган. Икенче мөнәҗәттәге (6б кәгазьдә):

«Будыр минем мөнәҗәтем,
Ки Гыйззәтулла минем атым»,

– дигәндә, тагын бер кеше исеме очрый. Әлеге Гыйззәтулла, күрәсең, шул аерым бәетнең авторы булгандыр. Бәет-мөнәҗәтләрне иҗат иткән татар әсирләре хакында башкача төгәл мәгълүмат юк диярлек. Һәрхәлдә, Ярулла Шаһиәхмәт улы белән бергә япон тоткынлыгында татарлар аз булмаганлыгы:

«Бертугандай булдык монда
Җыелышкан җыен татар» (13а кәгазь)

– юлларыннан аңлашыла.

Алар, дәфтәрдәге бәетләрдән күренгәнчә, Манҗуриядәге сугышларда катнашып, Мукден шәһәре янындагы бәрелеш вакытында японнарга әсирлеккә эләккәннәр һәм тоткынлык вакытын Кытайда үткәргәннәр. Моны шушы юллар раслый:

«Бу сугышлар каты булды
Кытай җире җагында». (2а кәгазь)

«Кытай җирләренә килдем,
Яхшы-яманнарны күрдем». (24б кәгазь)

«Плин улдым японнарга». (4б кәгазь)

«Чыгып киттек Мукдингә
...Плин улдык ушал җирдә». (6а кәгазь)

«Хусэ дигән суларда,
Манжур дигән җирләрдә,
Ягмур кебек каннар акты
Без сугышкан җирләрдә». (17а кәгазь)

«Җапуннар Мукдинне чолгап алган,
Егерме мең гаскәремез шунда калган.
Плин төшкәч, йөрәкләрем ут янды,
Сезнең нурлы йөзеңезне күрмәк өчен». (17б кәгазь)

«Япон дигән патшага плин төшкәч,
Ни хәл итик ыризыкымыз шунда булгач?..
Японнар җыелдылар безне алгач,
Кулымыздан мылтык-кылыч алмак өчен». (17а кәгазь)

Бәетләрдә әсирлекне тасвирлаган урыннарның кайберләре мондый:

«Кытайларның каласы,
Ярык таш икән каласы.
Һәм аларның илендә
Бөтен солдат җир ашый». (4б кәгазь)

«Бер чиләктә аш бирәдер
Безнең кырык кешегә». (13а кәгазь)

«Дүрт казанда чәй кайната
Мең дә өч йөз кешегә». (13а кәгазь)

Соңгы ике юлда «мең дә өч йөз кеше» дигәндә, күрәсең, лагерьдагы әсирләрнең саны күздә тотылгандыр.

Бу сугышның мәгънәсезлеге һәм патшалар гаебе белән бихисап гөнаһсыз кешеләрнең һәлак булуы турында бәетләрдә мондый юллар бар:

«Ике патша күп халыкны
Бу сугышта җуйдылар». (13б кәгазь)

«Кяферләргә дөньялыкта мал бик күп кирәк,
Японнарның гаскәре күзгә зирәк.
Бу сугышта күп солдатлар булды һәлак
Бу бер фани дөньяның малы өчен». (20а, 20б кәгазьләр)

«Безнең кяфер патшабызны кара,
Булган нәчәлства малга алдана.
Хакъ Тәгалә кяферләргә каһәр сала,
Гөнаһсыз солдат канын түккән өчен». (20б кәгазь)

Япониядәге әсирләр 1906 елның 11 февраленә кадәрге арада Россиягә кайтарып бетерелгән. Ә Кытай (Манҗурия) территориясендәгеләре, Ярулла Шаһиәхмәт улының дәфтәрендә *«1906 елда, 2 мартта, Кытай җирендә»* дип язылганга карағанда, шул елның март аенда әле тоткынлыктан азат ителмәгән. Мукден янындагы сугыш 1905 елның март аенда төгәлләнгәнен исәпкә алганда, Ярулла Шаһиәхмәт улы һәм иптәшләре япон әсирлегендә гомерләренең бер елын үткәргәннәр.

Бәет-мөнәҗәтләрнең шактые сугыштагы солдатның хаты рәвешендә язылган. Чынлыкта да, хатларны бәет-мөнәҗәт рәвешендә язып туганнарына җибәрү гадәте – шигъри җанлы һәм моңлы халкыбызның электән килгән традициясе. Ярулла дәфтәрендәге бәет-мөнәҗәтләрдә теркәлгән мондый юллар да шундый дәлилләрдән:

«Бән алдым кулыма киягаз-каләм,
Хат язып әйтмәк өчен сезгә сәлам». (2а кәгазь)

«Әй, сөекле әнкәем,
Яздым сезгә сәлам хат».

«Бисмиллаһ» дип каләм алдым
Тотып сәлам язмага». (9б кәгазь)

«Сәлам яздым бәет кушып,
Йөрәк-бәгырьләрем пешеп». (15б кәгазь)

«Минем үткер кулымдадыр киягаз-каләм,
Олуг-кечек кардәшләргә яздым сәлам». (19б кәгазь)

Бу дәфтәрдә тупланган бәетләр һәм мөнәҗәтләр дә, башкаларына хас булганча, сугышның куркыныч күренешләре, яшәү һәм үлем, чиксез сагыш-моң, туган җирне һәм якыннарны сагыну, намаз-гыйбадәттән мәхрүмлек һәм шәригать кушканнарны үти алмау гаҗизлеге, әсирлек җәфалары, өметсезлек, билгесезлек, ачлык газаплары, котылу һәм сабырлык теләп Аллага ялвару, шулай ук башка хисләрне һәм сурәтләүләрне үз эченә ала. Мөселман татар сугышчыларының хәрби-тарихи бәетләрдә чагылган хәл-халәтләрен һәм кичерешләрен гомуми тасвирлап моңарчы язган идек[2], шуңа күрә Ярулла Шаһиәхмәт улының дәфтәрендәге бәетләргә дә хас булган андый үзенчәлекләргә җентекләп тукталырга ихтыяҗ юк.

1905 елның мартында әсирлеккә төшкән солдат Ярулла дәфтәрендәге бәетләр барысы да япон тоткынлыгында вакытта, дәфтәрдә күрсәтелгән даталарына карағанда, 1906 елның язына кадәрге арада теркәлгәннәр.

Бәет-мөнәҗәтләрдә шигъри осталык үрнәге булырдай өлгеләр очравы һәм төрле сурәтләү чараларының уңышлы кулланылуы, гомумән, халык иҗатының һәм татар

[2] Сугыш һәм солдат бәетләре / төз.: Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2016. – Б.18-22.

әдәбиятының күпгасырлык бай традицияләренә бәйле. Мәсәлән, 1 нче, 15 нче һәм 22 нче бәет текстлары XIII гасыр әдибе, шагыйрь Кол Галинең мәшһүр «Кыйссаи Йосыф» әсәре калыбында иҗат ителгәннәр. Шулай ук беренче бәеттәге «Мөбарәк йөзләреңезне күрсәм үзем» (2б кәгазь) дигән сүзләр XVI гасырда яшәп иҗат иткән Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасындагы:

«Кем мөбарәк Урдага барса үзем,
Ханның котлуг йөзен күрсә күзем»,

– дигән шигъри юлларын хәтерләтә.

Текстларның тел ягыннан төрлечә булуы да халык арасында киң таралган шигъри әсәрләр һәм мөнәҗәтләр калыбында иҗат ителүләренә бәйле. Кайбер бәет һәм мөнәҗәтләрнең шигъри төзелешләрендә төрки-татар суфый әдипләренең хикмәтләре, Габдеррәхим Утыз-Имәни, Габделҗаббар Кандалый, Һибәтулла Каргалый әсәрләренең чалымнары бар.

Ярулла солдат дәфтәренең 14а кәгазендәге «Солдат бәете» ахырында язып куелган:

«Бөтен дөнья бәнем улса,
Гамем бетмәс – нәдәндер бу?»

– юллары XVI гасыр шагыйре Мөхәммәт Фөзулиныкы. Әлеге юлларны соңгырак чор татар шагыйрьләре (мәсәлән, Әбелмәних Каргалый, Габделҗаббар Кандалый) үз әсәрләрендә кулланганлыгы мәгълүм.

Бәетләрдә һәм җырларда «япон», «японнар» дигән сүзләр бик күп. Японнарны тасвирлаган урыннарның кайберләре бу рәвешле:

«Японнарга плин төшкәч,
Тереләй тотып туныйдыр». (5б кәгазь)

«Японнарның атлары
Ефәк илән тышаулы». (17а кәгазь)

«Японнарның гаскәре күзгә зирәк». (2а кәгазь)

«Японнарның гаскәре бик вак кеше». (17а кәгазь)

«Японнарның ызбасы
Бар да кара таш икән». (5б кәгазь)

«Японнарның бакчасы,
Барча йимеш агачы». (24б кәгазь)

Дәфтәр иясе сугышта булган һәм әсирлек вакытын кичергән Кытай иле атамасы да егермеләп урында кабатланган. *«Ошбу кытайларның бәетләре булыр»* дип аталган бәеттә кытай халкының көнкүреше һәм гадәтләре турында кыскача мәгълүмат бирелгән: *«бигрәк озын сачләре», «ашаганы әче торма»* һәм *«дөге белән тары ярмасы», «өйдә юк һич нәрсәсе», «тәрәзәсе ак киягаз», «чурт та аңламай телләрен» һ.б.* ■

Безнең мирас №9 сентябрь 2021

Нарва ислам җәмгыяте

Ильяс Мифтахов

Нарва мәхәлләсе йорты

1917 елгы революция һәм Беренче бөтендөнья сугышы нәтиҗәсендә Россия империясенең кайбер төбәкләре үз бәйсезлекләрен игълан иткәч, әлеге төбәкләрдә яшәүче татарлар да шул дәүләт ватандашлары рәвешендә калырга мәҗбүр булганнар. Күпләр исә инкыйлабтан соң бу дәүләтләргә күчеп китүне мәгъкул күргәннәр. Мөмкинлек булу белән әлеге төбәкләрдәге татарлар, үзара берләшеп, җәмгыятьләр оештыру чарасына керешкәннәр. Үзәге мәчет, мәктәп һәм җәмгыять бинасы тирәсендә төзелгән әлеге оешмалар ватаннан ерак булып, чит халыклар арасында азчылык тәшкил иткәнлектән, үз милли, дини асылларын саклап калуны һәм киләчәк буынны шул рухи кыйммәтләр белән тәрбияләүне үзләренә максат итеп куйганнар. Чит илләрдә төзелгән җәмгыятьләр арасында иң танылганы һәм эшчәнлеген бүгенге көнгә кадәр дәвам иткәне Финляндия татарлары җәмгыяте, дисәк, шәт, ялгыш булмас. 19 нчы йөзнең беренче яртысыннан башлап Финляндия җирлегенә сәүдә белән сәяхәт кылучы татарлар соңрак анда төпләнеп тә яши башлыйлар һәм 1925 елда рәсми рәвештә үз җәмгыятьләрен төзиләр. Татарлар тарафыннан оештырылган башка җәмгыятьләр дә бар, әмма аларның күпчелеге, төрле сәбәпләр аркасында, үз эшчәнлеген туктаткан. Моңа мисал итеп Ерак Көнчыгышта

1920-1930 нчы елларда оешкан татар җәмгыятьләрен күрсәтеп китәргә мөмкин. Алар хәтта үз типографияләренә кадәр ачып, дәреслек, дини китаплар, газета-журналлар да бастырып, татарлар яшәгән төбәкләргә таратканнар.

Бу җәмгыятьләр рәтендә Эстония дәүләтендәге Нарва ислам җәмгыятен дә искә алу урынлы. 1920 елда дәүләт бәйсезлеге башка илләр тарафыннан танылган Эстониядә яшәүче татар һәм башка төрки халыклар да активлык күрсәтеп, үз оешмаларын төзи. Шулай итеп, 1928 елда Нарва шәһәрендә ислам җәмгыяте оеша. Бу оешманы төзүдә Финляндия татарларының ул еллардагы имамы Вәлиәхмәт хәзрәт Хәкимнең роле зур була. Аның киңәше буенча, Нарвадагы татарлар Финляндия ислам җәмгыяте үрнәгендәге оешма төзиләр. Бу оешма эстон телендә «Narva Muhamedi Kogudus» дип атала. 24 мартта уздырылган җыелыш карарына нигезләнеп оештырылган бу җәмгыять, 15 майда Эстония эчке эшләр министрлыгыннан алынган рөхсәт белән, үз эшчәнлеген рәсми рәвештә башлап җибәрә. Керем-чыгымнарга караганда, әлеге эштә Финляндия татарларының да матди яктан байтак ярдәм итүләрен күрергә мөмкин. Сүз уңаеннан шуны да әйтеп китү кирәк: Эстониядәге мөселманнарның икенче җәмгыяте 1939 елда Таллинда «Tallinna Muhamedi Usuühing» исемендә төзелә.

Алда әйтеп үтелгәнчә, 1928 елда оештырылган җәмгыять үз эшчәнлеген ун елдан артык дәвам иттерә. Мәхәллә бинасы мәчет ролен дә үтәп килә. Шулай ук җәмгыять тарафыннан дүрт ел буенча оештырылган курсларда балаларга милли һәм дини тәрбия бирелә. Ул чорда Эстониядәге татарларның саны аз булуына карамастан, җәмгыять актив эшчәнлек алып барган дип әйтергә мөмкин. Кайбер мәгълүматларга караганда, 1934 елда анда 170 мөселман кешесе саналып, шуларның 166сы татарлар булган.

1939 елның 23 августында Германия һәм СССР арасында төзелгән яшерен килешү нәтиҗәсендә, Көнчыгыш Европа дәүләтләре бу ике ил арасында бүленә. Эстония дәүләте СССР өлешенә тия. Бу килешүдән соң күп тә үтми, Германия Польшага һөҗүм итә. Моңа каршы СССР Эстония дәүләтен үзара ярдәмләшү килешүен төзергә мәҗбүр итә һәм Эстониядә үзенең хәрби базаларын төзи. 1940 елның августында исә СССР Югары Советы Эстония, Латвия һәм Литва Республикаларын рәсми рәвештә СССРга кабул итә. Шулай итеп, егерме ел бәйсез яшәгән Эстония дәүләте Советлар Союзына кушыла. Моның нәтиҗәсендә, Таллин һәм Нарва шәһәрләрендәге ислам җәмгыятьләренең дә эшчәнлекләре туктатыла, чөнки әлеге милли һәм дини оешмалар совет идеологиясенә туры килми. Соңрак, немец оккупациясе елларында, Нарва ислам җәмгыятенең мәчет, мәктәп һәм җәмгыять рольләрен үтәгән бинасы да бомбага тотылу нәтиҗәсендә җимерелә. Ислам җәмгыяте әгъзаларының кайберләре репрессияләнә. Сугыштан соң исә җимерелгән Нарва шәһәренә кире кайтырга рөхсәт ителмәү сәбәпле, татарлар Таллинда төпләнә. Хәзерге көндә Нарва шәһәрендә яшәүче татарларның күпчелеген совет чорында күчеп килүчеләр тәшкил итә.

«Яңа милли юл» журналының 1938 елгы 8-9 нчы берләштерелгән санында басылган «Нарва җәмгыяте исламиясенең унъеллык бәйрәме» дигән мәкаләдә зур мәгълүмат табарга мөмкин. Анда оешманың барлыкка килү тарихы язылган, бу эшкә үз өлешләрен кертүче шәхесләрнең исемнәре дә күрсәтелгән.

Мәкаләдә юбилейда балалар тарафыннан төрле җырлар җырлануы, шигырьләр сөйләнүе, спектакльдән өзекләр куелуы әйтелә. Гариф Рәми исә бу чараларны әзерләүче буларак искә алына. Ул – мәшһүр иганәче һәм шагыйрь Мөхәммәт Закир Рәмиевнең (Дәрдемәнд) улы. Чит илдә белем алып йөргән егет, 1917 елгы

болганышларны ишетеп, туган иленә әйләнеп кайтмый. Озак еллар Финляндиядәге татар балаларына белем биргән Гариф Рәмиев 1971 елда Рим шәһәрендә вафат була. Димәк, ул 1930 нчы елларда Нарва ислам җәмгыяте тарафыннан оештырылган курсларга да мөгаллим буларак үз өлешен керткән дип әйтергә мөмкин. Балалар тарафыннан куелган номерларга карaганда, биредә Ерак Көнчыгыштагы татар җәмгыятьләрендә үткәрелгән чаралар белән уртаклык күзгә ташлана. Гаяз Исхакый пьесасыннан өзек кую, Тукай шигырьләрен уку, сәхнәләштерү шул чордагы Кытайдагы татар җәмгыятьләренең бәйрәмнәрендә дә булган.

Эстония мөселман мәдәнияте үзәге тарафыннан чыгарыла торган «As-Salam» исемле газетаның 2010 елгы 3 нче санында басылган «Мусульмане в Эстонии» дигән мәкаләдә Нарва ислам җәмгыяте хакында кайбер төгәлсезлекләр киткән. Мәкаләдә оешманың 1937 елда төзелүе әйтелә. Дөреслектә исә җәмгыять үз эшчәнлеген рәсми рәвештә 1928 елда ук башлап җибәрә. Шулай ук газетада бирелгән фотосурәт астына: «Праздник в честь регистрации татаро-мусульманского общества в Таллине», – дип язылган. Хәлбуки, шул ук рәсем: «Яңа милли юл»ның 1938 елгы санында «Нарва җәмәгате исламиясе»нең 10 еллык бәйрәме мәрасиме», – дип бирелгән. Таллин ислам җәмгыятенең 1939 елда гына оешуын исәпкә алганда, әлеге фотосурәт Нарва җәмгыяте юбилее уңаеннан төшерелгән дип әйтү дөрес булыр.

Язмадан күренгәнчә, җәмгыятьнең киләчәккә өметләре зурдан була. Әлегә кадәр оешу, бина сатып алу кебек эшләр белән шөгыльләнергә мәҗбүр булган җәмгыять киләчәктә эшчәнлеген киңрәк җәелдерергә уйлый. Кызганыч ки, аларның бу өметләре чынга ашмый. Озакламый башланып киткән Икенче бөтендөнья сугышы, Эстониянең бәйсезлеген югалтуы аларның әлеге хыялларын чәлпәрәмә китерә.

(Текстны басмага әзерләгәндә авторның стиле тулысынча саклaнды, бары тик төрекчә сүзләр генә татар телендә бирелде.)

Нарва җәмәгате исламиясенең унъеллык бәйрәме

Нарва ислам җәмгыятенең корылуына үткән унбишенче майда ун ел тулып, бу юбилей мөнәсәбәте белән 26 нчы июньдә бер бәйрәм уздырылды.

Бәйрәм дини мәрасим белән башланды. Читтән килгән кунаклар һәм мәхәллә әгъзалары сәгать унике чиректә дини вә милли байраклар белән бик ямьле итеп бизәлгән мәчеткә җыелып өйлә намазын укыдылар. Намаздан соң хәзрәт Вәлиәхмәт Хәким җәнаплары бу бәйрәм мөнәсәбәте белән вәгазь сөйләде. Соңрак мәрхүм булган әгъзаларга мәгъфирәт, терек булганнарга да озын гомер, киң тормыш теләп дога кылынды. Дини мәрасим тәмам булгач, кунаклар һәм мәхәллә әгъзалары бу бәйрәм өчен махсус арендаланган зур бер залда туплaндылар. Мәчет кебек бу залның эче дә милли вә дини байраклар белән бизәлгән, зал уртасында мәҗлес өстәлләре ко-

«Нарва җәмәгате исламиясе»нең унъеллык бәйрәме мәрасиме

рылган иде. Кунаклар җыелып беткәч, җәмгыятьнең рәисе Хөсәен Фәтхулла бәкнең үтенүе буенча, хәзрәт Вәлиәхмәт Хәким, бик тәэсирле нотык сөйләп, мәҗлесне ачты һәм сүзенең соңында, Эстониядә тереклек итүче илдәшләребезгә тыныч вә иректе тормыш тәэмин итүче Эстония җөмһүрияте рәисе Пятс җәнапларына, эстон каһарман гаскәренә вә аның башлыгы генерал Лайдонер җәнапларына, Эстония хөкүмәте әгъзаларына һәм эстон милләтенә дога кылды.

Хәзрәтнең сүзеннән соң яшьләр вә мәктәп балалары сәхнәгә чыгып эстон маршын һәм төрек маршын хор белән әйттеләр.

Шуннан соң Нарва ислам җәмгыятенең вакытлы имамы **Мостафа Хәйретдин бәй** мондый нотык сөйләде: *«Хөрмәтле илдәшләр! Бүгенге бәйрәм мөнәсәбәте белән мин үз тарафымнан берничә сүз әйтергә телим. Ләкин сүзгә керешкәнче бу бәйрәмгә безнең белән бергә катнаша алмаган, мәрхүм булган әгъзаларыбызны яд итәргә бурычлыбыз дип уйлыйм. Безнең беренче рәисебез Закир Фәтхулла Шахмай, икенчесе Зариф Гали Хуҗа, баш язучыбыз Сафа Низаметдин һәм алардан әүвәл вафат булган Гатаулла Дилбирде мәхәлләбезгә күп хезмәт иткән булсалар да, бүген безнең шатлыгыбызга кушыла алмыйлар. Аларның һәм башка вафат булган әгъзаларыбызның рухын Җәнаб-ы Хак шат кылсын! Аларның барчасының хакхөрмәтләренә бер-ике минут аякка басуыгызны үтенәм!»*

Бу минутта мәҗлестә булучылар барысы да торып бастылар һәм үлгәннәрне хөрмәтләгәч, Мостафа бәк сүзенә дәвам итте: *«Хөрмәтле илдәшләр! Бүген без монда Нарва ислам җәмгыятенең унъеллык бәйрәмен уздыру өчен җыелдык. Бу безнең барчамыз өчен зур шатлык көне. Күрше Финляндиянең имамы һәм Эстониянең башка шәһәрләреннән килгән кунакларның арабызда булуы безнең шатлыгыбызны*

бигрәк тә арттыра, мәҗлесебезне тагын да күркәмләндерә. Бу бәйрәм – безнең унъеллык бәйрәмебез. Асылда бөтен Эстония төрекләренең 10 еллык, хәтта 100 еллык бәйрәме дип әйтергә мөмкин. Чөнки ата-бабаларыбыз йөз ел элек монда килеп йөри башлаганнар. Ләкин ул заманда илгә кайтып йөрү гадәт булганга, бер мәхәллә оештырылмаган, мәчет салу эше уйланылмаган. Аллаһка мең шөкер, хәзерге көндә безнең гыйбадәт урыныбыз, мәктәп урыныбыз – мәчетебез бар. Без бүген шуңа шатланып бәйрәм ясыйбыз. Шул бөек шатлык белән Нарва ислам җәмгыяте исеменнән һәм дә үз исемемнән барчагызны да ихлас күңелдән тәбрик итәм. Бу бәйрәмнең ясалуына сәбәпче булган, җәмгыять оештыру эшендә ярдәм күрсәткән барча илдәшләребезгә вә иң башта Финляндия имамы Вәлиәхмәт Хәким хәзрәт җәнапларына рәхмәт укыйм. Һәрбер милләткә хезмәт итүчеләрнең әҗере гиндә-Аллаһ (Аллаһ хозурында) булсын! Хөрмәтле илдәшләр! Без бу көннең кадерен, хөрмәтен яхшы аңларга, яхшы белергә тиешбез. Эстония кечкенә мәмләкәт булса да, җаныбыз-малыбыз тыныч, ни кылсак – юлыбыз ачык. Үз ата-бабадан калган гадәтләребезне тотабыз, гыйбадәтләребезне кылабыз, мәктәбебездә балаларыбызга дини-милли тәрбия бирәбез. Ни кылсак – барысы өчен хөрлек бар! Бөтен боларны тәэмин итүче булган эстон хөкүмәтенә даиман рәхмәт уку һәркайсыбызның бурычыдыр. Безнең шул тәшәккүрләребезне Нарва ислам җәмгыятеннән бер телеграмма белән хөкүмәткә белдерелүен тәкъдим итәм. Яшәсен эстон милләте! Яшәсен Нарва ислам җәмгыяте!»

Мостафа бәй сүзен тәмам иткәч, оешманың кятибе **Сәмигулла Зариф** *«Нарва җәмәгате исламиясе»*нең тарихын сөйләде. *«Яңа милли юл»* укучылары өчен дә кызыклы булачагын уйлап бу тарихны да язабыз.

«Хөрмәтле ханымнар, хөрмәтле әфәнделәр! Нарва шәһәрендә һәм дә Выру белән Тарту өязләрендә яшәүче мөселманнар 24 нче март 1928 нче елда Нарвада бер җыелыш ясадылар. Бу җыелыштан максат – үзләренең дини эшләре хакында сөйләшү вә киңәшү иде. Шул җыелышта бу мөселманнарның дини эшләрен тәртипкә куячак һәм башкарачак бер оешма төзергә карар чыгарылды. Җыелышка катнашучы мөселманнарның фикер берлеге белән, яңа төзеләчәк булган оешманың төп максаты буларак, бу оешма әгъзаларының дини вә мәдәни ихтыяҗларын үтәү һәм аларның бу өлкәләрдә алга китүләре өчен тырышу эше кабул ителде. Асыл ана ватаннарыннан аерылып чит бер мәмләкәттә яшәүче бу мөселманнар, үз дини, милли барлыкларын, ата-бабалардан мирас булып калган йолаларын саклау һәм аларны күрсәтү теләге белән бер фикергә килгәннән соң, бу фикерне тормышка ашыру өчен, берлек белән, кулга-кул бирешеп тырыштылар. Бу фикерне тормышка ашыру эше, безнең мәгънәви вә матди хәлебезгә күрә, зур һәм авыр бер эш иде. Чөнки безнең мондагы мөселманнар, үз туган җирләреннән, үз милләтләреннән, кардәшләреннән аерылып, чит бер илгә килеп, тормышларын яңадан корырга мәҗбүр булган кешеләрдер. Бу кыен хәлгә карамыйча, бирелгән карар тормышка ашырылды һәм үткән ун ел эчендә танылды.

Оешманың корылачагын сөйләгәндә, безгә бу эштә зур ярдәме тигән бер кешене бу мәҗлестә тәшәккүр белән искә алып узасым килә. Бу кеше бүген безнең арабызда, безнең кунагыбыздыр. Ул – Финляндия ислам җәмгыятенең имамы, хөрмәтле хәзрәт Вәлиәхмәт Хәкимдер. Моннан ун ел элек Вәлиәхмәт Хәким хәзрәтләре безнең арабызда мосафир иде һәм безгә Финляндиядәге илдәшләребез кебек оешма кору фикерен бирде.

Сүз башында әйткәнемчә, 1928 нче елның 24 нче мартында булган җыелыш шул шартлар эчендә тупланды һәм кабул ителгән карарны тормышка ашыру

өчен бер комиссия төзеде. Бу комиссиягә рәис буларак Зиннәтулла Сәйфулла, эш йөртүче буларак Низаметдин һәм хәзинәдар (кассир) буларак Мостафа Хәйретдин билгеләнделәр. Оешманың ясасын (уставын) хәзерләү эше Сафа Низаметдин белән Зиннәтулла Сәйфуллага тапшырылды. Тарту университетын тәмамлаганнан соң вакытсыз үлем белән вафат булган Сафа Низаметдин өстенә алган вазыйфасын чын ихлас белән үтәде вә оешмабызның эшләрен тәртипкә салуда күп ярдәм күрсәтте. Аның үлеме һәм безнең өчен, һәм милләтебез өчен авыр бер югалту булды. Оешмабыз яшәгән вакытта Сафа Низаметдин исеме дә яшәячәктер. Яса хәзер булгач, яңадан гомуми җыелыш тупланып, яса кабул ителде вә Закир Шахмай һәм Закир Байбур, Зариф Гали Хуҗа имзалары белән Эчке эшләр министрлыгына раслау өчен җибәрелде. Эчке эшләр министрлыгы тарафыннан яса 1928 нче елның 15 нче май көнендә расланды һәм шул көнне Нарва ислам җәмгыяте рәсми рәвештә дөньяга туды. Җәмгыятьнең беренче рәисе вазыйфасын мәрхүм Закир Фәтхулла Шахмай үтәде. Бу эшләр милләттәшләребез тарафыннан бөек ризалык һәм шатлык белән каршыланды вә һәркем бу хәерле эшкә ярдәм итүне үзенә дини һәм милли бурыч дип белеп, хәленнән килгәнчә тырышты. Ләкин үз көчләребез генә аз иде вә фикерләребезне тормышка ашыру авыр иде.

Бәрәкәт бирсен (Аллага шөкер), Финляндиядәге һәм Эстониянең башка шәһәрләрендәге кардәшләребез безгә ярдәм кулын суздылар. Финляндия төрекләреннән (төркиләреннән) 1777,95 крона акча җыелып, безгә тапшырылды. Бу эштә ул вакыттагы имамыбыз Исмәгыйль Дәүләтшаһ әфәнденең зур ярдәме тиде. Таллин мөселманнарыннан Фатих Закир вә Хәйрулла Мәһди фирмасыннан 500 крона һәм калган диндәшләребездән 170 крона бүләк килде. Бүген оешмабызның унъеллык бәйрәмен котлаганда, бу кардәшләребезнең безгә күрсәткән ярдәмләрен бөек шөкран (олы рәхмәт) белән яд итү, безнең вазыйфабыздыр.

Шулай ук әгъзаларыбыз да һәркайсы ярдәм итте, эстон фирмаларыннан акча җыюда Мостафа Хәйретдин һәм башка әгъзалар ярдәм иттеләр.

Эшләрнең букадәр уңышлы баруы нәтиҗәсендә, оешма исеменә бер йорт алу фикере туды һәм төрле тәшәббесләр (керешү, эшкә тотыну) соңында хәзерге мәчет бинасы 17,500 кронага алынды. Шул мөнәсәбәт белән унъеллык керем-чыгымнарыбыз хакында кыска гына мәгълүмат биреп узуны кирәкле күрәм. Оешма корылган көннән алып 1937 нче елның соңына кадәр кулыбызга 27718,28 крона акча кереп, 27710,54 крона акча чыккан.

Оешма корылганга кадәр шәһәребездә ана телендә курслар яки мәктәп юк иде. Оешма корылгач, 1930, 1931 һәм 1933 нче елларда курслар оештырылып, балаларыбызга дини-милли тәрбия бирелде. Курсларда һәр ел уртача 25тән 30га кадәр бала укыды. Мәктәп чыгымнарын мәхәллә әгъзалары үзара кушылып түләделәр.

Әгъзаларыбыздан Сибгатулла Мәһди, Фатих Закир, Хәйрулла Мәһди һәм Мостафа Хәйретдин әфәнделәр зуррак сумма белән кушылып, бу эшкә ярдәм күрсәттеләр. Тулмый калган акча оешма кассасыннан тәмамланды. Бу курслардан соң, үкенечкә каршы, берничә ел курслар оештырылмады. Инде бу 1938 нче елда яңадан 4 айлык курс ачылды. Бу курста 24 бала укый. Быел мөгаллимгә хезмәт хакы өчен оешма кассасыннан 150 крона алынды һәм әгъзабыз Мостафа Хәйретдин бәй 100 крона ярдәм итте.

Оешма корылгач, мәхәлләбезнең каберлеге оешма исеменә яздырылды. Бу каберлекне Гатаулла Дилбирде үз заманасында, шәһәр идарәсеннән алып, тирә-ягына койма эшләткән иде. Бу бәйрәмдә мәрхүм Гатаулла Дилбирденең әлеге хәерле эшен искә төшерү – бурычыбыздыр. Моннан берничә ел элек шәһәр идарәсеннән яңадан

җир алынып, каберлек зурайтылды. Минем әлегәчә сөйләгән сүзләремнән күренә ки, бу үткән 10 ел эчендә безнең байтак кына көчебез оешманы кору, нигезләндерү өчен сарыф ителде. Шул сәбәптән, бәлки, чираттагы эшләребезне тулысынча эшләргә мөмкин булмагандыр. Бу чираттагы эшләрен тәртипкә салу, алга җибәрү киләчәк елларда вазыйфабыз булырга тиеш.

Киләчәк өчен эшләнәчәк эшләребез, йортыбызның бурычыннан котылу, дәвамлы мәктәп ачып укыту эшләрен тәртипкә салу, вазыйфалы имам билгеләү, дини эшләребезне башкаручы бу оешмабыз янында бер яшьләр берлеге корып, милли һәм культура эшләребезне аңа тапшыру булачактыр.

Безнең өчен бик мөһим булган тагын бер нәрсә – Эстониядән башка мәмләкәтләрдә тереклек итүче илдәшләребез белән, иң беренче чиратта, Финляндиядәге илдәшләребез белән якынрак мөнәсәбәт баглау һәм берләшеп эш йөртү булачактыр».

Сәмигулла Зариф бәй сүзен тәмамлагач, төрле кешеләр бәйрәмне котлап сүз сөйләделәр. Беренче булып **Вәлиәхмәт Хәким хәзрәт** җәнаплары бәйрәмне үз исеменнән һәм Финляндия ислам җәмгыяте, Финляндия төрекләре берлеге исеменнән тәбрик итте. Бу мөнәсәбәт белән, аның сөйләгән сүзе әһәмиятле булганга күрә, кыскартылып биредә китерелә.

«Бәйсезлектән, үз-үзенә, үз җиренә-суына хуҗа булудан мәхрүм булган бер милләт, үзенең милли барлыгын саклап, аны дәвам иттерү өчен һәрнәрсәдән элек мәгънәвиятка ябышырга мәҗбүрдер.

«Кардәшләр! Дини җәмгыятегез рәсми рәвештә раслануына, мәктәбегез, мәчетегез үз йортыгызда ачылуына 10 ел тулу мөнәсәбәте белән үтә торган бөек бәйрәмегезне мөкатдәс мәчеттә дини мәрасим белән башладык. Җәмгыятегезне төзүдә мәгънәви ярдәмләре, мәчет, мәктәп өчен алынган өегезгә матди ярдәмләре тигән Эстония һәм Финляндиядәге хөрмәтле кардәшләрнең вафат булганнарына мәгъфирәт, терек булганнарына озын гомер, киң тормыш теләп дога кылдык. Йөрәктән чыккан пакь авыз, тугры тел белән теләгән теләкләребез фәрештәләрнең әмин дигән вакытына туры килеп, Газизел-Хәким булган Аллаһ каршында кабул булды.

Инде зур залда бәйрәмнең милли һәм әдәби өлеше башланып киткәнче, җәмгыятебезнең фәхри (мактаулы) әгъзасы сыйфатым белән һәм Финляндия ислам җәмгыяте, Финляндия төрекләре берлеге исемнәреннән вәкил булып килүем уңае белән, бернечә сүз әйтүне урынлы дип беләм.

Кардәшләр! Бәйсезлектән, үз-үзенә, үз җиренә-суына хуҗа булудан мәхрүм булган бер милләт, үзенең милли барлыгын саклап, аны дәвам иттерү өчен һәрнәрсәдән элек мәгънәвиятка ябышырга мәҗбүрдер. Хаким булган милләтнең бөтен матди-мәгънәви һөҗүмнәренә каршы кулланылган мәгънәвият әхвалләргә күрә төрле төстә булырга мөмкиндер.

Иске заманнарда милли барлыгыбызны саклау һәм дәвам иттерү өчен булган тартышларыбызда бөек роль уйнаган нәрсәбез – динебез иде. Милләтебез, телебез, гадәт һәм йолаларыбыз озак вакытлар динебез аркасында сакланып килгән. Хәзер әхвалләр үзгәрде. Хәзерге заманда мәдәният дөньясында милли дошманны кире кагуда дин урынына башка нәрсәләр куелды. Ул гамәлләр мәдәни гамәлләрдер. Сез арасында яшәгән эстон милләтенең мәгънәви кораллары булган мәгарифе, әдәбияты,

музыкасы астында изелеп калмас өчен сезнең дә дини вә милли көрәшегезнең башында шул ук мәгънәви кораллар белән коралланган булуыгыз кирәк. Кулларында мәгънәви кораллары булмаган бер милләткә очкыч, туп, мылтык кебек матди кораллар да буйсынмый. Бу тәҗрибә белән билгеледер. Мәгънәвияты гасрый мәдәнияты булмаган дүрт йөз миллионлык Кытай гасрый мәдәнияты булган алтмыш миллионлык Япониягә җиңелде. Бу хәл алтмыш кешенең дүрт йөз кешедән өстен булуын күрсәтә. Инде мәгънәви һәм матди кораллар белән камил рәвештә коралланган бер милләт өчен дә үзен саклый белү өчен тагын да мөһим бер шарт бардыр. Бу шарт – берлектер. Испания вакыйгасы үз эчендә берлек булмаган бер милләтнең ничек харап булганын бик яхшы күрсәтә».

Бу урында бик хөрмәтле имам әфәнде берлеккә өндәп сүзенә дәвам итте һәм сүз арасында шушы аяти кәримәләрне укыды:

«Вә әтыйгуллаһә вә расүләһү вәля тәнәзәгу фәтәфшәлу вә тәзһәбә рихекөм вәсбиру иннә Аллаһә мәгас-сабирин»*.

«Аллаһ Җәллә Җәлалеһү хәзрәтләре бу могҗизалы аяти кәримәсендә, беренче Аллаһка һәм аның пәйгамбәренә (с.г.в.) итагать итегез дигәннән соң, тагын: «Фәтәфшәлу вә тәзһәбә рихекөм», – дип әйткән. Коръәни Кәрим терминологиясендә тәназугъ – берберсе белән маташу, аерымлыклар, ихтилафлар тудыру, фәшел – куркаклык, зәгыйфьлек; рих – куәт, дәүләт дигән сүзләр булганга күрә, аяти кәриманең мәгънәсе – «Низагъ кылышмагыз, бер-берегез белән бәхәсләшеп маташмагыз, дошманлашмагыз – куркаклашырсыз, зәгыйфь булырсыз, куәтегез, дәүләтегез кулыгыздан китәр».

Бер-берсе белән булышкан бер милләт әгъзалары дошманына каршы үзенең барлыгын саклый алачак матди көчләр хәзерләргә вакыт һәм мөмкинчелек таба алмас, моның белән бергә мәгънәви куәттән дә мәхрүм калыр.

Кардәшләр! Аллаһка итагать иткән, ислам пәйгамбәре Мөхәммәт (с.г.в.) күрсәткән юл белән киткән, берлеге, бәйләнешы бар булган бер ислам җәмәгате дәүләттән, куәттән, сәгадәттән мәхрүм калмас. Аллаһның боерыгын тыңламаган, ислам пәйгамбәре Мөхәммәтнең (с.г.в.) сүзләренә колак салмаган, бер-берсенә дошман булган бер ислам җәмәгате бәхетсезлеккә юл тотудан, юкка чыгудан үзен коткара алмас».

Бу урында иттифакъ хакында тәэсирле сүзләр әйткәннән соң, хөрмәтле имам хәзрәтләре, сүзенә дәвам итеп: «Вәсбиру иннә Аллаһә мәгас-сабирин», – җөмләсен укыды вә диде ки: *«Сабыр – һәртөрле катылыкларга күкрәк киерү, дошман һәм куркыныч каршында чыдамлыкны кулдан ташламаудыр. Ислам каршында сабыр – бөек бер фазыйләттер. Фәкать мәхкумияткә, әсирлеккә, кыйналуга, сүгелүгә һәм төрле түбәнсетүләргә чыдап, аларны көрәшсез кабул итү сабыр түгелдер. Болар – кешенең шәрәфен китәрә торган нәрсәләрдер. Котылу чарасын күреп тә котыла алмый мәшакать вә мәхрүмлекләргә төшсә, күкрәк киереп чыдау – сабырлыктыр».*

Вәлиәхмәт хәзрәтнең бу гаять гүзәл нотыгы мәҗлестә катнашкан кунакларга бөек тәэсир ясады. Хәйрулла Мәһди бәй, Таллин мәхәлләсе исеменнән, тәэсирле сүзләр белән бәйрәмне тәбрик итте. Соңрак Мөгаллимә туташ Хәйретдин яшьләр һәм мәктәп укучылары исеменнән бәйрәмне котлап сүз сөйләде вә бәйрәмнең оештырылуы өчен балаларның ата-аналарына һәм мәхәллә әгъзаларына рәхмәтләр укыды.

Нарва ислам җәмгыятенең әгъзасыннан Зиннәтулла Сәйфулла бәй бәйрәмне котлап сөйләгән гүзәл нотыгында кайнар сүзләр белән халыкны иттифакка, берләшеп эш итәргә өндәде.

---

* Коръәни Кәрим, «Әнфал» сүрәсе, 46 нчы аять. *(И.Мифтахов искәрмәсе.)*

Таллин төрекләреннән Гайсә бәй Магҗан бәйрәм өчен махсус язылган шигырен укыды. Шуның белән бәйрәмнең беренче бүлеме тәмам булып, аш мәҗелесе башланды. Аш һәм чәйдән соң тәнәфес игълан ителде.

Кич белән бәйрәмнең әдәби бүлеме ясалды. Бу бүлемнең программасы бик тулы иде. Яшьләр һәм мәктәп балалары тарафыннан төрле милли җырлар җырланды, шигырьләр әйтелде, күрсәтүләр ясалды. Спектакль өзеге буларак Гаяз Исхакыйның «Дулкын эчендә» исемле китабының 2 нче пәрдәсе сәхнәгә куелды. Бу пәрдәдә баш рольләрне алып баручылар: Разыя роле Сәгадәт ханым Низаметдин тарафыннан, Бәкер роле Сәмигулла Зариф һәм Хәйрулла роле Гали Зариф тарафыннан үтәлде. Болардан башка пәрдәгә катнашучылар: Гафур Бай, Хәсәнә Фәтхулла, Фатыйма Зариф, Хәят Шахмай, Мөгаллимә Хәйретдин, Әхмәт Хәйретдин, Габделкадир Нуретдин, Рабига Дакир (Закир?), Рәхимә Зариф, Гөлҗиһан Хәйретдин. Моннан башка Габдулла Тукайның «Дәрес беткәч уйнарга ярый» исемле әсәре күрсәтелде. Аны башкаручылар: Хәйрелбану Мифтахетдин, Халидә Сәйфулла һәм Мөнирә Имаметдин.

Милли җырларыбыз ике хор тарафыннан башкарылды. Беренче хор – яшьләр хоры, икенчесе балалар хоры иде.

Яшьләр хоры тарафыннан «Былбыл», «Өмид йолдызлары», «Бәгърем багалмам», «Мөкатдәс» һәм башка тагын берничә җыр һәм шигырь башкарылды. Бу хорда катнашучылар: Хәсәнә Фәтхулла, Мөгаллимә Хәйретдин, Фатыйма Зариф, Хәят Шахмай, Разыя Мифтахетдин вә Зәйнәп Мифтахетдин. Балалар хоры тарафыннан «Кара урман», «Заманай», «Халык җырлары» кебек берничә милли җыр җырланды. Хорга катнашучылардан аеруча Зәйнәп Мифтахетдин «Мәдинәкәй» көен, Фатыйма Зариф белән Хәсәнә Фәтхулла «Галиябану» өзеген һәм яшь балалардан Мөнирә белән Халидә Имаметдиннәр Сәгыйть Рәминең «Авыл» исемле шигырен җырладылар. Программадан тыш буларак, Гафур бәй моңлы тавыш белән бер-ике милли көй җырлады.

Мәктәп балалары тарафыннан милли шагыйрьләребезнең төрле шигырьләре әйтелде. Программаның һәр номеры уңышлы булды. Кичәгә катнашучыларның барысының да яхшы хәзерләнгән булуы күренде һәм караучылар да бик шат булдылар. Кичә тәмам булу мөнәсәбәте белән сөйләгән чыгышында Мостафа Хәйретдин бәй кичәнең әдәби өлешен оештыручы мөгаллим Гариф Рәми бәйгә һәм кичәгә катнашучы яшьләргә, балаларга Нарва ислам җәмгыяте идарәсе җитәкчелеге исеменнән рәхмәтләрен укыды. Кичәнең күңелле узуына ханымнар тарафыннан хәзерләнгән чәй өстәленең дә файдасы күп булды. Кичәнең әдәбият бүлеме тәмам булгач, кунаклар озак итеп үзара сөйләшеп, дәртләшеп утырдылар һәм төнге сәгать икедә генә таралдылар.

Бәйрәмнең икенче көнендә шул ук залда Хөсәен Фәтхулла, Хисаметдин Низаметдин, Гомәр Нуретдин, Зиннәтулла Сәйфулла һәм Габдулла Нуретдин тарафыннан кунакларга зур бер мәҗлес оештырылды. Бик күркәм үткән бу мәҗлестә милли эшләребез турында сүзләр сөйләнде. Мәҗлестә, Таллин мәхәлләсе әгъзаларының күбесе катнашуыннан файдаланып, мәктәп эшләре турында да фикерләр сөйләнде һәм бик мөһим булган бу эшне моннан соң ике мәхәллә бергәләшеп алып бару хакында халык тарафыннан бертавыштан карар бирелде.

Шул рәвешчә Нарва ислам җәмгыятенең унъеллык бәйрәме бик уңышлы чыкты һәм Нарва мәхәлләсенең җирле бәйрәме рәвешендә генә калмыйча, Эстониядә яшәүче барча илдәшләребез өчен милли бер көн булды. Бу көн катнашучы кунакларда онытылмаслык бер хатирә калдырды. ■

КОТОЧКЫЧ АЧЛЫК

СӘХИФӘ ИДЕЛ БУЕНДАГЫ 1921-1922 НЧЕ ЕЛГЫ АЧЛЫКНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА ҺӘМ АЧЫГЫП ВАФАТ БУЛГАН МӘРХҮМНӘР ИСТӘЛЕГЕНӘ БАГЫШЛАНА.

Күгәрчен авылыннан Сәйфетдин Мөхәммәтсадыйк углы Тәүкәт (1898) сөйләгәннәрдән. (Истәлекне язып алу вакыты –12.05.1971 ел.)

«1921 елның ачлыгында авылның 50-60 проценттан артык игенче хуҗалыклары җиккән атларын, ачлыктан үлмәс өчен, суеп ашадылар. Ачлыктан исән-имин чыкканнары 1922 елны яшәрлек уңыш алганнан соң, кабат, ничек кенә булса да, ат алу эшенә керештеләр. Һич тә булмаса, ике хуҗалыкка бер ат алу теләге белән алар ачлык булмаган җирләргә таралыштылар. Ул ачлык вакытында безнең дә атыбыз беткән иде. 1922 елны ничек кирәк алай үткәрдек. 1921 елда тишелми калган орлыклар кабат тишелеп чыгып, чәчелмичә калган кырлар да уңыш бирә, әмма игенче хуҗалыкларына атсыз яшәү һич мөмкин булган хәл түгел иде. Ул заманда әтигә 68 яшь. Йортыбызның иң зур терәге шушы кечти апыйда. Мин үз хакымда берни дә әйтмим. Ул елны миңа 19 яшь тулган иде. Шуңа да карамастан, мин бик йомшак, юаш һәм йөрәксезрәк идем. Шуңа күрә дә күп вакытларда апый мине «юкка чыккан» дип шаяртып килә иде. 1923-1924 нче елның кышында авыл кешеләре Себергә атка барырга хәзерләнделәр. Өй эчебез белән без дә ат алырга хыялланабыз. Тартып-сузып булса да акча җыябыз да, авыл кешеләре белән мин дә Себергә китәм. Безнең анда барган иптәшләребез: Сабитов Гарифетдин, Мөхәммәдиев Әүхәди, Миңлегали Хәйри, Касыйм Чәпәшкә, Фәсхи Даут, Мөхәммәдгали Ибраһим КОНО, Нәҗиб Әхмәдгали, Хәмит, Бозау Вәлимөхәммәт улы, мин, М.Починоктан Семен Силантьевич Белов һәм балыкчы Фрол дәдәй иде.

Без февраль башындагы бер көндә җәяүләп Арчага барабыз һәм шул көнне поездга утырып китәбез. Ничә көн барганбыздыр – анысы хәтердә калмаган. Күпмедер вакыт узгач, Төмәнгә барып төшәбез. Шул көнне үк һәркайсыбыз ат алабыз да кайтырга ук чыгабыз. Гарифетдин Сабит ялгызына ике ат алды. Мөхәммәтгали белән Фрол дәдәй икесенә берне алдылар. Шулардан башкаларыбыз барыбыз да берәрне алдык. Кайтканда атларыбызны чанага җигеп, ат аягы белән кайтабыз. Өйдән чыкканда ук акчаларыбыз чамалы булганга күрә, үз ризыкларыбыз ничек кысылган булса, атка бирергә дә берни дә юк иде. Кайсыларыбыз ачлы-туклы, кайберләребез бөтенләй ачка тилмереп кайта иде. Атлар арасында минем атым барысыннан да зуррак гәүдәле булганга, аны ашату канәгатьләнерлек түгел иде. Шул сәбәпле, ул кайта-кайта бик ябыкты. Иптәшләр артыннан калмыйм, дип, миңа аны куарга туры килә. Аерылып калудан куркам. Авыл аша узганда ат кайда ачык капка күрә, шунда кереп китәргә омтыла иде. Күз ачкысыз буран чыга. Кирмән башының аргы ягында бер тауга җитеп туктталабыз. Тауга күп итеп кар салган. Үрмәләп тә менә алмыйбыз. Кулларыбыз белән карны ничек кирәк шулай ишкәләп, атларыбызны җитәкләп диярлек менгерәбез. Кирмән башына җиткәч, анда фатирга кереп, атларга салам бирәбез дә үзебез

чикмәнле бәрәңге пешереп, Кирмән башыннан чыккач, юлыбызны туры Чаллыга тотабыз. Анда Сабит Гарифетдиннәрнең карендәшләренә кереп төн кунабыз. Аннан иртә чыгабыз да актык араны үтәбез дип киләбез. Соңгы көнендә атым актык чиккә килеп терәлгән иде. Балтачны чыккач, иптәшләребездән калабыз. Атны алга җибәреп, үзем әкрен генә ат артыннан киләм. Тик атым егылыр дип курка идем. Без ат белән эчертмәнең бире ягына җиткәндә, кулына ипи тотып апый да каршы килеп җитә. Ул елларда бу ат 16-17 яшьләрдә булгандыр инде. Кара төстә, уртадан зур гәүдәле. Зур, куәтле һәм бик акыллы иде. Агач сука белән йөри белми иде, өйрәнде. Бу ат безгә бик күп игелекләр күрсәтте. 5-6 еллар җиккәннән соң, картаю сәбәпле бетерелде. Бу көннәрдә Себергә атка барган 12 кешедән бары тик минем белән КОНО Ибраһимның Мөхәммәдгалие генә калды, калганнарыбыз ахирәткә күчте».

Тәберде Чаллысы авылыннан Нургаян абый һәм Хәтимә апай (1934) сөйләгәннәрдән (29.09.2014).

«Әниләр 1921 елгы ачлыкларны исләренә төшереп утыралар иде. Ул елны көн саен авылдан чана белән тартып зиратка мәет китереп торганнар. Бик күп кеше үлде, ди торганнар иде. Әни 1911 елгы иде. Ул вакытта яшь булганнар әле алар. Шул күргәннәрен, исләрендә калганнарын гына сөйлиләр иде. Атлары булганнары атларын суеп ашап исән калды, атлары булмаганнары үлде, ди торганнар иде. Аңынчы кешеләрнең, җиргә булган налугыгызны түли алмыйсыз, дип, булган бар ашлыкларын себереп, талап алганнар. Җилпучта калган оннарына чаклы алып чыгып киткәннәр дип сөйлиләр иде. Сәвит таламаган булса, кеше ул чаклы күп үләсе булмаган әле ул...»

Тәберде Чаллысыннан Шәмсебәдәр апай (1925) сөйләгәннәрдән (4.11.2014).

«Әнинең Габдуллаҗан абыйсы белән энесе Фатыйх абыйны Магниткага кудылар. Барып йөргәләдек. Фатыйх абыйның хатыны анда кулларын сындырган иде, ач иде инде алар. Ач булып, каядыр барып кәбестә яфраклары җыеп йөрделәр. Әнинең моннан аларга посылка салгалаганын беләм. Әни җилпуч белән он иләп җибәрә иде: «Шушының белән торалар бит алар», – дип. Бер хатларында: «Әй, апай, урыслашып та бетмәс идек, туган җирләрдән кумаган булсалар...» – дип язганнарын хәтерлим.

Әни, 1921 елгы ачлык вакытында ачтан үлүчеләр булды, дип сөйли, атап кешесен әйтми иде. Ачлык елларында Ханов Газизнең атасы: «Берсе калса да җитәр иде, ачка үлеп бетәләр инде дип сөйләгән», – дип әйтәләр иде. Аптырагач әйткәндер инде. Үзебез дә ничек үлми яшәгәнбездер инде...»

Яңа Сала авылыннан Шәрәфиева Назыймә апай сөйләгәннәрдән (28.12.2014).

«Яңа Сала авылында, Габделхәй абыйларның ике катлы йортында, 1921 елгы ачлык вакытында балаларны тукландыру өчен ашханә ачканнар. Биектау авылыннан Мәрфуга апайның ире (сугыш вакытында офицер булган) ачлык елны Америкадан килгән ашлыкны балаларга ашату буенча эшне җитәкләгән. Анда минем Маһирә әби дә балаларга ризык пешерергә булышкан. Аның: «Балаларга кофе кайнатып эчерә идем», – дип сөйләгәннәрен дә хәтерлим. Мәрфуга апайның ире, үзен нәчәльник икәнен танысыннар өчен, кулына, рулон кебек бөгәрләп, гәҗит тотып йөргән. Аңа ашханәдә ашарга дип ризык салып биргәч, ач булса да, балалар хакына кермим, дип ашамаган».

Нажия апай сөйләгәннәрдән (8.08.2015).

«1921 елгы ачлыктан халыкны Әмрикә ярдәме (АРА оешмасы) гына коткарып калды, ди әти. Чистайдан китерелгән ярдәм арасында кофеларга хәтле булган. Сугыш чорында да халык күп кырылды. 1911, 1914, 1936 нчы елларда да ачка үлүчеләр күп булган. Черек бәрәңге, алабута, элмә кайрылары барысы да ашалды, урман буендагы агач кәүсәләре ап-ак төстә калды. Тегермәндә тарттырылган кайры оныннан авыр йомышларын үти алмыйча тилмерделәр. Кычыткан, бәрәңге яфраклары да ашалып бетте. Мал асраучылар гына исән-сау калды. Үләннәр ашау өстенә, сөте, катыгы, мае да кирәк бит әле».

Биектаудан Галия (1952) апай сөйләгәннәрдән (17.10.2016).

«1921 ел турында Тәти апай (Мөнәвәрә) сөйли иде: «Абый әйтте, быел бик авыр ел булачак, дип. Шул сәбәпле бик күп яшелчә утырттылар: кишер, кәбестә, шалкан, чөгендер. Астагы инештән без, кызлар, җәй буе шуларга су ташып үлә яза идек. Шуның белән беренче елны ярыйсы гына кичердек», – дип. Икенче елны, әти әйтә, авылга кагылдым, ди. Әни шул чакны миңа дип табынга ипи чыгарып куйды, ди. Ул ипи яртылаш алабута, имән чикләвекләре кушылган... Ашый торган түгел иде. Шуннан әти: «Юк, әни, болай булмый», – дип, әниләренә кайдандыр ике пот ашлык юнәтеп алып кайтып биргән».

*Истәлекләрне **Нурулла Гариф** язып алды.* ■

Безнең мирас №9 сентябрь 2021

«Күңелемне тартып калды»

Мирхәйдәр Фәйзи

1923 ел, июль

1ендә иртүк уяттылар. Чәй генә эчтек тә, Һашим ат җикте. Яңадан килү уйларында да торганга, китү авыр тоелмады. Тик Сәетгәрәй абый бик читенсенә. Икрам, Әхмәт, Мөхәммәт йоклап калдылар. Арбага утырыр алдыннан абый, җиңги белән бакчага кердек. Бүген төннән пешкән кура җиләкләрен үзем җыйдым. Җиңги ак карлыган, абый виктория җыеп китереп бирде. Учым тулы җиләк булган хәлдә арбага мендем. Арба өстеннән абый, җиңги, Һашимнарга да ашаттым. Сәетгәрәй абый, Кунерга кадәр озатачак булганга, безгә утырды. Җиңги капка төбендә озатып калды. Нык торсам да, күңелем азрак йомшады. Өйдә дога кылдырганнарында бер бөртек яшем дә чыга язып калды. Гади генә ташлап китеп булмый. Хуш, Шода, хуш, туганнар, хуш, күңелемнең якыннары – җегет-кызлар! Сау йөреп, сау яшик. Бәлки, күрешербез дә, кем белә.

Артыма әйләнеп Шодага карый-карый Кунерга җиттек. Сәетгәрәй абый белән Кунер урамында хушлаштык. Йомшак тавыш белән әйткән соңгы «хуш»ы күземнең яшен актырып чыгарды. Шулай да тиз генә тыелдым. Сәетгәрәй абый калды. Авылны чыкканчы артка әйләнеп карадым. Баскан урынында бездән күзен алмый карады да торды. Кызганыч булып торып калды. Хуш, иң зурыбыз булып калган Сәетгәрәй абый! Саулыкта тагы күрешеп куанышыйк!

Һашим белән барабыз. Бер туганым – яраткан, дуслашкан энем янымда әле. Аның белән җуандым. Ул миңа күп уйланырга юл бирмәде. Күңелле кыланып, җырлап, сөйләшеп, дуслыкны ныгытып барабыз. Дворганы үттек, Сәрдек, Пожмара, Кучким, Кырымданнарны үтеп, Заводка җиттек. Бу күңелемә берәү аркасында кәгъбә булып әверелгән авылда бик матур ике пар кыз күреп, бик матур йортлар күреп үттек. Нунәгәр дә зур, матур, күңелле авыл икән. Күңелемне тартып калды.

Гәрәйләр авылы Чутайны тыштан гына күреп үтелде. Үҗәли, Чуаллар үтәли Малмыжга җиттек. Йөреш-килеш күңелле, хатирәле булды. Яшә, Һашим!

Җизни чәй эчерде. 500 миллион акча биреп торды. Сөйләштек. Малы-нәрсәсе күп, бай булган җизни варис эзли. Малын калдырыр бер кешесе дә булмау өчен кайгырып, миңа: «Өйләнеп кил дә, бергә торыйк, варис булырсың», – дип мөрәҗәгать итте. Мөмкин булмавын, малга кызыгып хөрриятемне җуя алмавымны анык белә торып та, сөкүт белән *(дәшми торып)* өздердем. Карт җизниемне өзелгән җавабым белән борчып китәргә теләмәдем. Мәгъзур җизни, үз ирегемә йөрү алтыннан мең өлеш кадерле! Байлыгың мине кызыктырмый!

Малмыж пристаненең юлы бик күңелле аның. Кызыклы итеп бардык. Һашим бик җылап, көзге байлыкта тагы килергә чакырды. Матур сүзләр әйтте.

Пароход килмәгән дә, белмиләр дә. Никакой расписание юк. Пароход көтүчеләр бар икән, мин дә калырга булдым. Пристаньда пассажирларга урын юк. Ачык далада, җиргә әйберләрне куеп, кешеләр янына чукайдым. Һашим китәргә булгач (бер-ике сүз сызылган, укылмый – Р.Ш.), хушлашып кул бирештек. Кинәт авыр булып китте. Шодадан чыкканда да, Сәетгәрәй абзыйдан аерылганда да булмаган дәрәҗәдә йомшадым. Һашим белән гел бергә йөреп, бергә шаулап килеп тә, хәзер шыр далада япа-ялгыз, кайчан килүе билгеле булмаган пароходны көтеп торып калу бик зур әллә нәрсә кебек тоелды. Мин нәрсәләремнән бик аерылмый гына читтәнрәк кенә карап тордым. Ул арбасына утырып кузгалды. Тагы бер хуш диештек. Авырсынсам да, сер бирми, көлеп кенә исәнләштем. Шулай да горбәттә ялгыз торып калуым Һашимны борчыды бугай, аз гына атлагачтын да иелеп күзләрен басты. Шуны күрү белән мин дә җыладым.

Ул түбәтәен болгый-болгый күздән югалды; мин җылый-җылый яулык болгап тордым. Шулай итеп Һашим белән аерылу бик авыр булды. (Соңрак автор, ярты биткә аркылы, кызыл кара белән өстәп язган: «Бу битне җыртып алу турында күп уйлап тордым. Теге ягын югалтмас өчен калдырдым. Җылавымнан оялам. Хәйдәр. 1926». – Р.Ш.)

Нәрсәләрем янына утыргач та тыела алмый җылап утырдым. Бергә гөрләп килеп тә күңелсез, карарсыз җирдә ялгыз торып калу, актык туганнан да аерылу. Һашимның сөйкемле итеп аерыла белүе түзүемне алды. Урыслар белән ияләшеп, нәрсәләремне аларга ышана башлагач, шул аерылган җиргә барып, картинаны күз алдыма китереп, җылап ала-ала кич җиткердем. Һашим киткән юл күзләремә кәгъбә булып әверелде. Хуш, җегет! Хуш, идеядәш энем! Хуш, яшь крестьян! Саулыкта күрешик!

Пароход юк. Кич булгач, утыру күңелсезләнде. Эч поша, һичбер җуаныч юк. Тирәмдә җыен урыс. Ифрат җайсыз, ифрат моңлы. Бервакыт башыма чүкте. Караңгыланып күренмәс булганчы, Һашим юлына карап тордым. Аннан нәрсәләрем янына килеп утырып уйларга бирелдем.

Йокы килә. Йокласам, нәрсәләремне алырлар дип куркам. Соңга таба түзмәдем, нәрсәләремне астыма җыеп, башымны бүрәнәгә куеп йоклап-йоклап ала башладым. Пароход юк та юк.

2сендә. Черкинең талаулары астында бүлә-бүлә аз-маз черемләп кояшны чыгардым. Кояш белән бергә күтәрелдем. Торгач та Һашим юлына күз ташладым. Ул миңа горбәттә бер иптәш кебек хис ителә. Аерылып калу минутларын уйлап йомшап-йомшап алам.

Озакламый югарыдан пароход килде. Иртәгә сәгать 8дә «Внучка» атлы пароход белән газаплы Малмыж пристаненнан кузгалып киттек. Акчам җитми калыр дип куркып, второй класска гына 90 сумга билет алдым. Вяткада пароход икегә генә бүленгәнгә, второй борынгы третий урынында (бу кечкенәләрдә четвертый урынында) гына. Тар, кешеләр белән бәрелеп утырулар кызыксыз. Идәннәргә урнаштык. Монда йөрүнең әүвәл-ахыры шушы булсын дип теләдем.

Өскә менеп, Малмыж пристане күздән югалганчы карап бардым. Һашим юлы, Дилбәрләр күңелемне күбрәк биләде. Бу якта күреп үткәргән нәрсәләр, бәндәләр берәмләп уйдан кичте. Саулыклар, күрешүләр тели-тели күзләремне кәгъбәсеннән аердым.

Йомарланып ятып кына йоклаштырдым. Өскә менеп карап баргаладым. Ләкин утырган урын таза булмагач, рухланып булмый. Күңелемне ямьләрлек танышлар да чыкмады. Шулай да, йөргәндә нәрсәләремне күзәтерлек урыс танышлар ясадым. Файдаларын күрдем. Юлда һичбер уйламаган танышлар табылып, бер-береңә файдачы булып китәсең. Шунысы уңай әле.

Бер авылның ямьле дә, гармунчы да, шахтер да булган җегете генә хатирәмә бизәк булып калды. Һәрбер татар хатыны белән дә дусландык соңгарак.

Соколкига төнлә 12дә җиттек. Пароходыбыз төртелә-төртелә килде. Бер җирдә бер сәгатьтәй утырып та тордык. Су ифрат сай.

Пристаньга төшкәч, иртәгә сәгать өчсез пароход булмавын, Уфадан «Судосоюз» киләчәген белдек. Бу Ак Иделнең иң зур пароходы инде. Ләкин көтәсе күп бит. Нихәл итәсең. Тарлыкта бөршәеп, бөкләнеп йоклаган төсле итеп төн үткәрдек.

3ендә. Кәтәбез шул. Караҗиләк, кызыл бөрлегәннәр алып ашадым. Мамадышның бер кешесе белән танышып алдым. Йоклаштыргаладым. Теге җегетнең гармун уйнауларын тыңлаштырдым. Шулай үткәрелде вакыт.

«Судосоюз» вакытында килде. Торган чагымда Уфаны яратмасам да, хәзер Уфадан килгән пароходны әллә нинди итеп каршыладым. Ник, Ак Идел пароходы бит ул; Әҗәкүлдән дә үткән бит ул!..

Первый класска пласкартсыз билет алдым. (180 сум.) Берүзем бер каютага урнашып, рәхәтләнеп, рухланып алдым. Халык аз булганга, пласкартсыз билетларга да бирәр каюта җитә. Кеше булса гына, урын саен ике кеше җибәрелә.

Пароход зур гына, матур; йөреше шәп кенә. Выжлатып алга китте. Ифрат күңелле! Кузгалып китү белән калган йокыны туләргә тотындым. Яттым да тибрәнеп кенә йокладым.

Пароходның көпчәге ватылып, ике сәгать якорь салып торган, мин белмәдем, йокым нык булган.

Пароходта Уфада күрелгән кешеләр бар, ләкин минем танышлар түгел. Кич Чистайга җиттек. Пристаньнан күмәч, сөт, чияләр алдым. Бер кадак чияне авызымнан төшерми ашап рәхәтләндем. Кичке манзарада тирәне карап палубада бераз утырып бардым да ятып йокладым.

4ендә. Каманы бетереп Волгага чыктык. Кама – кап-кара булып, Волга ап-ак булып, бер-берсенә кушылмый, аерылып торалар. Бераз бер-берсенә бирелми агып баралар. Ике төрле ситсаны җалгап куйган кебек, бик кызык булып күренә.

Богородскийда кура җиләге алып ашадым. Җәйге йөрешнең бер рәхәте шулар инде. Казан байларыннан Закир Апанаев белән таныштым. Байтак сөйләшеп бардык. Шулай ук Казан мулласы һәм мөхәррире Шәһер Шәрәф белән дә утырыштым.

Читтән Казан бик матур күренә. Уфа кала мени ул...

Көндезге 3тә Казанга җиттек. 80 сумга извозчик яллап, Казанга мендем. «Гранд отель» дигән урыс номерына урнаштым. Проломныйга якын гына яңа ремонт ителгән, тыштан матур, эчтән бигрәк тә матур булган номерның суткасы 45 сумлык бер бүлмәсен алдым. Иң түбән дәрәҗәдәге саналган бүлмәм искиткеч таза, чиста, зиннәтле. Өр-яңа мәгкий мебельләр белән җыештырылган, идәннәре паркетлы. Рәхәтләнеп киттем.

> «
> **Чишендереп, бик ныклап карады. «Зур порок», – диде. Шулай да өметсез дәвергә чыкмаган. Беркадәр яхшыртырга да була. Яхшы саклaнганда бик озак яшәргә мөмкин, дип, бик куандырды. Нәрсәләрдән саклану хакында бик төпчеп, төшендереп сөйләде. Элекке саклыклар өстенә «өйләнмәү дә мәслихәтрәк»не ялгады. Үзе дә пороклы икән. Үзе кулланган даруны күрсәтеп, шул дару кушылган капляга рецепт бирде.**

Ашагач та урамга чыктым. Иң элек Галимҗан Ибраһимов, Рәмзиләрне күрергә дип Второй Дом Советовка киттем. Рәмзи юлда очрады. Ибраһимов Казанда юк, ди. Рәмзи белән дә иртәгә күрешергә булдым.

Зәйтүнә кодачаны күрү өчен Дом Советовка керсәм дә, ул да киткән икән. Аннан Гайшә абыстайларга киттем. Аларның капкасы бикле, ача да алмадым. Болар да Оренбурдадыр әле, дидем. Киттем Сәмигулла Салиховларга. Алар кичә генә Малмыжга киткән. Шулай иттереп, киткәннәр дә киткәннәр. Тинчуринга да бардым, ул да авылда.

Бер столовойга кереп котлет ашадым. Заллары матур, музыка уйнап тора. Казан – яхшы ук зур, матур, газыйм кала. Зур урамнар, биек йортлар, матур гыймарәтләр тулып ята. Шулай ук «Татарстан»лык та күзгә бәрелеп тора. Ничек тә Казанны яраттым мин.

Кич язып утырдым.

5ендә комбинатка бардым. Ибраһим Кулиев бик ачык каршылады. Шундук бүген эшемне бетереп бирергә приказ да бирде. Хәбибрахман Зәбирине дә күрдем. Договорның шартларын төзедек. Хәзер үк матбагага бирелә. Табагына алтын белән 15 сумга килешеп, 7 табакка 105 сум (9 миллиард 555 миллион) акча алдым. Саулыкта хәерен күрү насыйп булсын!

Ибраһим Кулиевтән чын-чыннан разый булдым. Аның простойлыгы, ачык һәм илтифатчанлыгы, яхшы күңеллелеге белән рәхәтләндем. Ике килешемдә дә һич җанымны кыйнамый эшемне бетерде. Казанга килеп тору хакында вәгъдәләр бирде. Башка турыларда да сөйләштек. Казандагы йөрәк авыруларына хас мәшһүр профессор Зимницкийның угылы белән таныштырып, атасына минем хакта әйтергә кушты. Сәгать 5тә барачак булдым. Шулай итеп Ибраһим Кулиев күңелем каршында фәрештә төсле тоелып калды.

Садри Җәләл белән таныштым. Ул Орскига барып кайткан икән. Рәфгатьне күргән. Ул монда артистлыкка килде.

Рәмзи артыннан Татарстан идарәсенә бардым, обкомолга бардым, юк, акылсыз. Исхаков дигән җегет белән сөйләшеп тордым. Кушай да Казанда, ди. Татнаркомпроска барам ди торгач, адашып китеп, Казанның очына барып чыктым, тәки тапмый кайтып киттем.

Столовойга кереп, пилмән ашап, зельтерский эчеп, 48 миллион түләп чыктым.

Профессор Зимницкийга бардым. Үзе каршылап алып керде. Баласы әйткән икән, фамилиямне дә онытмыйча «Фәйзи» дип эндәште. Картрак кына кеше икән. Чишендереп, бик ныклап карады. «Зур порок», – диде. Шулай да өметсез дәвергә чыкмаган. Беркадәр яхшыртырга да була. Яхшы саклганганда бик озак яшәргә мөмкин, дип, бик куандырды. Нәрсәләрдән саклану хакында бик төпчеп, төшендереп сөйләде. Элекке саклыклар өстенә «өйләнмәү дә мәслихәтрәк»не ялгады. Үзе дә пороклы икән. Үзе кулланган даруны күрсәтеп, шул дару кушылган капляга рецепт бирде. Гел эчеп торырга кушылмый, көчле нәрсә, ди. Үзе кулланганын бирергә бөтенләй курыкты. Язу эшләрем хакында да сорашты. «Син кирәкле кеше, яшәргә тиеш!» – ди. Үпкәң сау дип тә куандырды. Йөз сум бирдем. Кул биреп күреште. Озатып калды. Рухланып чыктым. Бусы өйрәнгән авыру булу өстенә, профессор да өметләндергәч: «Башка авырулардан имин булып, бусын тәрбияләп, яшәп маташыйм әле», – дип теләдем. Сау булыйм!

Кайткач булки, чия, монпансьелап чәй эчтем. Рәхәт булды.

6сында «Татарстан» идарәсенә бардым. Рәмзи* белән сөйләшеп уздым. Бу Рәмзи дигән халыкта кешелек ягы бик шәп түгелдер, ахры. Эшемне бетерер өчен Мәхмүт Максудка бәйләп куйды тагы. Обкомолда бетә торган эш булгач, нигә идарәгә китереп йөртәдер.

Шамил Усманов белән таныштырдылар. Яшь кенә җегет икән әле. Язуларым хакында тәти сүзләр әйтте. «Безнең юл» өчен биргән «Чишмә янында» дигән шигыремне укып, бик ошаттылар. «Бик көчле һәм табигый язасың», – дип, гел язарга киңәш бирде.

С.Җәләл «Безнең юл»ның секретаре икән. Язмамны кабул итеп, язып торырга нык димләде. «Ни генә җибәрсәң дә, басмый калдырмабыз», – диде. Бер данә журнал бирде.

Гәрәй Хәсәни, Ш.Шәһидуллин, М.Гали, Г.Газиз, Г.Рәхим кебек мөхәррирләр – бар да монда эшлиләр. Кайсылары белән танышмыйча гына таныштым. Кайсылары белән танышып йөрергә вакыт та булмады. Артык кызыксынмадым да.

Комбинатка бардым. Пьесаларым матбагага бирелде. Тинчурин, З.Вәлиев, Мостафиннарны күрдем. Фуад Кулиев белән күрештем. Шагыйрь Һади Такташ белән дә сөйләштем.

Әхмәт Гомәров кабинетына алып кереп, анда сөйләшеп утырдык. Конгресска дигән пьесам «Адашкан күңел»не тапшырдым. Бу Әхмәт Гомәров та минем өчен бик уңайлы кеше булып чыкты. Үзе теләп «Фәрештә» белән «Авыл бәйрәме»м өчен русча да, татарча да мөкаддимәләр язарга өстенә алды. Сәяси һәм башка яклардан тикшерәм, ди. Мин шуңа рөхсәт итеп язу бирдем. Өенә чакырган иде, бара алмам, дидем. Казанга килеп торырга тәүсыя итеп калды. Хәтта әле үзе язган пьесаларын миннән тәхлил иттермәкче *(тикшертмәкче)* була.

Бер ресторанга кереп обедать иттем дә Тинчуринга бардым. Заһидә ханымны да күрдем. Кыйраәтханәгә *(китапханә)* бардым.

Татпечать китап кибетенә барып, Шәһид Шәфигов дигән кешегә биш миллиард акчамны калдырып киттем. Иртәгә червонецка алмаштырып бирергә булды. Бу червонец дигән нәрсәкәй, акчаның бәһасен төшерми сакларга бик шәп булган лабаса.

Һәркем Казанга килергә димләде.

Урамда Нәсимә апай белән Зыяны күрдем. Ник килмәдең, диләр. Озак сөйләшеп тордым. Вакытым тар булганга, Габбасларга кадәр генә дә бара алмадым.

7сендә. Бүген сәгать 3тә китәчәк пароходка өлгерергә уйладым. Почтага барып, «Чыгам», дип, Орскига телеграмм бирдем.

Обкомолга барып Мәхмүт Максудны көттем. «Кызыл Шәрык яшьләре»ндә басылган нәрсәм өчен гонорар алдым. Исхаков белән утырдым.

М.Максуд белән таныштым. Бергә фатирына бардык. «Кызыл йолдыз»ны карап чыккан икән. Хәзер бастырырдай көчләре булмаганга, үземә ала тордым. Фикерләрен сөйләттем. Кешесе күп, ди. Хәйнең коммунистлыгы зәгыйфьрәк, ди. Байтак сөйләшеп, мөнәсәбәтне ныгытып чыктым.

Комбинатка барып, договордан копия алдым. Эшне бетереп, хушлашып чыктым. Шәфигов 5 червонец китереп бирде.

---

*Сүз журналист һәм тәрҗемәче Рәмзи (Рамазанов) Шакир Махиян улы (1898-1938) хакында бара.

Апайга бүләк итеп духи, сабын, чәй, күлмәклекләр-фәләннәр алдым. Бер җиргә кереп обедать иттем.

С.Җәләл белән очрашып сөйләштем. Бик ачык, күңелле кеше итеп таптым үзен. Казанда Ибраһим Кулиев, Әхмәт Гомәров, Садри Җәләл бик якын булып; Мөхәммәт Кулиев, Галимҗан Ибраһимов, Кәрим Тинчурин, Шамил Госманов, Ш.Шафигов җагымлы кешеләр булып күңелемә сеңделәр. Һәркем белән аз вакытта танышып, күрешеп кенә үткәнлектән, башкалар хакында хөкем итә алмыйм әле.

Мин пристаньга төшкәндә зур, дәһшәтле, матур «Красная Латвия» исемле теплоходның Самарага карап чыгуына 15 кенә минут вакыт калган иде. Чак төшеп өлгердем. Ләкин первый класска билет сатылып беткән булып, хур итте. Ирексез генә второйга алдым. Өстә бара алу бәхетеннән аерылдым.

Теплоход оча, ифрат шәп йөри. Акрынрак йөргәндә селкенгәне дә сизелми. Бөтен нәрсәсе җитеш. Буфет, парикмахер, почта, мунчалар – бар да бар. Тик каютасыз баруы гына матлубсыз булды. Второйда тыгызрак, соңлау аркасында койка да эләктерә алмый калдым. Шулай да бер урыс җегете – эшче белән дуслашып алып, ул берәүдән табып бирде. Хатыны белән бер койкага урнашты да үзенекен миңа бирде. Маладис!

Палубадан Волга буйларын тамаша итеп, теплоход белән очу, әлбәттә, күңелле инде. Пристаньнарда кура җиләге, чия, караҗиләкләр ифрат күп. Аны пристань саен алып кереп ашыйм. Җәйнең рәхәтләре белән мәнфәгатьләнеп, форсатларны качырмаска тырышам.

Сембердән төнлә үтеп, күрә алмадым.

8ендә теплоход парикмахерыннан, марҗадан, сакал кырдырдым. Буфетта ике рәт чәй эчтем.

Волга буе күренешләре артыграк матур, ахры. Бик ямьле рәвештә яратылган бормалы җирләр җаннарны рәхәтләндерә. Матурлыгына сокланып, карап туймыйм. Жигули тауларына барып тоташкан җирләрнең матурлыгын, Жигулиның ямьләрен онытырдай булмадым. Каршыма очраган зур пароходлар, теплоходларны тамаша итеп уздырып җибәрүләре дә бер зәвык.

Самараның матур дачаларын карап бару да күзгә бер бәйрәм.

Самарага сәгать өчтә җиттек. 100 сумга извозчик яллап, вокзалга киттем. Хуш, Волга! Саулыкта күрешик!

Вокзалда ыгы-зыгы. Ялгыз кешегә нәрсәләрне югалтмый билет алу бик кыен. Кесә көченә таянмый чара юк. Нәрсәләремне хранениега бирдем дә үзем билетка бардым. Кырыктан ишкән дилбегә кебек кеше касса янына тезелгән. Калган билет аз, поезд озакламый китә. Һичбер бүген китә алуымның ихтималы юк – хезмәт тәкъдим итеп йөрүченең химаясенә керми чара булмады. Кассирша белән файда уртакка кәсеп итә торган бу халык чиратсыз барып билет алды. Нәрсәләремне күтәреп вагонга бик һәйбәтләп урнаштырды. Хезмәт хакына алган 200 миллионын исәпләмәгәндә, рәп-рәхәт булды. Ләкин Самарадан Оренбурга бару 600 миллионга төште шул.

Озакламый кузгалып киттек. Классный вагонның бер койкасын биләп, рәхәтләнеп тирбәлеп йокладым. Акчаның хакы чыкты.

9ында сәгать 5тә Оренбурга җиттек. Нәрсәләремне хранениега биреп, Орски поездын белештем. Берсекөнгә сәгать иртә 6да икән. Җәяү генә калага менеп

киттем. Мәхмүтгәрәй абый өе турысыннан «үткәннәр»не уйлап узып, Харис абзыйларга бардым. Мидхәт, Җәүдәт, Шәүкәтләр дөбердәшеп каршы алдылар. Әти-әниләре Мәскәүдә икән. Балалар үрле-кырлы сикерделәр. Гаеттә бездә бул да, бездә бул, дип, тирәмдә әйләнгәләп, нишләргә белми йөриләр. Мидхәт йортның зур кешесе булып, ахиранә генә мөдир булып йөри. Чынлап та, җегет булып килә үзе. Бик матурлап чәй эчерделәр. Кымызлары бар. Бакчалары рәхәт. Пианино алганнар. Йорт-җир ике баштан шәп. Бик күңелле!

Ял итеп, бүген чыгасы итмәдем. Күңелле энеләрем белән ирмәкләндем. Җәүдәтнең гаять осталык белән пианино уйнавына кызыгып әллә ни гомер уйнатып утырдым. Мидхәт мандолина белән кушылды, әйттерәләр.

Бик матур җиһазлы бүлмәнең мамык кебек хәзерләнгән караватында ятып йокладым.

10сында. Мидхәт урогына китте. Җәүдәт рәсемнәр күрсәтте. Гомәр Хөсәеновның туган түгелмелегендә тагы шикләр туды.

Базарга чыктым. Апайга күчтәнәчләр алдым.

Өйгә кайтып чәй эчтем дә Рокыяләргә бардым. Бәхетсезлек! Рауза малярия белән авырый. Рокыя, гаеткә хәзерләнеп, пешеренеп йөри. Сара кодача шаулап килеп керде. Китмә дә китмә, дип бәйләнә дә башладылар. Бөтен сәбәпләр белән җиңелеп гаҗиз калдым. Мидхәт, Җәүдәт, Рокыя, Сараның – дүртле иттифакының – бердән һөҗүм белән самими үтенечләре каршында вөҗданым борчылды.

Вокзалга төшеп нәрсәләремнең саулыгын белештем. Киләсе поезд Куандыкка гына бара икән. Кондуктор №8гә акча калдырып, третий класска билет алып куярга куштым. Үзем поезд китәрдә генә төшәргә булдым.

Мидхәтләрдә бәйрәм ашлары белән чәйләр эчтек. Габдулла Тимушев белән таныштым. Пианинолар уйныйлар; сөйлиләр, сорыйлар; китмә, дип бәйләнәләр.

Мидхәт белән Рокыяләргә бардык. Рауза да айныган. Бераз утырып Рокыя белән өчәүләп Сараларга бардык. Китәчәгемне белдердем. Тагы бер кыстап карадылар, булмады. Озак утырдык. Сөйләштек, көлештек. Күңелле булды. Сара юл азыгы итеп тәмлекәйләр биреп җибәрде.

Кайткач, чемердәп кенә торган кымыз эчеп яттык.

11ендә. Иртүк тордык. Бәйрәм ашлары – чәк-чәк, чия ләвешләре, фәләннәр белән чәй эчтек тә, Мидхәтләр гаеткә китте, мин – вокзалга.

Беренче звонок бирелгән иде. Кондуктор билет алган. Классный вагонга кертеп урнаштырды. Орски поездына да утырдым. Бер-ике-өч кенә татар күренә. Таныш урыслар бар. Туган илгә якынлаганлык сизелеп тора.

Поезд кузгалгач, Оренбур IIне үткәч, Каргалы авылын озак тамаша итеп барып, күңелемне ямьләгәч, ятып йокладым. Шпаллар начарлык аркасында, кайсы урыннарда поезд бик акрын барып, тәмам эчне пошыра. Кыштырдап барып, җәяү төшеп йөгерердәй итә. Юл буе ауган вагоннар дәһшәт биреп тора. Крушение булмасын тагы.

Яңавыл, Утар авылы турыларын яратып карап, күңелем белән иркәләп уздым.

*Текстны басмага **Рәйсә Шәрәфиева** әзерләде.* ■

Безнең мирас №9 сентябрь 2021

Шәҗәрәбез тарихы

Әнвәр Маликов

Әдип Маликов. 1975 ел, 18 сентябрь

Җәлдәк тархан

Шәҗәрәбезнең башында торган Җәлдәк тархан якынча XV гасыр ахырында яшәгән. Аның тамырлары, Уфа белгече А.И.Ахунов раслаганча, Болгар шәһәренә барып тоташа. Әмма Ф.С.Мәрвәров фикеренчә, ул кыргыз ыруына караган Танычның улы яисә оныгы (Күккүз бинең улы) булырга тиеш. Хәер, бу ике фараз бер-берсенә каршы килми. «Башкорт ырулары тарихы»ның XIII томы Җәлдәк ыруына багышланган. Әмма Мортаза Рәхимов җитәкчелегендәге «Урал» хәйрия фонды финанслаган бу хезмәтне артык җитдигә алырга ярамый. Анда, мисал өчен, татарлар – чукынмаган чуашларның дәвамы дигән әкәмәтләргә кадәр бар…

Ахыры. Башы журналның 8 нче (2021) санында.

Җәлдәк Актаныш исемле туганы белән бергә әүвәл Агыйделнең аскы өлешенә килеп урнашкан. Яуда күрсәткән батырлыклары өчен Казан ханы аны хәзерге Борай районына (Башкортстан) кергән җир-биләмәләр белән бүләкләгән. Җәлдәк шунда авыл корган, аңа үз исемен биргән (урыс чыганакларында ул Ельдец дип күрсәтелә). Хәзер анда бушлык инде. Ерак түгел Яңа Җәлдәк (Новоельдяково, Новоельдецово) авылы гына бабабыз турындагы истәлекне саклый…

Башкорт биләмәчеләре сословиесе шул рәвешле оеша башлаган. Бу төшенчә турында Татарстан белән Башкортстанның аерым тарихчылары арасындагы бәхәснең тынганы юк. Кемдер «башкорт» сүзен, география-сословие термины, ди. Кемдер, моңа каршы килеп, этноним дип атый. Варислар теге яисә бу туфракка хокуклары булуын урыс хакимиятенә еш кына шәҗәрәләр ярдәмендә раслаганнар. Шәҗәрәләр нигә ул якларда аерата таралган соң? Минемчә, моның нигезендә хәзерге Башкортстан җирләренең тыныч юл, үз ирке белән урыс дәүләтенә керүе, нәтиҗәдә, көнбатыш кардәшләреннән аермалы, бик күп өстенлекләрне саклап калуы ятадыр. Казан ягын канга батырганнан соң, башка халыкларны буйсындыру эшендә Мәскәүнең сәясәте үзгәрә.

Төбәкне өйрәнүче Назыйм Моратов (үзе Чакмагыштан) мәгълүматларына караганда, Җәлдәкнең алты улы булган: Ябынчы-би («би» – биләмәгә ия булуны белдерә), Атлак-би, Бису-би, Кункай, Байгилде, Аккош-би.

Борай мирасы

Атлак-би, Корбан-би, Җаргази бабаларыбыз турында бернинди мәгълүмат сакланмаган. Ә менә Борай Ергозин (Җаргазин) мәгълүм зат. Аның исемен йөрткән авыл бүген Башкортстандагы район үзәкләренең берсе.

Борайның Мәккәгә хаҗ кылуы билгеле. Аннары ул Казанга киткән һәм 1600 елда шунда вафат булган. Балалары ватаннарында, төп нигездә калганнар. Мәскәүдәге Борынгы актлар архивында Борайга җир бирү турындагы документлар саклана. Берьюлы Борайның торыннары биләмә хокукы буенча үз җирләрен яклап кала алган. Бу хакта бик кызыклы акт бар. Эш шунда ки: 1714 елда Елан (Ваныш) һәм Җәлдәк вулыслары – олыслары (Танып елгасы буйлап Әҗәк суыннан Себергәнгә кадәр) вәкилләре арасында бәхәс купкан. Хакимияткә үтенеч хаты язганнар. Тикшеренү нәтиҗәсендә шунысы расланган: Борайның торыны Әкъмир Әсәнов «с товарыщами из Ельдякской волости владели дедовскою вотчиною по Таныпу реке». Әмма җирле халык баш күтәргәннән соң, бу биләмәне «Карашай Урахчин с тов. насильно» кулга төшерә. Документта Борайның фетнәгә кадәр биләмәгә ия булуы, аннары Уфа өязеннән Казанга күченүе, шунда җан тәслим кылуы бәян ителә. Балалары беркая да күченмәгән. *«А их деды Мусайкин де Мурзагул, Якушкин дед новокрещен Стенька; а после де дедов остались отцы их (Яшпулат и Исай) и они Мусайко и Якушко з братьями, и после смерти прадедов, и дедов, и отцов их, у тое вотчину прадеда их Бурая, владели насильством бес крепостей башкирцы Сава да Татлыбай Кокбашевы с товарыщи с прежние башкирские шатости по 205-й (1697) год»*. Нәтиҗәдә Мусайка Яшпулатов һәм чукындырылган Якушка Исаев биләмәнең хуҗалары итеп танылганнар: *«по урочищам по Таныпу реке з бортными угодьи, и звериными и рыбными ловлями, с озеры и с ыстоки с верхние межи речка Азякер, с устья наниз по Таныпу до речки Сибиргенского устья*

по левую сторону со иркою и со аремами... К сей владеной выписи великого государя царя и великого князя Петра Алексеевича печать Уфинского города камендант Андрей Михайловичь Колычов приложил».

Күренгәнчә, шәҗәрәләр җентекләп тикшерелгән. Шуңа күрә дә аларның дөреслегенә карата бернинди шик-шөбһә була алмый. Документта бәхәсле җирнең иманасы да аермачык күрсәтелгән: *«...с тое вотчины платили ясаку по 15 куниц да по 2 батмана меду на год».* Батман – агач чиләк, элекке заманда үлчәү берәмлеге булып торган. Аңа 10 фунт, хәзергечә әйтсәк, 4 килограмм бал сыйган.

1864 елда Борай авылы вулыс үзәгенә әйләнгән. 1870 елда биредә 4 мәчет, 5 училище, 4 тегермән, 40 кибет (лавка) эшләгән. Сишәмбе көннәрендә – базар, 20-27 нче декабрьләрдә ярминкә гөрләгән. XIX гасыр ахырында хәтта шәхси китап кибете дә ачылган.

Борайның улы Морзагол Бораев һәм оныгы Кадергол Морзаголов турында мәгълүмат таба алмадым. Ә менә Дүсмәт Кадерголовның Борайдан 5 чакрым ераклыкта Дүсмәт авылына нигез салуын беләм. Шулай ук Дүсмәт белән Уразның 1741 елда Ураз авылында яшәве билгеле. Елан вулысыннан булган көндәшләре, боларның биләмәләрен үзләштерергә теләп, ике туганны Казан өязеннән чыккан затлар, дип, нахак сүз тараткан. Әмма шәҗәрә ярдәмендә дәгъвачы Карашай Ураксинның ялганы фаш ителгән, Дүсмәт белән Уразның Борай торыннары булуы расланган. Аларның әтисе – Кадергол Морзагол улы. Морзагол – Борай улы.

Салават Юлаевның көрәштәше

Биләмә хокукын кысрыклауга каршы күтәрелгән фетнәләрдән соң, хакимият бу тынгысыз һәм каласыз-кирмәнсез җирләрдә форпостлар торгызу эшенә керешкән. Рәсми «донесение»ләргә ышансаң, 1737 елда биредә «...построено и строить зачато 18 городов и городков, в том числе в нескольких живут». Уфа, Бөре, Табын, Җәлдәк һәм Нагайбәк кирмәннәре корылган. *«Елдятская крепость на Сибирской дороге на р. Уфа, между гор, от г. Уфы – 160, а от Оренбурга 493 версты. Она построена при статском советнике Кирилове в 1735 году. Звание ее происходит от Башкирской Ельдятской волости; ибо стоит на земле той волости башкирцев. Гарнизону в ней ныне половины роты пехотной да служивых казаков 100 человек; жительства дворов со 100; церковь во имя Нерукотворного образа Спаса; укреплена с наружной стороны оплотом».*

Күсәпкол һәм Морзагол турында да мәгълүмат юк.

Чираттагысы – Сабанак. Мондый исем чәчү вакытында туган малайларга бирелгән. Сабанак 1773-1775 нче елларда Емельян Пугачев җитәкләгән восстаниедә Салават Юлаев белән иңгә-иң көрәшкән, 1773 елның сентябрендә Җәлдәк кирмәнен яулап алуда катнашкан. Бер елдан соң, 18 һәм 22 нче сентябрьләрдә, Борайдан ерак түгел Тимешкә авылы янында, Танып һәм Бөре елгалары арасында, подполковник Иван Рылеев сугышчылары һәм Сабанак җитәкләгән баш күтәрүчеләр арасында орыш булган. 25 сентябрьдә патша гаскәрләре кирмәнне яңадан үз кулларына төшергән. Сабанак сөргенгә озатылган.

Шимогол Сабанаков – мулла. Аңардан башланган Сабанаковлар фамилиясе ары таба буыннан-буынга күчкән. Күсәпкол Сабанаков – мулла, мөгаллим. 1787 елда яисә 1790 елда туган, 1838 елда бакыйлыкка күчкән. Беренче хатыны – Шәһәрвафа Зәйнуллина (1787 елгы), икенчесе – Бәдигыльҗамал Балтаголова (1799 елгы). Реви-

зия (салым түләргә тиешле халыкның җан исәбен алу) мәгълүматларына караганда, Бөре өязенең Акбулат авылында (хәзерге Тәтешле районындагы Иске Акбулат авылы) яшәгән, 1816 елда аңа 29 яшь булган.

Нурмөхәммәт Сабанаков (1824-1871) элгәре – Дүсмәт, аннары Югары Чат авылына указлы мулла итеп билгеләнгән. Дүсмәт авылына караган 1850 елгы ревизиядә мондый җөмлә бар: *«Кусяпкула Собанакова 4-й сын, указной мулла Нурмухамет, 25 лет»*. 1859 елның июнендә узган ревизиядә аның шул ук вазыйфада Югары Чатка күченүе турында язылган. Бераз соңрак Нурмөхәммәтнең ике хатыны, биш улы (өлкәненә – 5 яшь, кечесенә – 5 көн) һәм ике кызы теркәлгән. Хатыннары – Фәрхисорур Сәхибкамалова һәм Хәбибҗамал Гыймалтдинова. Уллары – Габдерахман, Нуретдин, Тәкыйулла, Сафиулла, Әсман. Габдерахман бабам соңрак, 1862 елда туган.

Күренгәнчә, нәселебезнең ким дигәндә өч буын ир-атлары указлы мулла вазыйфасын башкарган. Ул вакытта бу гыйлем ияләре авылда бик мәртәбәле урын тоткан: алар мәгърифәтче, мөгаллим, киңәш-табышчы, табиб һәм хәтта казый хезмәтен дә үтәгән.

Сөнниләрдә әүвәл белемле һәркем муллалык итә алган, үзе халык белән бергә яшәгән, эшләгән. Әмма Әби патша заманында дәүләт мөселманнарны эзәрлекләүдән туктаган һәм шуның белән, әлбәттә, үзенә карата ихтирам казанган. 1788 елның 22 сентябрендә имзаланган Указ нигезендә Уфада Мөселман диния нәзарәте оештырылган, мәчетләр төзергә рөхсәт бирелгән. Мәхәллә халкы сайлаган руханилар Нәзарәткә барып имтихан тотарга тиеш булган. Шуннан соң губерна идарәсе император исеменнән указ чыгарып, руханиларны теге яисә бу мәчеткә тәгаенләгән. Нәтиҗәдә, «рәсми булмаган» абызларны «указлы» муллалар алыштырган. Алар метрикә кенәгәләрен тутырган, халыкка хакимият сүзен җиткергән. Алай да рәсми статуска ия булмаганнар, дәүләттән һичбер матди ярдәм алмаганнар, мәхәллә хисабына көн иткәннәр. Җир һәм ярдәмче хуҗалык өстәмә керем чыганагы булып торган. Чакырылган муллаларга мәхәллә тарафыннан җир фәкать вазыйфа биләгән вакытка гына бирелгән. Империя, указлар кабул итүдән тыш, мөселманнарның эчке эшләренә тыкшынмаган. Указда, гадәттә, муллаларның мөгаллимлеге дә искәртелгән. Инкыйлабка кадәрге Россиядә нәкъ менә алар балаларга гыйлем-тәрбия биргән, ягъни «обучали магометанскому закону, татарской грамоте, читать, писать и арифметике». Мөселман мәктәп-мәдрәсәләре шәхси акчаларга тотылган. Мәхәллә халкының хәллерәге еш кына мәчет биналарының хуҗасы да булып торган. Мәзин (азанчы) өч төп вазыйфа башкарган: халыкны җыйган, имамны чакырган һәм гыйбадәт башлануын игълан иткән. Күп вакытта бу эш авылның гыйлемлерәк кешесенә тапшырылган. Кайбер документларда алар, нәсара руханиларына бәрабәр рәвештә, «пономарь» дип күрсәтелгән.

Остаз, мөгаллим, табиб

Гарифулла Нурмөхәммәтов (1862-1935) 9 яшендә ятим калган. Борайда дини белем алган. Мулла урыны буш булмагач, туган авылы Югары Чатта мәзин булып хезмәт куйган. 1917 елгы авыл хуҗалыгы җанисәбе документларында биләмәче (вотчинник) итеп күрсәтелгән. Кызылъяр җәмгыятеннән арендага 21 дисәтинә (бер дисәтинә – якынча 1,1 гектар) сөрүлек алып эшкәрткән: бәрәңге утырткан, иген чәчкән. Хуҗалыгында 3 ат, 2 сыер һәм 2 бозау, 4 сарык һәм 3 бәрән асраган. Аның белән бергә 50 яшьлек хатыны Гыйльмикифия, 27 яшьлек улы (Малик бабабыз бу-

Гарифулла Коръәне

лырга охшаган, гәрчә ул 1888 елда туса да), 21, 17, 12 һәм 7 яшьлек кызлары яшәгән: Мөнәвәрә (1896 елгы), Шәмгыйзия (1900-1935), Бәхиҗә (1906-1998), Фәүзия (1911 елгы). Җәмгысе 12 бала тәрбияләгән. Халык хәтерендә Гарифулла гаять эчкерсез кеше, зирәк киңәшче, остаз булып сакланган. Дару үләннәре җыйган, кешеләрне дәвалаган, ярлы-ябагага ярдәм иткән. Авыл аркылы узган юлчыларны ул үз табынына чакырып, туганнарыдай якын күреп, сыйлап-кадерләп озаткан. Хатыны, усал Гыйльмикифия (гади итеп әйткәндә, Кифая), бу юмартлыгың белән гаиләне ыштансыз калдырырсың әле, дип, аны еш кына әрли торган булган. Җөмләдән, Кифая – Шәрифҗанның бертуган сеңлесе. Шәрифҗан исә – Татарстанның халык шагыйре Илдар Юзеев белән филология фәннәре докторы, профессор Нил Юзеевның бабасы.

Ватандашлар (Гражданнар) сугышы чорында, авылга әле аклар, әле кызыллар бәреп кергәндә, яшәп торыр өчен тегесе дә, бусы да Гарифулланың мәһабәт йортын сайлаган. Ул барчасын да тигез күреп каршыларга тырышкан. Әмма Кифаянең сүзләренә караганда (ул бу хакта кызларына сөйләгән), аклар үзен тыйнаграк тоткан, хуҗалар күрсәткән сый-хөрмәткә канәгать булып, рәхмәт әйтә белгән. Кызыллар исә ни ашарга теләүләрен үзләре ярып салган, хуҗаларның мал суюын таләп иткән.

Күмәкләштерү елларында Гарифулла бар милкеннән коры калган, йортыннан куылган. Бушаган бинада соңрак Авыл Советы урнашкан. Бабам гаиләсе белән Югары Чат читендәге иске мунчага күченгән. Берәр елдан соң, авылдашлары соравы буенча, аңа яңадан үз йортына кайтырга рөхсәт бирелгән. Әмма Гарифулла, кайбер кемсәләрнең рәхимсезлеген һәм үзенең шулай мәсхәрәләнүен кичерә алмыйча,

Дүсмәткә чыгып китәргә карар кылган. Югары Чат янындагы Алма-Тау (юкка чыккан авыл) зиратында җирләнгән.

Гарифулланың Габдерахман исемле бертуганы булган. Габдерахманның балалары – Лотферахман Сабанаков (1885-1965), Җәмилә (1891-?), Васфирахман (1896-1928) Алма-Тау (1965 елда юкка чыккан), Сабанчы (1988 елда юкка чыккан), Көрәш (шулай ук юкка чыккан) авылларыннан коммуна төзегәннәр. 1931 елга кадәр Лотферахман аның рәисе булып торган, аннары Тәтешле райкомының секретаре вазыйфасына күчерелгән. Коммуна соңрак Сабанаков исемендәге кумәк хуҗалыкка үзгәртелгән.

Бездә Гарифулла мәзиннең төсе булып Коръән саклана. Тузган китап та, хуҗасы кебек үк, шактый кыенлыклар күргәнгә охшый. Тышлыгы яңартылган, җитмәгән фрагментлар төрле-төрле кешеләрнең кулы белән өстәп язылган. Китап читенә соңгы тапкыр теркәлгән сүзләр: *«1959 елда 20 үктәбер бу Кәлямшәрифне төзәтдем. Мөнәвәрә Гарифулла кызы»*. Милли китапханәнең сирәк һәм кульязма китаплар бүлеге җитәкчесе Айрат Заһидуллин фикеренчә, бу фолинат XIX гасырның ахыргы чирегендә Казан император университеты типографиясендә басылган булырга тиеш. Коръән нәшер итү ул заманда бик керемле һөнәр саналган. Инкыйлабка кадәр чыккан һәм әлегәчә яхшы хәлдә сакланган изге китапларны табу гаять кыен, битләре купкан, үзләре ертык, ут һәм су орынган урыннары да шактый, ди ул.

Безнең фамилия

Гарифулланың улы Малик 1888 елда Югары Чат авылында туган. Данлыклы «Галия» мәдрәсәсендә белем эстәгәндә Мәҗит Гафури, Шәехзадә Бабич, Галимҗан Ибраһимов, Сәйфи Кудашлар белән танышкан. Шундый кешенең үз улына Әдип исемен кушуы гаҗәпмени?!

Мәдрәсәне тәмамлагач та, Малик казакъ һәм кыргыз далаларын иңләгән, балаларны чатырга җыеп, бармак белән санарга, исемнәрен язарга өйрәткән. Аннары Кытайга җитеп, Чөчәк шәһәрендә уйгырларга гыйлем тараткан.

Совет хакимияте урнашканнан соң гына туган авылына кайткан, бер-бер артлы алышына барган гарәп, латин (яңалиф) һәм кирилл хәрефләрендә татар телен, татар әдәбиятын укыткан. 1934 елда аны Аксәет авылына (хәзерге Тәтешле районы) мөгаллимлек итәргә җибәргәннәр. Ул гомер буе шунда яшәгән.

Хатыны – мулла кызы Рауза Бускина белән бергә Малик 9 бала тәрбияләп үстергән (алардан тыш өчесе сабый чакта үлгән). Барысы да югары белем алуга ирешкәннәр.

Иң өлкәннәре – Әдип – кечкенәдән әдәбиятка тартылган, мәктәпкә кергәнче үк журналлар, газеталар, китаплар укыган. Аның үсмер һәм егет чакларында латин имласы белән язылган шигырь дәфтәрләре әле дә саклана. Күренгәнчә, әтисе аңа очраклы исем кушмаган.

Алга таба, совет хакимиятенең беренче елларына хас булганча, фамилия мәсьәләсе безнең гаиләдә дә буталып беткән. Патша заманында, аксөякләрдән кала, татарлар фамилиясез йөргән дип санала. Мин моның белән килешмәс идем. Чөнки инкыйлабка кадәр тутырылган җанисәп документлары киресен раслый. Дөрес, соңгырак чорда татарларга фамилияне әтисе исемен үзгәртеп куша башлаганнар. Югыйсә XVIII гасырдан алып без Сабанаковлар булырга да мөмкин идек. Маликның бертуган Мөнәвәрә апасы шул фамилияне йөрткән бит.

Әти паспорт алганчы һәркайда Гарифуллин дип барган. Аннары кинәт кенә Маликовка үзгәргән. Бу хәл хәтта аның үзен дә гаҗәпсеткән. Энекәшләре Гарифуллин булып калганнар. Әмма мин бу үзгәрешкә үкенмим, фамилиябез бик ошый. ■

Безнең мирас №9 сентябрь 2021

«Әтрәч укулары»нда Туфан Миңнуллинны искә алдылар

Быел 13 июньдә Тәтеш җирендә узган XV «Әтрәч укулары»нда Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе ректоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин, Тәтеш муниципаль район хакимияте башлыгы Рәмис Хатыйп улы Сафиуллов, Бөтендөнья татар конгрессының Казан бүлеге җитәкчесе Фәрит хаҗи Мифтахов, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон, «Ак калфак» Бөтендөнья татар хатын-кызлар иҗтимагый оешмасының Тәтеш бүлеге җитәкчесе Рима Сафиуллова, Тәтештәге милли оешма җитәкчесе Асия Ибраһимова, галим-агроном Харис Камалиев, Җәмил хәзрәт Маннанов, Данил хәзрәт Җиһаншин, Гыйльфан хәзрәт Гыймадиев (Апас), «Авангард» газетасы хезмәткәрләре һәм башкалар катнашты.

«Әтрәч укулары»н Тәтеш районы мөхтәсибе Инсаф хәзрәт Җәләлетдинов ачты. 2009 елда үзе откан грант акчасына Изгеләр зиратын тимер рәшәткәләр белән әйләндереп алырга ярдәм иткән, Зур Әтрәч авылындагы укуларны рәсмиләштерүгә күп көч куйган Татарстанның халык язучысы Туфан ага Миңнуллин һәм башка әрвахлар рухына дога кылынды.

Тәтеш муниципаль район хакимияте башлыгы Рәмис Сафиуллов, Изге Әтрәч җиренең тарихыбызны, мәдәниятебезне саклауда тоткан урыны хакында сөйләгәннән соң, чараны оештыручыларга үз исеменнән Рәхмәт хатлары тапшырды.

Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе ректоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин чарада катнашучыларга дини мирасның кыйммәте хакында сөйләде. Тарихи җирлеккә сакчыл караш кирәклеген искәртеп, ул «Ак калфак» Бөтендөнья татар хатын-кызлар иҗтимагый оешмасының Тәтеш бүлеге җитәкчесе Рима Сафиулловага Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Камил хәзрәт Сәмигуллин исеменнән Рәхмәт хатын тапшырды.

БТКның Казан бүлеге җитәкчесе Фәрит хаҗи Мифтахов кунакларны Бөтендөнья татар конгрессы исеменнән сәламләде. Шулай ук ул татар халкының үсеше өчен саллы хезмәт куйган Кече Әтрәч мәдәният йорты директоры Хәлил Мәгъсүмовны һәм «Нур» агрофирмасы җитәкчесе Радик Нургалиевны конгрессның «Бердәмлек» медале белән бүләкләде.

«Әтрәч укулары»нда катнашучылар, соңыннан «Изгеләр чишмәсе»ндә булып, әтрәчлеләрнең сый-нигъмәтеннән авыз иттеләр, бергәләп истәлеккә фотога төштеләр.

«Әтрәч укулары»на нигез салучыларның берсе, төбәкне өйрәнүче Мөнир ага Вәлиев (заманында мәктәптә 45 ел физика, математика һәм химия фәннәрен укыткан, директор урынбасары вазыйфасын башкарган) Болгар бабаларыбыздан калган тарихи мирасны саклап, түкми-чәчми киләчәк буыннарга тапшырырга чакырды.

Мөнир Вәлиев, төбәк тарихын өйрәнүче, 2009 елда «Әтрәч укулары»н оештырып җибәрүче:

– Зур Әтрәч – бик борынгы авыл. Ул өч чорны колачлый: протоболгар чоры, болгар чоры һәм монгол чоры. 1552 елдан Әтрәч башка тарих белән яшәп китә. Без, көчебез җиткәнчә, авыл тарихында казындык. Чынлап та, безнең эрага кадәр үк шушы урында кешеләр яшәгән дияргә җирлек бар. Авылның борынгы исеме Әтрәч түгел, ә Мең Өйле Шонгат. Аның исеме елга белән бәйле – Үләмә елгасы кушылдыгында Шонгат елгасы башлана. Шәһәрне шушы елга исеме белән йөрткәннәр. Аның Биләр һәм Болгарга караганда да зуррак икәнлеге билгеле – 6 мең 500 йорты булган.

Әтрәч исеменең килеп чыгышы Болгар тарихы белән бәйле. Әтрәч – тәхәллүс. Болгарлар, сәрбиләр белән бергә, Төркиягә каршы сугыш алып баралар. Нәтиҗәдә, Истамбул шәһәрен алалар. Истамбулдан ерак түгел Әтрәч исемле тау була. Менә шул тау итәгендә безнең борынгы бабаларыбыз җиңүне бәйрәм итә. Аннан кайткан сугышчылар бу исемне үзләре белән туган якларына алып кайта.

Татарстан Республикасы Милли музеенда Әтрәч кырларыннан табылган 48 меңнән артык акча бар. Тик, ни кызганыч, алар хәзерге көнгә кадәр җентекләп өйрәнелмәгән. Шулай да шунысын тәгаен әйтә алабыз: бу җирләрне монгол яулары тар-мар иткәнче, биредә акча сугылган.

(Өземтә журналист Руфия Фазылованың «Татарстан» журналында (№8, 2020) басылган язмасыннан алынды.)

Л.Лерон һәм Ф.Мифтахов фотолары файдаланылды. ■

Безнең мирас №9 сентябрь 2021

«Сары умырзаая эзләдем»

Мөнир Вәлиев

Зур Әтрәч мәдәният йортында Роза апа Фәйзуллинаның иҗат бәйрәме

Табигать күренешләре белән кешенең гомер мизгелләре арасында бәйләнеш бар, диләр. Әлеге сүзләрнең хаклыгына икеләнергә мөмкин түгел. Таң ату, яңа көн тууны – кеше туу белән, ә кояш батышын, төн җитүне кешенең үлеме белән чагыштырып була дигән сүзләрне халык арасында еш ишетергә туры килә. Адәм баласының фани дөньядан бакыйлыкка – мәңгелеккә күчүе күп очракта таң алдыннан яки кояш баеганнан соң була.

2021 елның 5 июль таңында Зур һәм Кече Әтрәч халкы өчен Тәтеш хастаханәсеннән килгән хәбәрне аяз көнне яшен сугу белән тиңләп була иде. Күңел ышанмый, исәндер ул, булуы мөмкин түгел кебек уйлар һәрберебезнең күңелен борчыды. Могҗиза көтсәк тә, кайгылы хәбәр дөрес булып чыкты. Авылларыбызның киләчәген кайгыртып, милләтебезнең гореф-гадәтләрен, мәдәниятен, тарихын һәм динен саклауга күп көч куйган җирле шагыйрәбез, Ак әби дәрәҗәсенә ирешкән җәмәгать эшлеклесе Роза Габделнур кызы Фәйзуллина бакый дөньяга күчте…

Тәтеш һәм күрше-тирә районнарда аны яхшы белсәләр дә, башка төбәк кешеләре белмәскә мөмкин. Сүземне 2010 елда Роза апаның «Гөл сагышы» дигән шигырьләр җыентыгында үз кулы белән язган биографиясеннән өземтәләр

белән башлап җибәрергә телим: *«Мин 1943 елның гыйнварында элек Апас районына кергән (хәзер Тәтеш районы) Кече Әтрәч авылында туганмын. Әнием Разыя – Апас районындагы Кече Тормыдан Ногманов Камәретдин кызы. Әтием – Апас районындагы Кече Әтрәчтән Габдрахманов Габделнур Габдрахман улы. Алар 1928 елда гаилә корган. Озак та үтми, бәхетне Донбас якларында табарга өмет итеп, туган авылларыннан читкә чыгып киткәннәр...*

Әтием Габделнур шахтер булып күмер чаба башлый. Сугыш башланыр алдыннан гына, әти эшли торган шахтада зур авария була, байтак күмер чабучы һәлак була. 2 нче группа инвалидлык алган әтием тагын юллар чатында кала. Көнбатыштан коралланган Фашист Германиясе армиясе менә-менә сугыш башларга тора. Әни белән ныклы фикергә килеп, яңадан Кече Әтрәчкә кайтырга карар кыла алар...»

Илдә чыпчык үлми, ди халык... Габделнур ага тормыш иптәше һәм өч баласы белән туган авылларына кайта. Нахакка рәнҗетелгән Хәмит абый һәм Хәлимә апалар (атаклы дирижер Фоат ага Әбүбәкеровның әти-әнисе) торган өйне сатып алалар. «Туасы бала туачак» дигән әйтем бар. Өч бала янына тагын икәү өстәлә: Роза һәм аның сеңлесе Динә.

Шулай итеп, 1943 елның 24 гыйнварында Роза, әти-әнисен шатландырып, дөньяга аваз сала. Салкыннан да, сугыштан да, тормыш авырлыгыннан да курыкмаган ул. Роза апа сөйләшеп утырганда еш кына, балачагым авыр елларга туры килсә дә, үсмер, яшьлек елларымда искә алырдай матур, сөенечле мизгелләр дә күп булды, дип, шул хакта сөйләп ала. Зур Әтрәчтә җидееллык мәктәпне тәмамлагач, укырга теләге бик зур булса да, гаилә хәленең авыр булуы аркасында, туган авылындагы кошчылык фермасына эшкә килә ул. Кечкенәдән эш белән чыныгып үскән Роза апа бер генә эштән дә чирканмый, һәр хезмәтен сыйфатлы, ялт итеп, үз вакытында эшләп куя. 1964 елда Зур Әтрәчтә туып-үскән киң профильле механизатор, соңрак шофер Ислам Фәйзуллинга кияүгә чыга. Пешекче, КБО җитәкчесе һәм хат ташучы да булып эшли. Гаиләдә 7 бала туа. Һәрберсенә белем биреп, олы тормыш юлына озаталар. Балаларының дүртесе – Мәскәүдә, икесе – Казанда, ә төпчек уллары Инсаф, гаилә корып, туган нигезендә яши.

Шунысы гаҗәп: динебездә адәм баласының гомер дәфтәре дүрт ай да ун көндә тутырылып бетә дигән мәгълүмат бар. Хәтер күзәнәкләренә Бөек Аллаһ тарафыннан бик күп мәгълүмат салынып куелган. Кайбер кешеләрдә сәләт балачактан ук ачыла башлый, ә кемнәрдәдер ул гомер көзендә генә ачылып китеп, могҗизалар тудырырга мөмкин. Мәрхүмә, хәзер бакыйлыкка күчкән хөрмәт иясе Роза апабызның да сәләте гомеренең көзендә генә ачылган дип уйлыйм. (Дөрес, бу минем шәхси фикерем, әмма аны якыннан белгән кешеләр барысы да бу фикергә кушылыр дип уйлыйм.)

Милләте, халкы һәм авылының язмышы өчен янып-көйгән Роза апаны тасвирлап бирү өчен мәгънәле матур сүзләр табу да бик читен, чөнки моның өчен югары белемле психолог та, филолог та булырга кирәк. Хәзерге вакытта волонтер дигән сүз киң кулланышка кереп китте. Менә аны киң профильле волонтер дип искә алыр идем. Үзлегеннән Коръәнне өйрәнеп, аны авылдашларына, балаларга, мөслимәләргә укытып, ике Әтрәч халкы өчен дә күркәм абыстайга әверелде ул. Кәфенлек тә кисә, «Ясин» да чыга, Коръән мәҗлесләрен үткәрергә дә өлгерә иде Роза апа. Ул 2006 елда районыбызда беренчеләрдән булып «Мөслимәләр» оешмасын төзеде һәм аны җитәкләде. Ире Ислам Гарифулла улы Зур Әтрәч мәчетенең имамы булып эшләде. Алар, бер-берсенә терәк булып, авылдашларын аң-белемле итү юлында армый-талмый хезмәт куйдылар.

Мин Роза апаның шигырьләр язуы хакында көтмәгәндә генә белдем. Бервакыт ул: «Мөнир, минем бер гозерем бар иде», – диде дә кулыма берничә дәфтәрдән торган төргәк китереп тоттырды. Кыяр-кыймас кына: «Шуларны бастырып чыгарырга булышсаң, «Әтрәч укулары»на килүчеләргә таратыр идек», – дип сүзен тәмамлады. Саллы гына шигырьләр җыентыгын якташларым Ильяс һәм Хәйдәр хәзрәтләрнең ярдәме белән мәдрәсәнең типографиясендә бастырып чыгардык. Мәрхүмә, сүзендә торып, игелеклелеген раслап, китапны бәйрәмдә таратты. Кайвакыт үзенә дә: «Роза апа, югары белемең булса, син нинди дәрәҗәләргә ирешкән булыр идең!» – дип әйткәч: «Кем белә инде аны, теләгем бар иде, әмма тормышка ашмады. Мин генә түгел, башкалар да шундый шартларда яшәде бит, уфтанмыйм. Шуны гына әйтә алам: тормыш гөлем Исламның тугрылыклы хатыны, балаларымның әнисе, оныкларымның дәү әнисе булган булыр идем», – дип шаяртып, туры җавап белән шома гына качып кала иде... Роза апа дуслары, туганнары һәм иганәче Рима Гомәр кызы Сафиуллова ярдәме белән саллы китаплар бастырып чыгарырга өлгерде. Аның 20дән артык шигыренә җыр язылды. Роза апа Дамир Фәезханов, Фоат Әбүбәкеров, Фәридә Фәйзуллина, Сания Гарифуллина һәм җырчы-композитор Вил Усманов кебек танылган шәхесләр белән дә уңышлы гына эшләде.

Ә җәмәгать эшендә, төрле чаралар үткәргәндә аңа тиңнәр булмады. Чын әйдаман булып, һәр эшен җиренә җиткереп башкарып чыга иде Роза апа. 15 ел буе үзен аямыйча эшләү дә сәламәтлегенә зыян салгандыр инде... Ләкин зарланырга яратмый торган шәхес булып башкалардан аерылып тора иде ул. Гомер көзенең соңгы этабындагы үзгәрешләрне аның эшчәнлегеннән, характерыннан һәм йөзендәге хәсрәт чагылышларыннан белеп була иде. Нәтиҗәләр ясау өчен, яраткан оныгы фаҗигале рәвештә суга батып үлгәч язылган шигыреннән өзек китерү урынлы булыр:

«Язлар җиткәч, су буена төштем,
Сары умырзая эзләдем.
Болай да бит аның гомере кыска,
Сындырмадым аны, өзмәдем.

Кушымта:

Умырзая тик бер сылтау,
Су буеннан сине эзләдем.
Умырзая кебек иртә сулдың,
Әрнеп өзгәләнә үзәгем».

(«Өзелгәндер йөрәк бәгырьдән». Фоат Әбүбәкеров көе.)

Менә яраткан әнисе вафат булгач язган җыр тексты:

«Хәер-фатыйхаңны бирдең миңа,
Балам, диеп, барын кичереп.
Синең алда булган бурычларны,
Буламы соң түләп бетереп».

Кушымта:

Газиз әнием! Синең фатыйхаңа
Таянам мин, кайда йөрсәм дә.
Үзең күңелемнең түрләрендә,
Ә рәсемең куен кесәмдә».

Кече Әтрәч мәдәният йортында иҗат кичәсе



Роза апа Фәйзуллина «Әтрәч укулары»нда яңа шигырен укый

Көннәрдән беркөнне Роза апа миңа: «Шәҗәрә төзү уе белән йөрим әле, башлап карадым да туктап калдым, ярдәм кирәк иде. Тагы сиңа килдем инде, болай да эшең тыгыз», – дип, кыенсынып кына мөрәҗәгать итте. «Тиешле белгечләр белән сөйләшеп карармын әле, бәлки, башкарып чыга алырмын», – дип, хәл кадәренчә тынычландырдым аны. Ниһаять, Роза апаның кулына әтисе белән әнисе ягыннан 7 буын бабаларының исемнәре язылган «нәсел агачы»н тапшырдым. Район һәм төбәктә узган шәҗәрә конкурсларында 1 һәм 2 нче урыннар алып уңышка иреште ул алар белән. «Гомерем булса, Ислам абыең ягыннан да нәсел шәҗәрәбезне ясатам әле, пенсия түлиләр ич», – дип, планнар да корып яшәде.

Роза апа бик матур киенә иде, башкаларга да гаять игътибарлы булды. «Бигрәк тә матур бит борынгы бабаларыбызның каракүл бүрекләре! Кайдан гына алып була икән аларны?» – дип уйланып йөргән Роза апа теләгенә ирешә бит! 4 ир баласына, яраткан иренә һәм киявенә каракүл бүрекләр бүләк итте.

Кызганыч, ике Әтрәч күгендә якты йолдыз булып янган Роза ханым бүген безнең арада юк инде. Ире Ислам абыйга, яраткан улы Исхак язган җырның бер куплетын истә тотып, төшенкелеккә бирелмичә, безнең арада озак яшәргә насыйп әйләсен иде:

«Ялгызларның җыры моңлы була,
Ялгыз хәлен белми парлылар.
Яраланган гөлләр иртә шиңә,
Шуңа микән бераз зарлылар».
(«Ялгыз калмагыз!»)

Аллаһы Тәгалә аның балаларына, оныкларына һәм күпсанлы туганнарына сабыр, бердәм булып, авыр кайгыларга бирешмичә яшәргә насыйп әйләсен. Раббыбыз кылган изгелекләрен, биргән сәдакаларын, укыган намазларын кабул итеп, Роза апага җәннәт капкасын ачып керергә язсын. Хуш, Роза апа!

Изгеләр зираты

Авыл янында бар бер каберлек,
Күмелгәннәр, диләр, изгеләр.
Дога кыла халкым шунда килеп:
– Изге рухлар шат булсын, – диләр.

Каберлекне саклап калган ташлар,
Ун гасырлык, диләр, үзләрен.
Тарихчылар килеп, ташны сыйпап,
Эзли шул заманның эзләрен.

Мәңгелек түгел бит, кеше китә җирдән –
Тарихка без ниләр калдырыйк?
Калсын иде тик яхшы гамәлләр
Яшь буыннар үрнәк алырлык.

Роза Фәйзуллина ■

безнен мирас №9 сентябрь 2021

Мин сездән, авылдашлар...

(Өзек)

Илдар Юзеев

Илдар Юзеев туган ягына кайткач

Таныйсыңмы мине? Чит итмисеңме? Онытмадыңмы? Әйе, мин инде синең болыннарыңда юрга тайдай чапкан яланаяклы малай түгел. Мин сиңа дөнья күргән, сабырланган, аз сөйләп күп тыңларга өйрәнгән ир булып кайттым. Сиңа җитәр-җитмәс тау башында машинадан төштем дә, чемоданымны җиргә куеп, туктап калдым.

Кайларга гына бармадым, ниләр генә күрмәдем! Ярты дөньяны әйләнеп чыктым дип мактана алмыйм, кызганычка каршы, минем әле чит илләрдә сәяхәттә йөргәнем юк, шулай да үз илебезне аркылыга-буйга иңләдем. Казакъ дусларның тәңгә сихәтләре булган шифалы кымызын авыз иткәндә, мин синең иркен болыннарыңның хуш исле печәнен ашаган сыерның күбекләре ташып торган җылы сөтен сагындым, каракалпак дусларның, су сорамасаң да, ширбәт

итеп биргән ал-кызыл карбызларын иреннәргә тидергәндә, мин синең йомшак тиреслегеңдә үскән кабагыңны күз алдыма китердем. Украин дусларның җылы нурларда иркәләнеп үскән алмаларын кулда тотканда, мин синең бакчаларыңда үскән бәрәңгеңне уйладым. Үз гомеремдә нинди генә тәмле-шифалы сулар эчмәдем: шәфталу соклары, кока-кола, коктейль, тагын әллә ниләр… әмма кырык градуслы салкында күршебез коесындагы чиләктән эчкән судан да тәмлерәге очрамады. Әгәр бар дөньяның иң оста-маһирлары эшләгән будильникларны тезеп куеп: «Теләсә кайсын сайла», – дисәләр, мин, һич тә икеләнмичә: «Туган авылымда сызылып таң атканда моңлы тавыш белән кычкырып уяткан әтәчне китерегез!» – дияр идем. Сабый чакта йокы бигрәк тә тәмле була. Шуңа күрә микән, безнең авылда, без бәләкәй чакларда, йокларга гына түгел, җырларга да яраталар иде.

«Кара дуга, пар кыңгырау
Безнең атларда гына.
Рәхәтләнеп йоклап калдым
Сабый чакларда гына...»

Музейда шагыйрьнең шәхси әйберләре

Музей шагыйрь турындагы хатирәләрне саклый

Өч баш мөхәррир – Вахит Имамов, Ләбиб Лерон һәм Рөстәм Галиуллин Ямады авылы балалары белән



Хушлашканда.

Мин дөньядан киткәч,
Бик ямансу булыр,
Йортымдагы һәрбер уләнгә,
Сугардым бит чиксез мәхәббәтем белән
Матурлыкның кадерен белгәнгә.
Сагышлырак булыр серень чәчәкләре,
Минсез аткан тәүге язларда.
Тик мин генә булмам шул чагында,
Сагыным кайтыр киек казларда.
Агач саен кәккук кычкыргында,
Моңсурак була урманда.
Үпкә тотмыйм кәккугемә,
Калган гомерем кыска булганга.
Кем иркәләр икән серень чәчәкләрен,
Кулларында тоеп җылысын,
Сау булыгыз гомер иткән җирем,
Тыныч тормыш сезгә миннән соң.

Шәкүрә.

1974 ел. декабрь.

Илдар Юзеевның әнисе Шәкүрә ханым язган шигырь

Чит илләргә чыксаң...

Илдар Юзеев сүзләре,
Сара Садыйкова көе

Китмә, диләр, бездә калып җырла...
Әллә инде аңлый алмыйлар:
Туган илдән киткән сандугачлар
Чит җирләрдә сайрый алмыйлар.

Мин сандугач түгел, җырлыйм өзелеп,
Туган якка уем тартылган;
Сандугачтай читтә саргайганчы,
Очып кайтам җырым артыннан.

Адашканнар, сагынып тилмергәннәр
Бу җырымнан эзләп тапсыннар,
Телсез-җырсыз калган сандугачлар
Туган илләренә кайтсыннар.

Мин сандугач түгел, җырлыйм өзелеп,
Илсез саргаюлар чын икән...
Чит илләргә чыксаң, озак торма, –
Гыйбрәт алыр өчен чык икән.

Мин сандугач түгел, җырлыйм өзелеп,
Туган якка уем тартылган;
Сандугачтай читтә саргайганчы,
Очып кайтам җырым артыннан. ■

Ямады авылында Илдар Юзеев урамы

Безнең мирас №9 сентябрь 2021

Чүпрәледә – «Мунчәли укулары»

Быел 10 июльдә Чүпрәле районының Мунчәли авылында «Мунчәли укулары» уздырылды. Әлеге күркәм чарада Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев, Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе ректоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин, Чүпрәле муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары Илмир Измайлов, Бөтендөнья татар конгрессының Казан бүлеге җитәкчесе Фәрит хаҗи Мифтахов, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон, Татарстанның халык артисты Миңгол Галиев, язучы-драматург Данил Салихов, Татарстанның атказанган артисты Марсель Вәгыйзов, галим-агроном Харис Камалиев, шулай ук, республикабыз районнарыннан, Чуашстан Республикасыннан, Ульяновск, Түбән Новгород һәм Мордовия төбәкләреннән килгән дин әһелләре катнашты. «Мунчәли укулары» кысаларында Татарстанның атказанган урманчысы Ирфан Халитовның 70 яшьлек юбилеена мөнәсәбәтле «Шәҗәрә бәйрәме», балалар өчен «Шәкертләр бәйрәме», төрле уеннар һәм бәйгеләр дә үткәрелде. Кичке яктагы «Авыл бәйрәме»ндә исә Татарстанның атказанган артистлары Гүзәл Уразова һәм Илдар Хәкимов катнашты.

Мунчәли авылына кагылышлы кайбер фактлар

Чүпрәле районындагы Мунчәли авылы, бай тарихка ия булып, Казан ханлыгы чорыннан ук билгеле. Моны авылның төзелә башлавына, аның исеменә бәйле төрле риваятьләр дә дәлилли.

Тарихи чыганакларда мочар кабиләләре турында мәгълүматлар бар. «Мочар» сүзен мадьяр, мишәр сүзләре белән тәңгәлләштереп була. Әлеге кабиләләр Мещера һәм Сура елгалары бассейннарында яшәгән. Моңа мисал итеп, бүгенге Түбән Новгород өлкәсендә Мочалейка елгасы булуын әйтеп үтү урынлы булыр.

Мунчәли авылы берничә өлешкә бүленгән: Гать буе, Оч, Урталык, Кече авыл (Кычаул), Дубрау һәм Дарданел.

Мунчәли – Буа өязенә кергән авылларның берсе. 1774 елда Мунчәли волосте формалаша. 1780 елда Сембер губернасы барлыкка килү белән, Мунчәли волосте Сембер губернасының Буа өязе составына керә. XVIII гасырда һәм XIX гасырның беренче яртысында аның халкы дәүләт крестьяннары категориясенә кертелеп, авыр лашман хезмәтен үти. 1864 елгы реформалардан соң, биредәге Мунчәли иң зур авылга әверелә. XIX гасыр ахырына Мунчәли авылында өч мәдрәсә, дүрт мәчет барлыкка килә. 1904 елда «Урталык» мәчетендә арифметика һәм география укытыла башлый. 1910 елда рус-татар земство мәктәбе ачыла.

Мунчәли авылында 1930 елда «Кызыл партизан» колхозы оеша. Аның беренче рәисе Ишмөхәммәт Шаһиев була. 1960 елда «Кызыл партизан» колхозы, күрше колхозлар белән берләшеп, «Авангард» колхозы дип атала башлый. Аның рәисе итеп Әскәр Әкбәр улы Гайнуллин (Татарстанның халык артисткасы Алсу Гайнуллинаның әтисе) сайлана.

1992 елда мәктәп – Мунчәли урта мәктәбе, 2008 елда – төп мәктәп, 2012 елда исә «Мунчәли башлангыч мәктәп-балалар бакчасы» итеп үзгәртелә. Бу ел-

ларда биредә укытучы һөнәренең чын осталары хезмәт куя. Мәсәлән, Татарстанның атказанган мәгариф хезмәткәре Маһруй Якупова, халык мәгарифе отличнигы Иршат Хәлилов. 1973-1974 нче елларда Г.Тукай премиясенең булачак лауреаты шагыйрь Роберт Рәкыйпов мәктәп директоры булып эшли. Заманында биредә татар әдәбиятының Шәрәф Мөдәррис һәм Зәки Нури кебек күренекле шәхесләре укый.

Мунчәли авылы тумалары: филология фәннәре докторы, профессор Н.Хисамов, Татарстан Республикасы прокуроры С.Нәфиев (1941-2004), Татарстан Югары суды әгъзасы, ТРның атказанган юристы Б.Идрисов, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, шагыйрь Р.Аймәт, ТР һәм Россия Федерациясенең атказанган табибы И.Сингатуллин, Татарстанның атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре, ТРның атказанган табибы И.Измайлов, Татарстан Республикасының атказанган урманчысы И.Халитов, Советлар Союзы Каһарманы Н.Фазлыев, Социалистик Хезмәт Каһарманы А.Сабирҗанов һ.б.

Горурлыгым минем, Мунчәлием!

Кеше җирдә йорт-җир, нигез кора,
Тимәсен, дип, җилләр, салкыннар.
Җир йөзендә минем шундый өем –
Мунчәлием, туган халкым бар.

Ил йомышын кайда үтәсәм дә,
Сынатмаска дигән антым бар,
Балаларын күреп, сынап торган
Мунчәлием, туган халкым бар.

Ямансулап калсам мин еракта,
Үзәгемә үтсә салкыннар,
Җылысына кайтып сыенырга
Туган авылым, туган халкым бар.

Бу дөньяда мин бер ятим түгел,
Горурлыкка тулы хакым бар:
Тигезләргә мине тигез иткән
Республикам, туган халкым бар.

Нурмөхәммәт Хисамов ■

Акыл – мидәге сырлар...

(Хикмәтле җөмләләр)

Фарук Нәфиев

Акыл – маңгайдагы җыерчыклар түгел, ә мидәге сырлар.

Дөрес җаваплар бирүче түгел, дөрес сораулар куючы кеше галим дип атала.

Бик күп кирәкмәгән нәрсәгә өйрәнә алмаган укучылар галимгә әйләнә.

Алманың шапылдап җиргә төшүен күпләр күргән һәм күреп тора. Әмма Ньютон гына: «Ни өчен?!» – дигән сорау куйган һәм бөтен Галәмгә хас мөһим законны ачкан.

Урыслашкан башка милләт вәкилләре шовинизмда урыс милләтчеләрен дә уздыралар.

Ирләр барысы да бериш, хезмәт хаклары гына төрле.

Күп ирләр хатыннарын аңламаганга сабыша. Чөнки бу аларга арзангарак төшә.

Кызару – кешегә хас сыйфатларның иң кешелеклесе.

Ирләр күбрәк үзләренә ошаганны түгел, үзе аларга ошаган хатын-кызны сайлый.

Мәхәббәттә тәннәр һәм матур сүзләр тантана итә.

Мәхәббәттә җиңүчеләр булмаса да, җиңелүчеләрнең исәбе юк.

Мәхәббәт – мәңгелек, гашыйклар гына алмашынып тора.

Мәхәббәт терекөмеш сыман: аны йодрыкта түгел, ачык учта гына саклап була.

Мәхәббәт даруы – өйләнешү.

Мәхәббәт – һәр тарафы чыгымнар белән чолгап алынган хисләр диңгезе.

Бездә җайлап авыру өчен дә ат тазалыгы кирәк.

Үч алырга керешкәнче, ике кабер казы.

Артык әйтер сүзе булмаса, хатын-кыз иренә бер генә сүз әйтә.

Гаиләдә тынычлык саклау өчен, һичьюгында ике телевизор кирәк.

Бик җиңел бирелгән вәгъдә – аның үтәлмәячәгенең ышанычлы билгесе.

Бәхет – нык сәламәтлек һәм начар хәтер.

Сабыр кешенең ачуыннан саклан.

***Редакциядән:** Августта «Безнең мирас» журналының авторы Чүпрәле районының Мунчәли авылы тумасы Фарук Арифулла улы Нәфиевкә 85 яшь тулды. Юбилярны күркәм бәйрәме белән ихластан котлап, аңа саулык-сәламәтлек, иминлек теләп калабыз!* ■

Хәкимов

Индус Таһиров

Рафаил Хәкимов. ***Максим Платонов фотосы***

Рафаил Сибгат улы үзенчәлекле сәләтле галим. Аның яратып эшли һәм яза торган темалары күбрәк татар тарихына, милләтебезнең бүгенгесенә һәм киләчәгенә багышланган.

Күптән түгел Интернетта аның татар атамасының кайбер идеологлар язганча түгел, ә күпкә борынгырак барлыкка килгәнлеген исбатлауга багышланган язмасы дөнья күрде. Әлеге язма турындагы фикерләр үзләрен күп көттермәде. Араларында шактый үзенчәлеклеләре дә бар. Минем өчен иң кызыклысы Президентыбыз Рөстәм Нургали улыныкы булды. Анда болай дип язылган: «Хакимов, если ты такой правый, опубликуй научную статью в авторитетном международном журнале. Там твои аргументы беспристрастно проверят и примут решение, стоит ли печатать такие мысли. Пришли ссылку на свои публикации про это. Сейчас выходит, что ты псевдонаукой занимаешься. Ты убеждаешь массы в своей правоте через СМИ. Поверь, так наука не работает: нет публикации – нет признания твоих мыслей».

Димәк, ул тарихыбызга караган китапларны, мәкаләләрне ныклап карап бара. Минем кайчандыр инглиз дипломаты Эдуард Паркерның татарларның борынгы тарихына багышланган әсәрләре турында язган мәкаләм бар. Аны мин беркайда да бастырмадым. Хәзер исә, шушы очрактан файдаланып, «Безнең мирас» журналына шул текстны тәкъдим итәм.

***

Э.Х.Паркер – мәшһүр дипломат һәм тарихчы – 1849 елда туып, 1926 елга кадәр яшәгән бер инглиз галиме. Күп еллар буена Кытайда дипломатик хезмәттә вакытта кытай телен камил рәвештә үзләштереп, татарларга караган кытай чыганакларын ныклап өйрәнгән, киң карашлы шәхес булган[1]. Аның инглиз телендә язылган китабының «Тысяча лет из истории татар» исемле беренче басмасын 2003 елда русчага – АКШта яшәүче күренекле галимебез Вил Мирзаянов, ә икенчесен – «Татары: история возникновения великого народа» дип аталган хезмәтен Т.Ю.Любавская русчага тәрҗемә иткән. Ике басмасы да 2003 һәм 2010 нчы елларда «Идел-Пресс» нәшрияты тарафыннан нәшер ителгән.

Эдуард Паркерның китапларына күз салыйк әле. Бу китапларда төркиләрнең тамыр башы татар икәнлеге исбатланган. Безнең дәвернең ахырында төрки сөйләмнәр нигезендә Гансу (Сицзян), Ляо (Төньяк Кытай) исемендәге ике татар дәүләте булган. Алар арасындагы 2,5 км ара татар даласы дип аталган. Кытайлар «төрек» термины барлыкка килүгә кадәр мең ел элек үк татар сүзен кулланганнар.

Китапларда тупланган фактлар шушы исемдәге кечкенә генә бер кабилә булып, соңрак аның исеме барлык тугандаш кабиләләрнең, шул исәптән һуннарның да җыелма исеменә әверелгәнлеге турында сөйлиләр. Кытай чыганаклары бу җыелма тугандаш кабиләләрне, алар төзегән дәүләтләрне «хиен-ху» дип тә күрсәтәләр. Шул ук вакытта аларга карата «Татарстан», «татар» дигән төшенчәләрне еш кулланганнар[2]. Ә төрки сүзе безнең дәвернең V гасырында гына әйләнешкә кергән[3].

Дөрес, Паркерга кадәр дә, аннан соң да моңа охшаш мәгълүматлар күренгәләп торган. Тик аларга тиешле игътибар гына булмаган.

Ничек инде ул ниндидер булыр-булмас автоном хокукта яшәгән татарлар бөек булсыннар! Ничек инде аларның Ганнибалга тиң гаскәр җитәкчеләре була

---

[1] Бу галим «История возникновения великого народа». (Центрполиграф, 2008), «Происхождение тюрков и татар» исемле китапларның да авторы. Соңгысында ул скифларның да төркиләрдән чыкканлыгын исбатлый.
[2] Э.Х.Паркер. Тысяча лет из истории татар. Казань: «Идел-Пресс», «Слово», 2003. – с.48.
[3] Шунда ук, 5 б.

алсын! Рус күңеле һич кенә дә моның белән килешә алмый. Бу уңайдан инде революциягә кадәр үк, Аттиланы руслаштырырга тырышып, зур хезмәткә кадәр языла.

Ә бит чынында Аттила тактикасының дәвамчысы булган Модэ-Баһадурны «Татария Ганнибалы» дип атаганнар. Аның ил һәм гаскәр белән идарә итү системасы шулкадәр камил булган ки, аны кытайлар да, соңрак монголлар да үзләренә өлге итеп алганнар. Паркер Баһадурның үткән дәвернең 211 елында 320 меңлек кытай армиясен тар-мар итүен Аттиланың Шалон янында Рим гаскәрен тар-мар итүе белән чагыштыра. Бу уңышлар Паркер тарафыннан борынгы татарларның күпләргә караганда гайрәтлерәк икәнлекләре, ат өстендә оста сугыш алып бара белүләре, үзләренә генә хас сугыш стратегияләре һәм тактикалары булу белән аңлатыла.

Кир, Александр Македонский, Дарий, Керкс, Цезарь һәм Помпей кебек гаскәр башлыкларын Баһадур белән чагыштырырлык та түгел, дип язылган аның китабында. Баһадур Кытай императорына язган бер хатында, үз кул астыма барлык татарларны яки «ат өстендә җәядән ук атучыларны» җыйдым, дип яза. Сүз 1911 елга кадәр Кытай империясенә кергән Тибеттан башка җирләр турында бара.

Ул татарлар төзегән дәүләтләрдә җинаятьчелек юк дәрәҗәсендә икәнлеген ассызыклап күрсәтә. Кешегә каршы җинаять кылучы адәм үлем җәзасына тартыла. Күрәсез ки, хөрмәтле укучылар, борынгыларыбыз кеше кадерен бик яхшы белгәннәр. Монда халык санын алу системасы да җайга салынган була. Һәм ул Алтын Урда дәүләтендә дә үз дәвамын таба. Рус җирләрендә халык санын алу хезмәтен дә татарлар башлап җибәрә.

Паркер хезмәтендәге татарларның кытайларга ясаган йогынтылары, хәтта Пекинны яулап алып, император тәхетенә утырганлыклары, императорларның татар традиция һәм гореф-гадәтләрен үзләштерүләре, үзара никахлары турындагы мәгълүматлар күпләр өчен яңалык.

Мәгълүм ки, кытайлар төрки музыка-моңны ныклап үзләштерәләр. 1989-1990 нчы елларда Казан университетында стажировка үткән кытай профессоры Чянь Бинь: «Без сезнең музыкагызны алдык һәм аны тирә-якка тараттык, хәтта Япониягә кадәр җиткердек», – дип әйтә иде. Бу, чыннан да, шулай. Профессор Марсель Әхмәтҗановның хезмәтләрендә кытай императорларының татарлар янына аларның музыкасын язарга махсус рәвештә кеше җибәрүләре хакында мәгълүмат бар. Ә менә мәшһүр Зәки Вәлиди төрки музыканы казан татарлары саклап калганлыгын дәлилли. Моның сәбәбен ул заманында Казан тирәсенә Алтай ягыннан күчеп килгән татар кабиләләренең урнашуы белән аңлата.

Тик монда шунысын онытырга ярамый: кытайлар – үзенчәлекле цивилизация тудырып, дөньяга бик күп яңалыклар керткән халык. Һәм алар мәдәният ягыннан татарлардан күпкә өстен булганнар. Татарлар алардан бик күп нәрсәләргә өйрәнгәннәр. Мәсәлән, җир эшкәртү, иген игү, бакчачылык һөнәрләренә. Хәтта кәбестә саклау рәвешенә дә. Ләкин, кытайлардан аермалы буларак, һуннар кәбестәне дөге аракысына салып түгел, ә тозлап саклый торган булалар. Һәм алар шушы тозлау рәвешен европалыларга да өйрәтәләр.

Тик менә татарлар күпләргә караганда гайрәтлерәк булган, алар ат өстендә оста сугыш алып бара белгәннәр. Үзләренә генә хас булган сугыш стратегиясен һәм тактикасын булдырганнар.

Э.Паркерның хезмәтләрен революциягә кадәр дә, аннан соң да күрмәмешкә салыша килделәр.

Совет тарих фәнендә чит ил галимнәренең Россия тарихына караган хезмәтләре буржуаз фальсификация итеп бәяләнә килде. Болар барысы ялган, совет җәмгыятен таркатуга юнәтелгән уйдырмалар гына, имеш. Паркерның хезмәте исә телгә дә алынмый иде.

Дөрес, Паркерның хезмәте үз эченә Чыңгыз заманына кадәр генә булган чорны ала. Ләкин ул җыеп туплаган мәгълүматлар татарның алдагы бөеклекләрен ныклап аңлауга юл ача.

Бу бөеклек чоры кайчан беткән? Эдвард Паркер үз хезмәтендә татар тарихын юкка гына Чыңгыз дәверенә кадәр генә тикшермәгән. Чыңгыз ханның кытайлар ярдәмендә татар ханы Муджин Султуны җиңеп, аның үзен үтереп, бик күп татарларны кырганлыгы мәгълүм. Татарларның беренче бөеклек чоры шуның белән тәмамлана, күрәсең.

Монголларның «Сокровенное сказание»сендә татарлар һәм монголлар килешә алмаслык дошманнар итеп күрсәтелә. Баштарак ике арадагы бәрелешләрдә татарлар өстен чыга. Татарларга тугандаш башка кабиләләр шулай ук татарлар дип аталалар. 1247-1318 нче елларда яшәгән Рәшит әд-Дин үз язмаларында аларның башка кабиләләрдән бөеклекләре белән аерылып торганлыкларын, аларның монголларның да хуҗалары булганлыгын күрсәтә. Аның язуынча, татарлар үзләре 70 000 йорт тәшкил итеп, тутукулиут, алчи, чаган, терат, куин, баркуй, дербен, дутау, алухай кебек кабиләләрдән торганнар[4].

Тарих тәгәрмәче төрлечә әйләнә. Әгәр моңа кадәр монголлар татар хакимлегендә яшәгән булсалар, Чыңгыз ханнан башлап, киресенчә, татарлар үзләре аларга буйсынып яши башлыйлар. Алай гына да түгел, Чыңгыз татарларның арба чәкүшкәсеннән тәбәнәгрәк булган балалардан калганнарын юк итәргә куша. Эш хәтта йөкле хатыннарның эчләрен ярып, балаларын алуга кадәр барып җитә. Ләкин, дип язган шул ук Рәшит әд-Дин, бу әмер үтәлми кала[5]. Татарларның шактые качып котыла, күбесе монгол гаскәренә кушыла.

Татарларны монголлардан бик яхшы аера белгән көнбатыш сәяхәтчесе Вильгельм Рубрук сүзләренчә, Чыңгыз үз походларында татарларны һәрвакыт алдан җибәрә торган булган һәм: «Әнә татарлар килә!» – дигән аваз гел яңгырап торган. Шунлыктан, татар атамасы киң тарала. Әйе, нәкъ борынгы заманнардагы кебек!

Монголлар кыпчак далаларында, болгар илендә, төркиләр камалышында калалар. Шушы камалыштагы йогынты хәтта Чыңгыз нәселен дә әйләнеп үтми. Нәтиҗәдә, Алтын Урда ханнары татарлашалар.

XIV гасыр авторы Эль-Омари азчылык тәшкил иткән монголларның тиз арада төрки күпчелеккә сеңеп беткәнлеген мондый сүзләр белән белдерә: *«Борынгы заманда бу дәүләт кыпчак иле булган, ә инде аны монголлар яулаганнан соң, кыпчаклар аларның кул астында калдылар. Аннан соң монголлар кыпчаклар белән аралашып, туганлашып беттеләр һәм җир, аларның табигый һәм раса сыйфатларын җиңеп, өстенлек алды. Шуннан соң алар, әйтерсең лә, бер нәселдән кебек, нәкъ кыпчакларга охшаш булдылар»*[6].

Үзбәк хан заманында Алтын Урдага килгән гарәп авторы Ибне-Баттута, хан үзе монголча белсә дә, кыпчак телендә сөйләшә, дип язып калдырган. Аның күзәтүенчә, хан тирәсендәге югары катлам монголлар да, төркиләрнең гореф-

---

[4] Рашид ад-Дин. Сборник летописи. Т.1, кн.1. С.78.
[5] Шунда ук, 305 б.
[6] Шунда ук, 307 б.

гадәтләрен үзләштереп, төркиләшеп беткән булалар. Бу процессны Үзбәк ханның исламны дәүләт дине итеп игълан итүе дә тизләштерә.

Күп вакыт татарларны монголлар белән бутап, аларны бер кавем итеп күрсәтәләр. Мондый караш һич кенә дә дөрес түгел. XI гасыр филологы Мәхмүд Кашгарый татарларны 20 төрки кабилә арасында күрсәтә. Ул, алар, бәҗәнәкләр, башкортлар, кыпчаклар һәм кыргызлар кебек үк, төрки телдә сөйләшкәннәр, дип язган. 1160-1223 нче елларда гомер кичергән гарәп тарихчысы Ибне-Асир да аларны төрки кабиләләр арасында күрсәтә.

Татарларның яңа бөеклеге – Алтын Урда чоры. Тик совет җәмгыятендә моны күрсәтүгә дә табу салынган иде. Бу илдә күп еллар буе безне татарлыктан биздерү сәясәте тантана итә килде. Имештер, татарлар – Чыңгыз хан белән килгән явыз, кыргый һәм ерткыч монгол калдыклары. Алар башкаларны талап, аларны үтереп, шәһәр-авылларны җимерүчеләр. Һәм иң әһәмиятлесе – рус дәүләтенең һәм халкының иң явыз дошманнары. ВКП(б) Үзәк Комитетының 1944 елның 9 августындагы «Татарстан партия оешмасында агитация һәм пропаганда эшенең торышы» исемле карары менә шушы карашка нигез сала. Шуннан соң Алтын Урда дәүләте бары тик тискәре рәвештә генә күрсәтелә башлый. Партия диктаты хөкем сөргән заманда бу карардан, аның күрсәтмәләреннән читкә тайпылу – гөнаһларның да гөнаһысы, аларның да иң зурысы. Кая инде анда «Идегәй» дастанының өч йөз еллыгын үткәрү. Гәрчә Бөек Ватан сугышы башланыр алдыннан шул идеяне партия Өлкә комитеты үзе тәкъдим иткән булса да!

Татар атамасы хурлыклы тамгага әверелә. Бигрәк тә безгә туганнан-туган кырым татарларын гаделсез рәвештә илләреннән-җирләреннән сөргәннән соң.

Юк, без монгол да түгел, татар да түгел, без – болгарлар. Безгә бу хурлыклы атаманы тик кемнәрдер генә таккан! Ни кызганыч, мондый карашның әлегәчә юкка чыкканлыгы сизелми.

Моның да сәбәбе шул ук: татарның тарихта бөек булырга хакы юклыгында! Бу илдә һәрвакыт бер милләт бөек булган һәм бөек булып калырга тиеш тә!

Нәкъ менә шуның өчен хәтта Алтын Урда һәм татарлар хакындагы дөреслекне чамалы рәвештә генә биргән Карамзин, Соловьев, Ключевский кебек революциягә кадәрге тарихчыларга да урын тарая. Ә алар турында тулы дөреслеккә омтылган «Древности русского права» исемле тарихи әсәр тудырган В.Сергеевич кебек галимнәрнең хезмәтләре бөтенләй онытыла дияргә була.

Ни өчен? Рус җирләрен җыючы рәвешендә күрсәтелә килгән Иван Калитаның чын образын биргәне өчен. Мин чынында В.Сергеевичның бу сүзләрен, аларның ышанычлы булуын раслау өчен, оригиналдагыча китерәм: «Рабская угодливость перед Ордой доставила Калите (1328) обладание великим княжеством, которое он занимал до своей смерти. В завещании он ни одним словом не упоминает о судьбе великого княжения по смерти своей. Это совершенно согласно с его раболепным отношением к Орде: великим княжением распоряжаются ордынские цари; Иван Данилович, их покорный слуга, это знает и в права владык своих не вмешивается». В.Сергеевич, бу грамотаның хан ризалыгы һәм раславы нигезендә язылганлыгын аның мөһере раслый, дип язган һәм болай дип өстәп куйган: *«Калита – добрый и зажиточный семьянин, которому хорошо жилось под властью ордынских царей. Ничего лучшего он и для детей своих не желал»*. Татарга тылмач кирәкмәгән кебек үк, бу сүзләргә дә бернинди өстәмә кирәкмидер дип уйлыйм.

Әлеге галимнең башка сүзләре дә бөекдержавачыларны рухландырырдай түгел. Аларны да мин дөреслеккә хилафлык кылмау максатыннан чыгып рус телендә бирәм: *«Северо-восточные княжения получили первое, но чисто внешнее объединение в 1238 году, по покорении их татарами. С этого момента возникло общее подчинение их ордынским ханам. В лице ханов впервые создалась высшая власть над всеми князьями Русской земли. Ханы не только распределяли столы между князьями по своему усмотрению, но и призывали их к своему суду и вольны были в их жизни и смерти...» Татары таким образом «явились проводниками начала объединения Русской земли под главенством великого князя Владимирского... Татарское завоевание оставило глубокий след в нашей истории».*

Әйе, тирән эзләр... Бүгенге тарихчы-сәясәтчеләр Юрий Пивоваров һәм Андрей Фурсенко язганча, Алтын Урда чоры – рус тарихының иң бай катламын тәшкил иткән эзләр чоры. Юрий Пивоваров шушы фикерне «Комсомольская правда» газетасының 2010 елгы 28 август санындагы «От кого взяло государство российское: от Византии или Золотой Орды?» исемле мәкаләсендә тагын бер кат кабатлаган.

Ләкин Э.Пайпс әйткәнчә, рус тарихчылары бу турыда язарга оялалар. Чөнки дөресен яза башласаң, Александр Невскийның да шундый ук, үз мәнфәгатьләренә ирешү өчен үз туганын, хәтта улын да кызганмый торган кол икәнлеге, Дмитрий Донскойның Мамай белән бәрелеш вакытында куркуыннан гади сугышчы киеменә киенеп качып китүе, Мәскәүгә Туктамыш ханның якынлашуын ишеткәч, ханнан куркып, шәһәрдән чыгып качуы хакында да язарга туры килер иде. Дмитрийның Мәскәүдән чыгып качуының сәбәбен рус елъязмалары, «убоявшись законного царя», дип аңлаталар. Ә законный царь, яки кануни патша ул –Туктамыш.

Күп очракта татар белән монголны бутауны күрергә туры килә. Ләкин алар икесе ике төрле кавем. Бу Паркерның китабында да, аңа кадәрге язучыларның хезмәтләре һәм әсәрләрендә дә ачык чагыла. Монгол гаскәрендә Чыңгыз хан тарафыннан җыелгән татарлар шактый була. Ләкин менә бу гаскәр, Уралның бу ягына чыгу белән, төркиләр яшәгән кыпчак далалары һәм болгар җирләрендә хәрәкәт итә башлый. Әмма төрки тамырлар шулкадәр көчле була ки, берничә дистә ел үтүгә, алар үзләре дә төркиләшәләр, дөресрәге, татарлашалар.

Чыннан да, монголлар җитәкчелегендә барлыкка килгән дәүләтне татарлаштыру могҗизаның могҗизасы. Э.Паркер кебек тарих тирәнлегенә ныклап күз сала алган галимнәр өчен бу могҗиза – объектив рәвештә барлыкка килгән катлаулыдан-катлаулы, каршылыклыдан-каршылыклы тарихи процесс нәтиҗәсе.

Без бүген дә кайбер тарихчыларның хезмәтләренә тиешле игътибар биреп җиткермибез. Әллә инде вакыт җитми, әллә күңел күзе күрми шунда. Ә күңел күзе күрмәсә, маңгай күзе ботак тишеге, ди бит халкыбыз. Бушков исемле рус кешесе Чыңгыз хан һәм ул төзегән империягә багышлап китап язган. Аны күрмәмешкә салынучылар да, күреп тә анда язганнарга ышанычсызлык белдерүләр дә булды. Ләкин бу кешенең монголларның моңа кадәр бернинди дәүләт төзү тәҗрибәсе булмавы һәм ул тәҗрибәнең бары тик татарларда гына булуы турында яза. Ул хәтта Чыңгызның үзен дә татардан чыккан дип исәпли.

Безгә исә аның бу очракта татарның чыннан да зур дәүләти тәҗрибәсе булуы турындагы исбатлаулары әһәмиятле. Алар, чыннан да, төркилекнең

башында торган кабилә булалар. Һәм инде Рәшит әд-Дин язганча, башкалардан үзләренең бөеклекләре белән аерылып торганнар.

Без кем соң: татарлармы, болгарлармы? Ә бәлки, кыпчаклардыр? Мин мондый сорауны һәм «Возрождение» фонды барлыкка килеп, эшен ныклап җәелдереп җибәргәннән соң куера башлаган бәхәсләрне урынсыз дип саныйм.

Берәү дә Татарстаныбызны Болгарстан итеп игълан итәргә җыенмый. Шул исәптән әлеге фондның башында торган Минтимер Шәймиев тә, хөкүмәт башында торучылар да. Аларның төп максаты урта гасырлардан калган болгар хәрабәләрен элеккеге хәленә китереп, аларны Европа дәрәҗәсендәге мәдәният учагына әверелдерүдән гыйбарәт. Шунлыктан бу изге максатның вакыты-вакыты белән чыгып тора торган бәхәсләргә бернинди мөнәсәбәте дә юк.

Илдәге 2010 елның октябрендә үткән җанисәп вакытында да болгарчылык хәрәкәте үзен белдергән иде. Берничә йөз кеше үзләрен болгарлар дип яздырып, татарлыктан китәргә маташтылар. Тик татарлыктан алай гына котылып булмый бит. Әгәр телең, гореф-гадәтләрең татарныкы, ата-бабаларың татар икән, син инде, кем булып язылуыңа да карамастан, татар булып каласың. Быел үтәчәк җанисәп вакытында да без үзебезнең татарлыгыбызны ныклап расларга тиешбез.

Татарның болгарлык чоры инде күптән үткән. «Үткән эшкә салават», – диләр халыкта. Бу, чыннан да, шулай. Бүген без инде күптән формалашкан татар милләтен тәшкил итәбез.

Моны болгарлыктан йөз чөерү дип атап буламы? Бу сорауга катгый рәвештә: «Юк», – дип җавап бирергә кирәк. Ни өчен? Чөнки бу динебезнең рәсми башы. Барлык уңайлыклары белән корылган шәһәрләр, күпләрне таң калдырган һөнәрчелек, җир эшкәртеп мул уңыш алу сәнәгате, заманча сәүдә итү, ислам мәдәнияте һәм башка бик күп нәрсәләр болгар чорында барлыкка килгән. Болар барысы бергә ныклы тамыр җәеп, булачак татарлыкның нигезен салуга зур өлеш керткән.

Кол Гали, аның үлмәс «Йосыф-Зөләйха»сы, болгар чорының башка рухи ядкярләре һәрвакыт халык күңелендә һәм телендә.

Милләттәшенең җырын тыңлаганда Тукаебызның да күз алдына юкка гына Болгар һәм Агыйдел буйлары килеп басмагандыр. Күрәсең, бу шагыйрьнең канына сеңгән тарихыбызны тоемлавы булгандыр?.. Ләкин Тукай һәрвакыт, горурланып: «Татар мин!» – дип әйтә килгән.

Вакыты-вакыты белән безнең каныбызда болгарлык та, кыпчаклык та кайнап, үзен сиздергәләп тора. Ләкин ничек кенә булмасын, шул ук вакытта без – каныбызга тарихыбызны бөтен каршылыклары белән сеңдергән татарлар!..

P.S. Рафаил Сибгат улы, һәрвакыттагыча, милләтебез язмышына багышланган актуаль проблемаларны күтәреп кенә тора. Сәләтле галим һәм сәясәт белгече ул. Һаман да шундый булып калсын иде.

Тик шулай да Президентыбыз сүзенә колак салып, язмаларын халыкка журналлар аша да ирештерә торса, бигрәк тә дөрес булыр. ■

«Безнең мирас» котлый!

Танылган шәхесләребез – галимнәр, язучылар, дин әһелләре, журналистлар һәм сәнгатькярләр сентябрь аенда үзләренең гомер бәйрәмнәрен билгеләп үтә. Менә алар:

3 сентябрь – ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1987), ТРның атказанган фән эшлеклесе (1998), филология фәннәре докторы (1996), профессор (1998), язучы, публицист **Илдар Малик улы Низамов**ка 85 яшь (1936);

3 сентябрь – ТР ФАнең мөхбир әгъзасы, ортопед-травматолог, медицина фәннәре докторы (1986), профессор, ТРның атказанган фән эшлеклесе һәм атказанган уйлап табучысы, ТР дәүләт премиясе лауреаты **Хәйдәр Зәйнулла улы Гаффаров**ка 80 яшь (1941);

6 сентябрь – ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1992), 1980 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы, шагыйрә **Флера Сабирҗан кызы Гыйззәтуллина**га 90 яшь (1931);

8 сентябрь – Башкортстан АССРның (1977), РСФСРның (1982) һәм ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1994), РСФСРның халык артисты (1989), Башкортстанның С.Юлаев исемендәге дәүләт премиясе (1976), Россиянең дәүләт премиясе (1996) лауреаты, актер, режиссер, педагог **Рифкать Вәкил улы Исрафилов**ка 80 яшь (1941);

19 сентябрь – ТР Язучылар һәм Журналистлар берлекләре әгъзасы, язучы, журналист **Альбина Равил кызы Нурисламова**га 45 яшь (1976);

24 сентябрь – Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, танылган дин галиме, авыл хуҗалыгы белгече, икътисадчы **Җәлил Васыйл улы Фазлыев**ка 65 яшь (1956).

Олуг затларыбызның барысын да юбилейлары белән ихластан котлыйбыз һәм аларга саулык-сәламәтлек, иминлек, иҗат уңышлары теләп калабыз! ■

Калининградка сәфәр

Ләбиб Лерон

Электричкага утырып, Калининградтан Светлогорскига барган чакта Калинин фамилияле бер юлдашыбыз, үзенең бу якларга ничек килеп эләгүе хакында сөйләгәндә, болай дигән иде: «Фамилиям – Калинин, мәйтәм, миңа ничек тә Калининградка барырга кирәк дип, тоттым да шушы якларга чыгып киттем. Туган җирне ташлап монда килгәнемә бер дә үкенмим!»

Ул шулай дип сөйләгәндә, минем дә Калининградка беркадәр «бәйләнешем» барлыгы исемә төште: мин үскән Актаныш районы элек – мин туганга кадәр – Калинин исемен йөрткән бит! Барлык райондашларыбыз кебек үк, Әүһади бабамны – әниемнең әтисен дә сугышка нәкъ менә Калинин районы хәрби комиссариатыннан алып киткәннәр...

Кыскасы, ни өчен тиктомалдан Калининград якларына барырга булдым соң әле? Тиктомалдан, дип... алай ук түгел инде. Җитди сәбәбе бар һәм ул каһарман шагыйребез Фатих Кәрим белән бәйле...

Балык авылы янындагы су күренеше

Калининград (Твангсте, Кенигсберг)

Храброво халыкара аэропортыннан (элек хәрбиләрнеке булган) Калининград-Кенигсбергка хатыным Фидания белән таксида бардык. Йөртүче – урыс кешесе, Валерий исемле. Сөйләшергә яратучан булып чыкты. Безне кызыксындырган сорауларга бик теләп, ихлас җавап биреп бара. Сорау бирмәсәк тә сөйли:

– Әти сугышны шушында тәмамлаган. Туган ягына кайтырга җыенган. Беркөнне, ашыйсылары килгәч, иптәшләре белән балык тотарга киткәннәр болар. Күп итеп тотканнар балыкны, алып кайтканнар. Кайтуга боларга әйткәннәр: «Ватанга кайтырга җыенгансыз икән. Китмәгез, калыгыз монда. Немецлардан бушаган фатирлар бар, шуларга урнаштырабыз!» – дигәннәр. Шулай төпләнеп калган әти…

Калининград өлкәсе ни-нәрсәсе белән данлыклы, дип сорасалар, бер генә сүз белән җавап биреп була – гәрәбә! Әлбәттә, тагын да дәвам итәргә мөмкин: марципан, угорь балыгы (еланбалык)… Болар турында безгә Валерий бик тәмләп сөйләде:

– Угорь балыгын күчтәнәчкә алырга уйласагыз, минем хатын үзәк базарда эшли, исегездә калдырыгыз: сиксәненче палатка; киләсез, әйтәсез, ул сезгә балык сайларга булышыр.

Такси безне «Radisson» кунакханәсенең ишек төбенә үк китереп куйды. Номерга урнашырга иртәрәк әле, дип, юл биштәрен кунакханәнең саклау камерасында калдырдык та 2010 елдагы җанисәп буенча биш меңләп татар яшәгән өлкәнең башкаласы белән таныша торырга булдык…

Беренче карашка Калининград шәһәре Россиянең башка шәһәрләреннән әллә ни аерылмый диярлек. Әмма йөри-күзәтә торгач, кайчандыр немец шәһәре

булган Калининградның элекке «рухы»н күпмедер дәрәҗәдә барыбер сизәсең – каланың борынгы җиде капкасы (Бранденбург, Закхайм, Тимер юл, Россгартен, Король, Аусфаль, Трагхайм) хәлкадәри исән, берникадәр генә Санкт-Петербург шәһәрен хәтерләткән су каналларында «трамвайлар» йөреп-йөзеп тора, әле анда, әле монда, дигәндәй, берничә гасыр элгәре салынган таш юллар очрый. Ленин проспектындагы Хрущев заманында салынган йортларны немецларның әүвәлге йортларына охшатып «киендерергә» тырышканнар.

Калининград өлкәсендә бүген 1 018 624 кеше (шулардан руслар – 772 534, украиннар – 32 771, белоруслар – 32 497, немецлар – 7349, татарлар – 4534), 1255 елга кадәр – Твангсте, аннары Крулевец, Кенигсберг (1946 елның 4 июленә кадәр) исемнәрен йөрткән башкаланың үзендә исә 493 256 кеше (шулардан руслар – 351 186, украиннар – 16 053, белоруслар – 15 077, татарлар – 2075, литвалар – 1789, немецлар – 1676, поляклар – 1114) яши.

...Фатих Кәрим һәлак булган урынга, Владимирово авылындагы туган якны өйрәнү музеена (анда каһарман шагыйребезгә нисбәтле экспонатлар бар) һәм Ф.Кәрим һәйкәлен күрү өчен Багратионовскига бару турында мин Калининградтагы «Кардәшләр» татар-мөселман җәмгыяте рәисе Рамил Рифкать улы Каюмов белән Казанда чакта ук сөйләшеп куйган идем – кунакханәгә урнашуга шылтыратырсың, дигән иде ул. Ленин проспектын җәяүләп үтеп, шәһәр кунакларының күңелле ял итү урынына әверелгән «Балык авылы»нда булып, су трамваенда кечкенә экскурсия ясап кайткач кына кунакханәгә урнаштык. Шундук Рамил кардәшебезгә хәбәр салдым. Ул исә, безнең килүебез ял көннәренә туры килү сәбәпле, барысын да ачыклап-җайлап бетергәч кенә кабат шылтыратып, Багратионовск якларына безне дүшәмбе көнне Сәлимә Габдулла кызы Яһудина алып барачагын һәм озатып йөриячәген әйтте.

Дүшәмбегә кадәр көн ярым вакыт барлыгын уйлап, без Калининградны үз хутыбыз белән иңләп-буйлап йөрергә, шәһәрнең истәлекле урыннары белән таныша торырга булдык.

Калининградка кадәр кил дә, «Гәрәбә музее»нда булма, имеш! Булдык анда да – сокланып карап, һәрбер экспонат белән танышып йөрдек: гәрәбә кораблар, гәрәбә шахмат фигуралары, гәрәбәдән эшләнгән чутсыз бизәнү әйберләре...

«Гәрәбә музее»ндагы гәрәбә шахмат

Гәрәбә кружка

Храброво аэропорты

Балык авылы

Балык авылында

Калининград кунакханәсе

Светлогорск (Раушен)

1258 елда төзелгән, халкы 2021 елда 16 099 кеше исәпләнгән, 21 км^2 мәйдан биләгән, 1947 елның 17 июненә кадәр Раушен исемен йөрткән, 1999 елның 29 мартыннан курорт статусын алган Светлогорскига без якшәмбе көнне сәфәр чыктык. Төньяк тимер юл вокзалы без урнашкан кунакханәнең «артында» гына иде. Электричкада сәгать тә унбиш минут бардык. Россия кайда да Россия инде: юл читендә әмерикәнски чаганнар «чәчәк атып ята», күпсанлы төзелеш эшләре башланган да ташланган, дигәндәй...

Светлогорскины, интернеттан карап, алдан бераз өйрәнгән идек. Шуңа күрә гәрәбә эшләнмәләр сата торган берничә кибетле Гагарин урамын, күңелгә ятышлы ашханә-кафены һәм, әлбәттә, истәлекле урыннарны бик тиз таптык. Балтыйк диңгезендә дә бераз коенып алу җае чыкты. Кеше күп – яр буенда халык кайный. Һәркайда гәрәбә ялтырый: анда-монда сату рәтләре тезелгән. Алга китеп булса да әйтим, самолетыбыз Казан аэропортына төшеп «кунаклагач», безнең алда гына утырып кайткан татар апалары белән сөйләшеп киттек. Алар «Янтарный» курортында ике атна ял иткән икән. Бик ошатканнар. Ничек соң анда, дигән сорауга, бер генә сүз белән җавап бирделәр: «Европа!»

Иске су кудыру манарасы. Светлогорск



Томас Манн хөрмәтенә куелган истәлек ташы. Светлогорск

Раушен балыкчысы белән. Светлогорск

Гәрәбә кибете. Светлогорск



Гәрәбә кибетендә. Светлогорск

Балтыйк диңгезе буенда. Светлогорск

Владимирово (Тарау, Эрнстоф). Туган якны өйрәнү музее

Калининградның Үзәк базары без урнашкан кунакханә янында гына иде. Биш минуттан анда, биш минуттан монда, дигәндәй... Дүшәмбе көнне шул базарның алгы өлешендә гәрәбәләр белән «танышып» йөргән чакта, сәгать унынчы ярты тирәсендә Сәлимә Габдулла кызы шылтыратып, кунакханә янына унбиш минуттан килеп җитәчәген хәбәр итте. Без шул арада кунакханәгә кайтып, Казаннан ук алып килгән чәк-чәкләрне, «Безнең мирас» журналының соңгы саннарын һәм «Мәдәни җомга» редакциясе күптән түгел генә бастырып чыгарган «Татар барда – хәтер бар» дигән китап нөсхәләрен юл букчаларыбызга салып, кабат урамга чыгарга өлгердек.

1315 елда төзелгән, 1946 елга кадәр Тарау һәм Эрнстоф исемнәрен йөрткән, 2010 елгы җанисәп вакытында 666 кешесе (мисал өчен, 1938 елда – 786, 2012 елда – 835) булган, Калининградтан 20 чакрым ераклыкта урнашкан Владимирово авылы Багратионовск районының Нивенск авылы җирлегенә карый. Авыл эченнән Прохладный (элекке исеме – Фришинг) елгасы ага. Авыл читендә борынгы Тарау Кирха урнашкан.

Төбәкне өйрәнү музеенда безне Ирина Аликовна Ломбенко (музей җитәкчесе) белән Марина Геннадьевна Захарова каршы алды. Бу мөлаем ханымнар Фатих Кәрим һәм аның кызы Ләйлә ханым хакында шундый яратып, исләре китеп сөйләде. Елга ике-өч мәртәбә килә иде, диде алар, каһарман шагыйрьнең кызы Ләйлә апаны искә алып, аңа сокланып.

Владимироводагы Мәдәният йорты. Каһарман-шагыйребез Ф.Кәримгә нисбәтле музей шунда урнашкан.

Ф.Кәримгә нисбәтле экспонатлар янында. Владимирово

Владимирово авылындагы музейда. Сулдан: Л.Лерон, М.Захарова, музей җитәкчесе И.Ломбенко, Ф.Леронова, С.Яһудина

Владимирово авылы музеена истәлек язуы язып калдырдык.

Сәлимә ханым Яһудина

Безне үз машинасында Сәлимә ханымның ире Владимир Сергеевич йөртте. (Рәхмәтләр яусын аңа!) Безгә кадәр дә бу бәхетле пар Казаннан килгән бер хатын-кыз журналистны («Республика Татарстан» газетасыннан, диделәр) Фатих Кәрим эзләре буйлап йөрткән булган. Тыныч тормышта да күпме михнәт кичкән, коточкыч фаҗига кичергән каһарман шагыйребезнең соңгы каны тамган урынга шоферыбыз, барасы юлны яхшы белгәнгә күрәдер, төрле авыллар һәм кыр-басулар аша үтәргә туры килсә дә, һич адашмыйча китереп җиткерде.

Биеклек, дисәң, хәтере калыр. Аны авыз тутырып биеклек дип әйтергә тел бармый хәтта. Калку урын, дисәң, бер хәл әле. Ни аяныч, бернишли алмыйсың, хакыйкать – шушы калкулыкны яулап алабыз (приказ!), дип, күпме яугир, шул исәптән безнең Фатих Кәримебез дә башын салган. Яраланган көе дә сугышуын – дошманга ут яудыруын дәвам иткән бит, бахыр! Үкенечле үлем, дими, ни дисең тагы. Хәер, үлем үкенечсез булмый, диләр…

Сәлимә Габдулла кызы. Сүз уңаеннан, бу ачык йөзле, мөлаем ханым турында бер-ике кәлимә булса да әйтим әле. 2002 елда Калининградта төрки телле халыкларны берләштерүче «Кардәшләр» оешмасы төзелә. Шул вакытта аның җитәкчесе итеп Сәлимә Габдулла кызы Яһудинаны сайлап куялар. Сәлимә ханымның зур тырышлыгы белән, оешма ныгый, милли бәйрәмнәребезгә нисбәтле төрле очрашулар оештырыла, концертлар куела. Булдыклы ханым тиз арада Польша, Литва һәм Латвия татарлары белән тыгыз элемтә урнаштыра. Мәрхүм Адам Якубовскийның польша-литва һәм белорус татарлары турындагы тирән эчтәлекле чыгышын калининградлылар әле дә сагынып искә алалар. Сәлимә Габдулла кызы җитәкчелегендә оештырылган матур эшләрне бүген Рамил Рифкать улы Каюмов белән аның урынбасары Әмир Хәйруллиннар дәвам иттерә.

Кардәшләребез – бертөркем милләттәшләребез. Арткы рәттә уртада – С.Яһудина

Бөтендөнья татар конгрессы Милли Шурасы рәисе В.Шәйхразиев С.Яһудинага тапшырган медаль

Ф.Кәрим һәлак булган урында (сулдан): Рамил Каюмов («Кардәшләр»нең бүгенге җитәкчесе), каһарман-шагыйрьнең кызы Ләйлә Кәримова, Татарстанның халык шагыйре Ренат Харис, Сәлимә Яһудина, драматург Данил Салихов, шагыйрә Шәмсия Җиһангирова

Ф.Кәрим рухына, йәгез, бер дога! (Шушыннан ерак түгел генә калкулык җәйрәп ята.)

Багратионовск (Прейсиш-Эйлау). Фатих Кәрим һәйкәле

1336 елда төзелгән, 1946 елга кадәр Прейсиш-Эйлау исемен йөрткән, 10,7 км^2 мәйдан биләгән, Калининградтан 37 км ераклыкта урнашкан, халкы 6401 кеше булган (руслар – 89%, икенче урында украиннар – 3,7%, белоруслар – 3%, әрмәннәр – 0,9%, немецлар – 0,6% татарлар һәм әзариләр – 0,5%, литвалар – 0,3%) Багратионовскига без Фатих Кәрим һәлак булган урыннан килдек.

2007 елда Багратионовскида затлы һәйкәл ачыла – узган гасырның алтмышынчы елларында Ф.Кәримгә куелган һәйкәлне яңасына алыштыралар.

Әлеге һәйкәлнең тарихы болай. Милләттәшебез, чыгышы белән Омскидан булган Гыйльфан ага Бәхтияров, каһарманыбыз Ф.Кәримгә яңа һәйкәл кирәклеген дәлилләп, шушы төбәктә яшәүче татарлар исеменнән Сәлимә ханым Яһудинага мөрәҗәгать итә. Акча эзләү мәрәкәсе башлана. Көннәрдән беркөнне Сәлимә Габдулла кызы, әллә ни өмет итмичә генә, матди ярдәм сорап, эшкуар Фәрит Касыйм улы Хафизовка сүзката. Рәхмәт төшкере, эшкуар кардәшебез шундук 93,5 мең сум акча белән ярдәм күрсәтә. Шулай итеп, мая салына, бөртекләп диярлек акча туплау дәвам итә. Кыскасы, игелекле кешеләрнең тырышлыгы, ярдәме, җирле хакимиятнең булышлыгы белән тиешле акча җыелып бетә, куелган максатның уңай нәтиҗәсе булып, Багратионовскида каһарман әдибебез Фатих Вәли улы Кәримовка күркәм һәйкәл ачыла.

Багратионовскидагы туганнар каберлегендә – 2007 елда Ф.Кәримгә яңартып куелган һәйкәл янында

Туганнар каберлегендәге истәлек ташында татар фамилияләре дә бихисап. Багратионовск

Мәчет

Фатих Кәримгә бәйле истәлекле урыннардан кайтышлый без Калининградтагы төзелеп бетмәгән мәчетне карарга махсус бардык. Затлы, мәһабәт мәчет буласы булган, ләкин, кызганыч ки, «ниндидер көчләр» төзелешне туктатканнар. Хәзер биредә бернинди дә эш алып барылмый, җан әсәре күренми. Алга таба бернинди өмет тә юк кебек. Барысы да Аллаһы Тәгалә ихтыярында. Милләттәшебез, Бөек Ватан сугышы ветераны Хәким ага Биктиев белән сөйләшкәндә, ул мондыйрак сүзләр әйтеп, безне сискәндерде: «Татарлар мәчеткә йөрми!» Йөрәге әрнеп әйткән бу сүзләрендә хаклык бардыр, ул аны тиктомалдан

гына әйтмәгәндер. Шулай да, мәчет булса, йөрүчеләр булыр иде әле дип уйлап куйдым. Милләттәшләребезгә үземчә киңәш тә биргән булдым: «Марат Хөснуллинны барыбыз да белә. Булышса, бу очракта бары тик ул гына булыша ала. Чөнки ул, «Мәскәү кешесе» буларак, Калининград белән турыдан-туры шөгыльләнүче, курьерлык итүче. Җаен табып, ничек тә шуңа мөрәҗәгать итәргә кирәк!» – дидем.

Төзелеп бетмичә калган мәчет. Калининград

Бертуган Равия һәм Наилә ханымнар

Ерак аралар үтеп, Калининград хәтле Калининградка кил дә үз татарларыбызны күрми кит, имеш! Аллаһы Тәгалә безне милләттәшләребез белән очраштырып кына торды, шөкер. Беркөнне Әмир Әдһәм улы: «Монда яшәүче апаларның сезне күреп сөйләшәселәре килә», – дигәч, бик теләп риза булдык. Аларны үзебезнең номерга дәштек. Равия һәм Наилә исемле ике бертуган ханым белән килде Әмир. Бу күркәм ханымнарның әтисе Ибраһим Шәрип улы Мостаев (1999 елның 21 июнендә вафат) Тәтеш районының Олы Тархан авылыннан, әниләре Сәкинә Әхәт кызы Әхәтова (1918 елның 10 августында туган) исә Буа районының Кырык Садак (Кырсадак) авылыннан булып чыкты. Язмыш апа-ханымнарны шушында китергән. Берсе Казанда медицина институтында укыган. Татарча бик әйбәт сөйләшәләр. Ниятләре – әтиләре язган һәм әле генә урыс телендә китап булып чыкан «Минем язмышым» җыентыгын Татарстандагы якташларга – татар укучысына җиткерү. Кайчандыр елга техникумында укып, соңыннан күпсанлы диңгезләрне гизгән капитан әтиләренең язмышы сурәтләнгән әлеге китап, иртәме-соңмы, татарча да дөнья күрер әле, иншәАллаһ.

Кунакханә номерында гәпләшкән мәлебез. Бер очрашу – үзе бер гомер.



И.Мостаевның «Моя судьба» китабы

Хәким ага Биктиевтә кунакта. Калининград

Гамьле әңгәмә. Бөек Ватан сугышы ветераны Х.Биктиев һәм «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Л.Лерон. Калининград

Хәким ага Биктиев

Милләттәшебез, сугыш ветераны Хәким ага Биктиев фатирына безне Әмир туганыбыз икенче көнне үз машинасында алып барды. «Казаннан килүчеләр булса, алар белән мине күрештерми калмагыз!» – дип әйткән икән ветеран агабыз. Әмир Әдһәм улы, капитан Ибраһим Мостаев кызлары белән гәпләшеп утырган чакта, Хәким агага шылтыратып, киләсебезне әйткән иде. Төш вакытында шунда идек инде. Ишекне марҗа ханым ачты, ул хуҗаның килене булып чыкты. Дөнья бит: парсыз калганнар да инде менә бер фатирда икесе генә яшәп ятмышлары. Туксан алты яшьлек Хәким ага «немецлардан калган» ошбу фатирда (Калининградта) 1945 елдан бирле яши икән инде. Аның сөйләвеннән чамалап, шул елларда ул шәһәр коменданты булып торган дип аңладым.

Кызыксына агабыз – Казан турында сораштыра. Төзелеп бетмәгән мәчет язмышы өчен дә борчыла. Култамга салып биргән китабымны һәм «Безнең мирас» журналы саннарын җәһәт кенә карап чыкты: укырга яратам, мин боларны, һичшиксез, укып чыгачакмын, диде.

Кыскасы, сәфәребез эшлекле төстә узды. Кыска гына вакыт аралыгында күп нәрсәләр күрдек, күп нәрсәләр белдек. Һәм, үз чиратымда, шуларны түкми-чәчми сезгә бәян итәргә тырыштым.

Ы.Кадыйрның рәсем-портреты

P.S. Казанга кайткач, Калининград өлкәсендә җирләнгән тагы бер татар шагыйре барлыгын белдем: ул – безнең Фатих Кәрим белән бер вакыттарак һәлак булган кырымтатар шагыйре Ыргат Кадыйр (Хәлил Җәмил улы Кадыйров, 1905-1945). Каһарман шагыйрьнең җәсәде – Зорино (1946 елга кадәр – Поппендорф) авылындагы туганнар каберлегендә. Бу якларга тагын барырга туры килсә, һичшиксез, әлеге каһарман-шагыйребез җирләнгән туганнар каберлеген дә зиярәт кылырбыз, иншәАллаһ. ■

Зоринодагы (Калининград) туганнар каберлеге. 2012 ел

Ислам дөньясы

Габдерәшит Ибраһимов

Тензин (Тяньцзинь) шәһәре

Тензин (Тяньцзинь)

Шулай итеп, мин Тензинда бер-ике көн калырга дигән карарга килдем. Тантази мәдрәсәсендә кунарга урын бирделәр. Ахун җәнаплары белән арабызда дуслык хасил булды. Тензин бик мәшһүр шәһәр, сәүдә эшләре буенча да шактый әһәмиятле урын били. Сәүдәгәрләрнең күпчелеге чит ил кешесе булуга да карамастан, Кытайның иң данлыклы сәүдәгәрләре дә нәкъ менә бу шәһәрдә яши.

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

Мине, әлбәттә, мөселманнар тормышы кызыксындыра иде, шуңа күрә алар турында мөмкин булган кадәр мәгълүмат тупларга һәм күбесенчә дини җәһәткә игътибар итәргә тырыштым.

Бичара мөселманнар, кайсы яктан гына чыгып карасаң да, бик мескен хәлдә иделәр. Бөтен мәдрәсәләрне карап, йөреп чыктым. Мәчеткә кушып салынган мәдрәсәләрнең биналары искиткеч матур һәм төзек. Тик менә белем бирү ягын карасаң, дөньяның башка бер генә җирендә дә очрамый торган ысул белән укытылуын күрәсең.

Боларда кулланылган китаплар – без белгән, бездә дә мәшһүр булган китаплар. Мәдрәсәләрендә басма китап юк дәрәҗәсендә аз. Дәреслекләре – бар да кулъязма дәрес китаплары. Бу көнгә кадәр бөтен Кытай шәкертләре белем алганда гел язып укыганнар, ягъни, нинди китап укысалар да, ул китапны остаз белән укып өйрәнәләр һәм шул ук вакытта күчереп тә язалар икән. Әле дә язып укучылар бар. Язулары Төркиядәге мәшкъ язуы[1] түгел, безнең Русия мөселман голәмәсе арасында киң таралган, җиңел укыла торган ачык аңлаешлы язу. Кәлам-е Кадим[2] дә шундый ук язу белән язылган. Бөтен мәчетләрдә дә шактый санда бүлек-бүлек итеп язылган Мусхаф[3] бар.

Кытайларның гарәпчә укулары да бик сәер. Гарәпчә китап алып, берәр кытай голәмәсенең кулына бирсәң, китапны ала, ачып, битенә күзләрен теки дә тотына кытайча укырга. Бер генә гарәп сүзен дә, гарәп авазын да әйтми. Тын да алмыйча, искиткеч тизлек белән укый. Сынап, сорап карадым: бөтенләй үк мәхрүм түгел, мәгънәсен шактый төгәл аңлый. Фикъһ (юридик) китапларындагы кайбер сорауларны сорагач, укып-өйрәнгән темалары булса, шәкертләрнең күбесе һич икеләнмичә җавап бирә. Шул җавапны дәфтәргә язарга кушсаң, шактый дөрес язалар. Әгәр сорауны да телдән түгел, язып бирсәң, тизрәк аңлыйлар. Мәсәлән, бер тапкыр бер шәкерткә: *«Хәл йәҗүзу алә-л-мүслиминә татвилүш-ша-р вә-л-әзафир* [Мөселманнарның чәч һәм тырнакларын озын итеп үстерүләре җаизме (шәригатькә каршы төшмиме)?]?» – дип сорау бирдем. Шунда ук кулына каләм алды һәм: *«Йәҗүзу ма-а-л-кәраһәти амма ыйндә әһли-с-сыйн аадәтун ма-руфәтун орфән кә-л-мәшру-и шәр-ан* [Кәраһәт[4] буенча каршы төшми, әмма кытайларда, шәригать кушкан нәрсә диярсең, шулкадәр киң таралган гадәт]», – дип язды. Шуңа охшаш сорауларны телдән генә дә биреп карадым, җавапны бераз озаграк уйлап бирә иде.

Мәдрәсәләрендә булган китапларның күбесе кытай теленә дә тәрҗемә ителгән. «Мухтасар-үл-мәгани»нең[5] дә тәрҗемәсе бар. Димәк, кайчандыр биредә мондый китапларны тәрҗемә итәрлек гыйльми куәткә ия голәмә булган. Тик хәзер инде андый белемгә ия кешеләре калмаган. Шулай булса да, алда телгә алынган китаплар мәдрәсәләрдә белем алучы шәкертләр һәм аларга белем бирүче голәмә тарафыннан кулланыла һәм хөрмәт ителә.

---

[1] Мәшкъ язуы – кулъязма гарәп язуы үрнәге, гарәпчә мәшкъ сүзенең «тиз» дигән мәгънәсеннән килеп чыккан булса кирәк *(тәрж.иск.)*.
[2] Кәлам-е Кадим – Коръән-е Кәрим *(тәрж.иск.)*.
[3] Мусхаф – Коръән-е Кәримнең тагын бер исеме *(тәрж.иск.)*.
[4] Кәраһәт – шәригать кушуы буенча булмавы, эшләнмәве саваплы һәм хәерле дип саналган берәр нәрсәнең бөтенләй үк баш тартмыйча яшәтелүе *(тәрж.иск.)*.
[5] Мухтасар-үл-мәгани – Әс-Сәккакыйның гарәп грамматикасына Әл-Казвини тарафыннан язылган өстәмәләр китабына Саадәтдин әт-Тәфтазани (үлеме – 1390 елда) язган шәрехләр китабы *(тәрж.иск.)*.

Ахун җәнаплары белән кабат күрешеп сөйләшү

Ахун җәнаплары гарәпчә шактый яхшы сөйләшә. Әйтергә-аңлатырга теләгән фикерне җиткерүдә бернинди дә кыенлык юк. Галим кеше. Үзе тәкъва әһеле. Кытайда ислам диненең кайчан тарала башлавы турында сорадым. Башка кытайлар кебек үк, Рәсүлуллаһ заманында Саад бин Әбү Ваккасның (Аллаһның рәхмәтендә булсын) килүе турында әйтте. Мин болай дидем:

– Бу сүз каян чыккан икән? Ислам дине белән бәйле китапларда һәм ислам тарихында сәхабәләрнең тәрҗемәи хәлләре гаять төгәл рәвештә теркәлгән һәм, шуның өстенә әле, Саад бин Әбү Ваккас – сәхабәләрнең иң мәшһүре. Аның ул заманнарда бирегә кадәр килүе турында берни дә әйтелми. Ләкин бу хакта бөтен Кытай голәмәсе диярлек уртак фикердә, бер авыздан бу сүзне сөйлиләр.

Аннары бераздан Ахун җәнапларыннан:

– Моны нәрсә белән раслый аласыз? – дип сорадым.

– Безнең кытай голәмәсе арасында, – диде ул, – элек-электән, гасырдан-гасырга, сәләфтән-сәләфкә, ягъни буыннан-буынга шулай сөйләнә килгән. Моннан 400 ел элек язылган китапларыбыз бар, аларда да нәкъ шулай дип язылган.

– Шулайдыр, тик сезнең бу риваятьләрегез ислам тарихы риваятьләренә туры килми. Саад бин Әбү Ваккасның Сәйидина[6] Османның (Аллаһның рәхмәтендә булсын) хәлифәлегеннән соң, Мәдинә-и Мөнәүвәрәдә вафат булуы могтабәр китаплар белән расланган.

– Без, Саад бин Әбү Ваккас биредә вафат булган, димибез. Безнең голәмәнең риваятенә күрә, Саад бин Әбү Ваккас, сәгадәт, ягъни Рәсүлуллаһ заманында Кантон шәһәренә кадәр килгән һәм алты айга якын шунда яшәгән. Янында ике юлдашы да булган. Юлдашларының берсе – Сәйидина Касыйм – Кантон шәһәрендә вафат булган. Җирләнгән урыны бүгенге көндә дә билгеле. Саад бин Әбү Ваккас салдырган мәчетнең нигезе дә билгеле һәм әлегә кадәр бар. Безнең Кытай голәмәсе барысы да моңа ышана. Кая гына барсагыз да, бу риваятьне ишетерсез. Котәйбәнең[7] килүе дә риваять итеп сөйләнә. Тик, Хәзрәт-е Котәйбә һиҗрәтнең 95 нче елында килгән, диелә. Ул вакытларда инде Кытайда мөселманнар булган. Шунысы да игътибарга лаек: Хәзрәт-е Котәйбә – Кытай Төркестаны аша, ә Саад бин Әбү Ваккас диңгез юлы белән килгән. Бу хакта бер Кытай каһанының әсәре дә бар. Исламиятне бик мактаган: «Кытайда ислам диненең таралуы – кытайлар өчен зур мәртәбә, шәрәф», – дигән. Әсәр моннан 200 ел элек язылган.

– Әйе, шулай булуы мөмкин. Тик гарәп тарихының һәркемгә мәгълүм булган барлык чыганаклары бу мәсьәләдә уртак фикердә тора, ә Сез сөйләгән нәрсәләр һич кенә дә бу чыганакларга туры килми.

– Мин дә әйтәм, мәшһүр булу белән бергә, дөрес булмаган яклары да бардыр. Безнең күз алдыбызда булган Кытай Император сарае вакыйгалары турында ниләр генә язмадылар. Кытай императоры газеталар битендә әллә ничә тапкыр вафат булды. Без һаман яшибез һәм газеталар да вакыйгаларны көнгә икешәр мәртәбә теркәп бардылар. Бүген бигрәк тә сарай кешеләре арасында булган ул вакыйгаларның барлыкка килү рәвеше һәм килеп чыгышы төрледән-төрле һәм бер-берсенә каршы килә торган итеп күрсәтелә. Ярар инде, без – вәхши Шәрыкъ халкы, мәдәни Аурупа халкы да әле утыз ел элек

[6] Сәйидина – чыгышы белән сәетләрдән, ягъни бөек, могтабәр затлардан дигәнне аңлата *(тәрҗ.иск.)*.
[7] Ислам тарихында Котәйбә бин Мүслим (һиҗри 670-715) исеме белән билгеле шәхес *(тәрҗ.иск.)*.

кенә Александр IIнең Петербургта үлеме белән бәйле ниләр генә язмады!.. Ул көнне Александрның җеназасын сарайдан юри генә, күз буяу өчен генә чыгардылармы икәнни? Аннары газеталарыгыз Александр исән дип язмадымы? Шулай булгач, Гарәбстанда әле язу һәм теркәү бик аз булган вакытларда Саад бин Әбү Ваккас турында төрле риваятьләр тумагандыр, дисезме? Тулысынча ялган, дисәгез, җитмеш-сиксән миллион кеше бу чи ялганга ничек ышанган соң алайса? Чынлап та, бар да бер үк сүзне сөйли лә.

– Әйләнә-тирәне җаһиллек сырып алган булса, ялганга бердәм ышану бик җиңел ул. Сиксән миллион гына түгел, ничә йөз миллион христиан хәзрәт-е Гайсәнең Аллаһның улы икәненә ышана, миллионлаган яһүди исә хәзрәт-е Гайсәнең зинадан туган бала булуына ышана. Аллаһ сакласын, җаһиллек китереп чыгарган мондый ышанулар Хак Тәгаләнең кодрәтенә дәлил булып тора алмый.

Ахун җәнаплары кычкырып көлеп җибәрде.

– Бик мавыктыргыч итеп сөйләдегез, бик канәгать калдым. Тагын шуны да әйтергә телим: мин сөйләгән уртак ышану, әйткәнемчә, кытайлар арасында киң таралган. Шунысы да бар: Кытайда исламият бик борынгы күренеш, хөкемдар һәм каһаннар да ислам дине белән шәрәфләнгән заманнар булган. Пекинга барсагыз, күрерсез: Император сараена керү юлындагы мәчет тә моның дөреслегенә дәлил булып тора. Һичшиксез, ул мәчет императорлар тарафыннан төзетелгән. Моны беркем дә кире кага алмас, чөнки болар ачык мәгълүм нәрсәләр. Сез миңа сорауны дөрес бирмәдегез дип уйлыйм. «Исламият кайчаннан башлап сүнүгә йөз тотты?» – дип сорасагыз, дөресрәк булыр иде.

– Әйе, аны да сорыйсы идем. Һәр сорау үз тәртибе белән. Инде килеп, сүзне башлаганбыз икән, ул хакта да фикерегезне әйтсәгез иде. Исламият кайчан сүнүгә йөз тоткан?

– Еларгамы, көләргәме – белмим. Бу юлы сөйлисе сүзләрем дә тарих битләренә теркәлмәгән. Болар да яңа нәрсәләр түгел, бик борынгы, кызганыч вакыйгалар. Моннан 450 ел элек, безнең Кытай мөселманнары Гарәбстаннан Мәккәгә хаҗилар төркеме оештырып, Тибеттан, Бәлүҗистаннан Басра аша Хиҗазга юл ачканнар. Ул вакытларда бу иң кыска юлны бер ел дигәндә үтәргә мөмкин булган. Ул берничә ел шул рәвешле дәвам иткән, гарәпләр белән кытай мөселманнарының бер-берсен якыннан тануына сәбәп булган. Кытай каһанының мөселман булуы да менә шул вакытларга туры килә. Мин даталарны тиешле төгәллеге белән атый алмыйм. Әгәр Сез Нанкингә барсагыз, сорарсыз, анда мәшһүр тарихчылар бар. Алар Сезгә династияләрне атый-атый сөйләрләр. Әмма анда тәрҗемәче таба алырсызмы икән – белмим. Ярар, менә шул заманнарда эчке чолганышлар барлыкка килә. Безнең мөселманнар хәзерлексез, бу фетнәләрдә, чолганышларда җиңелүгә дучар булалар, мәҗүсиләр исә, җиңү яулап, мәмләкәтнең идарәсен үз кулларына алалар. Шуннан соң болар мөселманнарның Хиҗазга баруларын катгый рәвештә тыеп кына калмыйлар, ил эчендәге мөселманнарның бер-берсе белән көрешүләренә дә каршы төшәләр. Нәтиҗәдә, җаһиллек менә бүгенге хәлгә китереп җиткерә.

– Болар хакында кытай тарихында да язылганмы?

– Әйе һәм бик ачык итеп язылган. Мин гарәп телен яхшырак белсәм, бик күп нәрсә тәрҗемә итәр идем. Сезнең гарәпчәгез, мәшәАллаһ, бик яхшы. Дөресен генә әйтим, Сезнең белән танышып сөйләшүемә бик шатмын. Аллаһ Сездән разый булсын!

– Тик мин Сездән шуны үтенеп сорыйм: читтән килгән мөселман кешеләре турында фикер чыгарырга ашыкмагыз, бераз сабырлык һәм хөрмәт белән мөгамәлә күрсәтегез, чөнки бөтен юлчы да теләнче булмый. Аннан соң бөтен юлчы минем кебек Сезнең ул авыр сүзләрегезгә түзеп тора алмас, кардәшлек юкка чыгар. Мин дә Сезнең белән танышуыма шулкадәр сөендем ки, әйтеп-аңлатып бетерерлек түгел. Инде мине кусагыз да китмим: Сезнең белән аралашып, мәгълүмат тупларга телим. Рөхсәт итсәгез, Сезнең белән тагын бер-ике тапкыр күрешеп сөйләшер идем.

– Нәсыйхәтләрегез өчен бик рәхмәтлемен. Әмма гарәпләрнең шундыйлары бар ки, ни дияргә дә белмәссең. Кытайга, Төркестан якларына Мәдинәдән килгән Хәмзә исемле бер гарәп кешесе килде бирегә. Килгәндә меңнәрчә доллар акчасы бар иде. Бар акчасын гөнаһ эшләрдә, зина кылып туздырып бетерде дә: «Юлга акча бирегез», – дип, җаныбызга тиде. 30 доллар бирдек. «Бу аз», – дип, безнең белән талашып гауга чыгарды. «Рәсүлуллаһ – минем бабам, ул сездән разый булмас!» – дип һәм тагын әллә ниләр әйтеп, безгә ләгънәтләр укыды. Шуның артыннан ук Сез килдегез, минем ул хәлләрдән сизгерлегем томаланган иде бугай, гафу итегез!

– Юк, бу әйткәннәрем үзем турында түгел. Мин Сездән бик канәгать һәм Сезгә бик рәхмәтлемен.

Ахун җәнаплары белән шул рәвешле якыннан таныштык.

Мин гел Тензин әйләнә-тирәсендә йөрим. Кая гына барып чыксам да, берәр һинд кешесен очратам. Шул яктан чыгып караганда, бу җирләр, чынлап та, инглиз идарәсе астында калган иде. Болар, вакытына карап, әле полиция кешесе, әле җасус, ягъни шпион була икән, кирәк булса, сәүдәгәр кыяфәтенә дә керәләр, кайчак тикшерүчегә яки хакимгә, ягъни судьяга да әйләнә алалар икән.

Инглизләрнең сәясәтләренә кагылышлы бик зур гыйбрәт дәресе иде бу. Кайда гына очратсаң да, боларның башларында бик зур чалма була. Чалма койрыгы билләренә кадәр салынып төшкән була. Белмәгән кеше, беренче карашка, боларны мөселман дип, хәтта ислам голәмәсе дип уйларга мөмкин.

Һиндстан мәҗүсиләренең башында ул зур чалмаларны күргәч, ирексездән: «Чалма нәрсә икән соң ул алайса?» – дип уйлыйсың.

Кытайда инглиз полиция кешеләре барысы да башына чалма кия. Офицерлар, гаскәриләр дә чалма кия. Ишек төбе сакчылары да чалма киеп дәрәҗә алалар. Безнең ишек төпләрендә торучы «ага» дип атала торган хезмәтчеләрнеке кебек вазыйфаны башкаручылар да башларына чалма кия, ләкин боларының чалма койрыклары озынрак була.

Кытай яр буйларында бөтен һинд мәҗүсиләр бу кыяфәтләре белән мөһим урыннарны кулга төшергәннәр. Бичара кытайлар ул һиндләрне күргәндә Газраилне күргән кебек куркалар. Без үзебез бәйләгән чалма белән бу чалмалар арасында, әлбәттә, аерма булырга тиеш. Тик аны ничек аңлатасың? Мыскыллап карасалар да, дәшми калырга мәҗбүр буласың. Һиндстанның үзендә дә шул ук хәл, кимсетеп карыйлар.

Инде шул һинд мәҗүсиләрнең җирле халыкка булган мөгамәләсе турында сөйләшик. Боларның кулларында һәрвакыт бер метр ярым озынлыгындагы камыш таяк була. Бичара кытай кешесе берәр хата эш эшләсә яки ике сүз артык әйтсә, ул таяк шунда ук мескен кытайның башына төшә.

Инглизләр бу һинд кешеләрен нинди сәләт һәм нинди максат белән шулай эшләтәләр, илнең эчке эшләренә шул рәвешле кайчан тыкшына башлаганнар икән соң?

Бу мәсьәләдә аңлаган нәрсәләремне бередә бераз әйтеп үтәчәкмен, тәртибе белән барып, ара-тирә тәфсилләп тә сөйләрмен.

Моннан якынча җитмеш-сиксән ел элек инглизләр Кытайга кадәр Ханкан шәһәренә килеп, үзләренә буйсынган берничә һинд кешесен шунда калдырып киткәннәр. Киткәндә аларга: «Менә сезгә акча, менә сезгә теге-бу. Сез әлегә монда тауарлар сатып алыгыз, бераздан килеп, без сезне алырбыз», – дигәннәр.

Шул рәвешле бу җирләрдә калган кешеләрнең берсенең улы могтабәр сәүдәгәр Абдуллах Фәкыйрь исемле кеше әле дә шунда гомер итә. Фәкыйрь исеме андагы мөселманнар тарафыннан бирелгән шөһрәт исеме икән. Шуннан соң инглизләр үз боерыкларындагы кешеләрне башта акрынлап көньяк-көнчыгышта, тора-бара бөтен яр буйларында арттырганнан-арттыра барганнар. Бервакыт: «Үз боерыгыбыздагы кешеләр белән идарә итәбез», –дигән сылтау белән, берничә полиция кешесен китереп урнаштырганнар. Аларга ачыктан-ачык: «Бары тик безнең кешеләребез белән генә эш итәсез», – дисәләр дә, кайчак, яшереп кенә, Кытайның эчке эшләренә тыкшынырга да әмер биргәннәр. Кытайлар бу тыкшынуларга каршы чыккан вакытта: «Безнең әмерләрдән читкә чыккан», – дип, тотылган бичара һиндне хәрби трибуналга тапшырганнар. Форсат чыккан саен тыкшыну ягын караганнар. Тора-бара хәлләр бүгенге дәрәҗәгә җиткән. Бүгенге көндә Тензинда Кытай хөкүмәтенең исеме генә бар. Кайбер җирләрдә түрәләр дә бар, тик кытай түрәләрдән ризасыз халык инглиз түрәләргә барып шикаять итә. Инглиз түрәләр золым күрсәтсә, *«Дошманың казый булса, кемгә шикаять итәрсең»* дигән табигый канунга буйсына башлыйлар.

Тензинда китап белән сәүдә итүче бер һинд кешесе бар. Бу кешенең вазыйфасы нидән гыйбарәт – мин моны һич кенә дә аңлый алмадым. Үзе гарәпчә дә, фарсыча да белә. Карап торышка китап сәүдәгәре, тик алай искитәрлек сәүдә дә алып бармый, сәүдәсе бөтенләй юк дәрәҗәсендә. Бер-ике сандык китабы бар. Бу кадәр китап белән сәүдә итү буламы? Әмма китап сәүдәгәре исемен алган. Мин бу кеше белән берничә тапкыр күрешеп сөйләштем, бернинди сәләтен дә сизмәдем дә, күрмәдем дә. Шулай да, менә инде ун еллап, бередә китап белән сәүдә итә, имеш. Бу кешенең сәүдәсе турында ахун җәнапларыннан сорадым:

– Бу кадәр аз китап белән ничек сәүдә итә? Шәхесе турында ни дә булса беләсезме? Кем бу кеше?

– Бу «мөхтәрәм» затның шәһәребезгә килгәненә ун ел булды, – диде. – Ул вакытларда да шул Сез күргән китаплары бар иде, әле дә шул ук китаплар. Үзе инде берничә тапкыр өйләнде, аерылды. Шактый күп акча сарыф итә. Сәүдәсе фәлән булмаса да, кәефе яхшы. Минем акылым бик ирешми. Үзе әле мөселман суфый кеше. Башыбызга бәла булып төште. Инде Мәүләм безне моның начарлыкларыннан саклый күрсен.

Мин Тензинда тагын берничә көн калырга уйлаган идем, ләкин ахун җәнаплары үзенә каядыр китәргә кирәклеген әйтте. Болай булгач, инде мин дә Тензиннан китәргә мәҗбүр булдым. Бу соңгы көнне тагын берничә мәдрәсәне барып карармын, дидем. Мәсҗид-е Җәмигъ мәхәлләсенә бардым. Бередәге мәчет бинасы яңа һәм бик матур иде, мәдрәсәләре дә бик төзек, тик шәкертләре аз. Шәкертләр белән инде таныш идек: гарәп телен фикерләрен белдерә алачак кадәр үк түгел, эндәшеп, сорау бирер дәрәҗәдә генә беләләр.

Төрекчәдән ***Асия Рәхимова*** *тәрҗемәсе* ■

Исмәгыйль хәзрәт Сәлимшин нәсыйхәтләре

Исмәгыйль хәзрәт Сәлимшин

Күркәм дога

Әллаһуммәхфазил-исламә вәл-иманә галәйнә гындәл-мәмәти вәл-хәяти бирахмәтикә йә әрхамәр-рахимиин.

«Йә, Аллаһ! Сакла исламны һәм иманны үлгәндә һәм исән вакытта, Синең рәхмәтең белән, ий, Рәхимлеләрнең Рәхимлесе».

Хикәя

Мөэминнәрдән зур җәмәгать Гомәр хәлифә булган заманда Гали радыаллаһу ганһу (Аллаһ аннан разый булсын) янына килде. Ул мөселманнар хәзрәти Муса белән хәзрәти Хозыр баргач, кунак итмәгән яһүдләрнең нәселеннән иделәр һәм әйттеләр: «Ий, мөэминнәрнең хуҗасы! Без Аллаһы Тәгаләнең берлеге һәм Мөхәммәд саллалаһу галәйһис вәсәлламнең пәйгамбәрлеге белән икърар итүчеләрбез. Сиңа бер хаҗәт белән килдек. Әгәр шул хаҗәтебезне үтәсәң, сиңа ун дөя алтын бирербез», – диделәр.

Гали радыаллаһу ганһу: «Хаҗәтегез нәрсә булыр?» – дип сорады.

«Ий, мөэминнәрнең түрәсе! Һәрбер Коръән укучы безнең бабаларыбызны шелтәли», – диделәр.

Гали хәзрәт: «Бәс, ул авыл халкы Хозыр белән Муса галәйһиссәламне кунак итүдән баш тартты. Бабаларыгыз заманнарының иң сараннары булганнар. Хәзрәти Муса берлә Хозырга ярты күмәч тә бирмәделәр. Мин Аллаһы Тәгаләнең сүзен үзгәртеп, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтеннән сөрелергә кәфер яисә монафикълардан түгелмен», – диде.

Тәнбиһ (кисәтү)

Карендәшләр, белегез, Аллаһы Тәгаләнең юлы мәшәкатьледер. Кабул ителмешләр җөмләсенә керү бик авырдыр. Вакытында кабуллык аз гына нәрсә белән булыр. Әмма вакытыннан соң бик кыйммәтле нәрсә белән дә табылмас. Вакытында ярты күмәч бирсәләр, максудлары (теләкләре) була иде. Әмма вакытыннан соң ун дөядәге алтын белән дә булмады. Бәс, әй, мөэмин, изгелекне вакытында кылырга тырыш. Терек (исән) вакытыңда ярты күмәч берлә тапкан нәрсәне, үлгәч, үзеңне һәм җаныңны биреп тә таба алмассың. Дөньядагы бер изгелеккә ун савап булганда хәзерләнмәсәң, ахирәттә кырык еллык хәзинә берлә дә бер савап таба алмассың.

«Әй, мөэмин, изгелекне вакытында кылырга тырыш. Терек (исән) вакытыңда ярты күмәч берлә тапкан нәрсәне, үлгәч, үзеңне һәм җаныңны биреп тә таба алмассың.

Вәгазьләнүне теләүче хакында

Бер ир (ул заманының галиме булган) олуг бер галим янына килде һәм: «Әй, мөселманнарның имамы, миңа вәгазь кыл, дәхи Аллаһы Тәгаләгә якын була торган нәрсә өйрәт», – дип сорады. Галим әйтте: «Вәгазь кылганчы синең үзеңнән ике мәсьәлә сорамакчы буламын. Әгәр җавап бирсәң, теләгәнчә өйрәтермен», – диде. Бу ир: «Сора», – диде. Галим әйтте: «Аллаһы Тәгалә дөньяны ахирәттән артык иттеме?» – диде. Бу ир: «Аллаһы Тәгалә ахирәтне дөньядан артык кылды», – диде. Шуннан галим: «Әй, ир, син дөньяны ихтыяр итәсеңме (сайлыйсыңмы) яисә ахирәтнеме?» – дип сорады. Бу ир: «Дөньяны ахирәттән күбрәк сөямен», – диде. Шуннан соң галим: «Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вәсәллам байлык-

ны сөя идеме яисә фәкыйрьлекне сөя идеме?» – дип сорады кабаттан. Бу ир: «Рәсүлемез фәкыйрьлекне байлыктан артык күрде һәм фәкыйрьлекне сөйде», – диде. Галим әйтте: «Әй, ир, син фәкыйрьлекне сөясеңме яисә байлыкнымы?» Бу ир: «Мин байлыкны сөямен, фәкыйрьлектән артык күрәмен», – диде. Галим әйтте: «Аллаһы Тәгалә рәхмәт кылсын, хәзер мин сораган нәрсәләргә Аллаһы Тәгалә һәм рәсүлемез теләмәгәнчә җавап бирдең. Бәс, үгет-вәгазь сиңа бик муафыйк булсын, бар кайт, эшеңне төзәт, гадәтеңне алмаштыр. Ахирәтне сөй, дөньяны ким тот, фәкыйрьлекне сөй, байлыкны ким тот. Шайтанны дошман тот. Бу рәвештә эшләсәң, Аллаһы Тәгаләнең сөеклеләреннән булып, җәннәт әһеленнән булырсың», – диде. Бу турыда Аллаһы Тәгалә: «Сез хатыннарыгыз белән шатланып җәннәткә керегез», – дигән («Зүхъруф», 70).

> «
> **Аллаһы Тәгалә: «Сез хатыннарыгыз белән шатланып җәннәткә керегез», – дигән.**

Хикәя

Нуширван залим, патша атасы үлгәннән соң, патша булып утырды. Көннәрнең берендә галимнәрне, акыллыларны һәм хакимнәрне җыйды һәм: «Дөньяда күркәмрәк ни нәрсәдер?» – дип сорады. Бу кешеләрдән һәр кайсысы бертөрле нәрсәне әйттеләр. Әмма Нуширванга берсе дә ошамады. Болар арасында бик әдәпле заманаларның артыграк булган бер галим ире бар иде. Шул ир: «Дөньяда өч нәрсәдән артык күркәм нәрсә юк», – диде. Нуширван: «Ни нәрсәләр?» – диде. Бу ир әйтте: «Әүвәл – үлем, икенчесе – хатыннар, өченчесе – мохтаҗлык», – диде. Нуширван: «Дөньяда болардан начар нәрсә юк», – диде. Һәм: «Нинди дәлил белән әйтәсең?» – дип сорады. Бу галим әйтте: «Үлем яхшы, чөнки син үлем сәбәпле патша булдың. Әгәр үлем булмаса, атаң үлмәс иде һәм син патша була алмас идең. Хатыннар яхшы, чөнки хатыннар булмаса, син бар булып патша булмас идең. Һәм мохтаҗлык яхшы шуның өчен: мохтаҗлык булмаса, олуг галимнәр һәм гаскәрләр сиңа буйсынмаслар иде», – диде. Патша, рас (дөрес) әйттең, дип теге галимгә йөз мең алтын бирде һәм өч сүз өчен яхшы киемнәр кидерде. Әй, мөэмин, бик бел син, бу олуг галим патшасы каршында җавапны биреп, мохтаҗлыкны белдерткәндә, ул патшадан йөз мең алтын алды. Бәс, мөэмин кол хөрмәтле булган Аллаһы Тәгалә каршында хаҗәтне белдерсә, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтеннән булган вакытта сөенеч, кабердә сәламәтлек табар. Бу турыда Аллаһы Тәгалә: «Ий, минем колларым, сезгә бүген курку булмас һәм сез кайгырмассыз», – дигән («Зүхъруф», 70).

Дәхи җәннәттә мөлекне (байлыкны) табар, чөнки Аллаһы Тәгалә әйткән:

«Әгәр җәннәткә карасаң, анда нигъмәт вә бөек мөлкәт күрерсең», – дигән («Инсан», 20).

Текстны басмага
***Сиринә Сәлимшина-Шаһимәрданова** әзерләде.* ■

Безнең мирас №9 сентябрь 2021

САБЫЙЛАР ӨЧЕН ДИНИ МИРАС

Дин дәресләре

Сөнгатулла Бикбулат

Өченче дәрес
Дога вә гыйбадәт

Мөгаллим: Бөтен дөньяны кем яралткан дигән идек әле?

Шәкерт: Аллаһы Тәгалә яралткан дигән идек.

Мөгаллим: Алай булгач, бөтен дөнья вә дөньядагы нәрсәләр кемнеке була?

Шәкерт: Аллаһы Тәгаләнеке була.

Мөгаллим: Әлбәттә, Аллаһы Тәгаләнеке. Менә без бер өй салып керсәк, ул безнеке була бит. Шуның шикелле Аллаһы Тәгалә яралткан бөтен дөньядагы нәрсәләр дә Аныкы. Шулай ук без дә Аныкы. Икенче төрле әйтсәк, без барыбыз да Аллаһы Тәгаләнең коллары вә бәндәләребез. Без, адәм балалары, Аллаһы Тәгалә яралткан нәрсәләр белән ни эшлибез әле?

> « Аллаһы Тәгалә яралткан бөтен дөньядагы нәрсәләр дә Аныкы. Шулай ук без дә Аныкы.

Шәкерт: Файдаланабыз.

Мөгаллим: Димәк, Аллаһы Тәгалә безгә ул нәрсәләрне файдаланырга биргән. Соң бу нәрсәләрне Аллаһы Тәгаләнең безнең кулыбыздан алырга кодрәтеннән киләме?

Шәкерт: Килә.

Мөгаллим: Әлбәттә, килә. Аның һәрнәрсәгә көче җитә. Аның бирергә дә, биргән нәрсәләрен алырга да көче җитә. Ул безгә сәламәтлек биргән. Шул биргән сәламәтлеген алып, авыру да ясый, үтерә дә ала. Безгә яңгыр яудырмыйча игенсез, үлән вә печәнсез калдырырга да кодрәтеннән килә. Күлләребезне, елгаларыбызны корытып сусыз калдырырга да көче җитә. Аллаһы Тәгаләнең безгә үзенең рәхмәте белән биргән нәрсәләрен барысын да кире алырга кодрәте бар. Шулай түгелме, Габдуллаһ?

Шәкерт: Шулай, Аллаһы Тәгаләнең боларның барысын да алырга көче җитә.

Мөгаллим: Алай булгач, безгә Аллаһы Тәгаләдән шул биргән нигъмәтләрен кире алмавын сорарга кирәк. Безгә ул сәламәтлек биргән. Шул сәламәтлегебезне алмавын, авыру булсак, авыруларыбыздан савыктыруын, сәламәт итүен, чәчкән игеннәребезгә яңгыр яудыруын, төрле афәт вә бәлаләрдән, мал-туарларыбызны авырулардан, казалардан саклавын сорарга кирәк. Беләсезме, Аллаһы Тәгаләдән сораугa ни дип әйтәләр?

Шәкертләр: ???

Дәвамы. Башы журналның 7 нче (2021) санында.

Мөгаллим: Аллаһы Тәгаләдән сорауга дога кылу дип әйтәләр.

Мөгаллим: Истә калдырдыңмы: Аллаһы Тәгаләдән сорауга нәрсә диләр?

Шәкерт: Дога кылу, диләр.

Мөгаллим: Безгә кирәк нәрсәләрне Аллаһы Тәгаләдән һәрвакыт сорарга, ягъни Аңа дога кылырга кирәк. Син әнкәңнән берәр нәрсә сорасаң, ни дип сорыйсың?

Шәкерт: «Әнкәй, бир әле?..» – дип сорыйм.

Мөгаллим: Шулай дисең шул. Аллаһы Тәгаләдән сораганда да шулай сорыйсың. Аңа: «Ий Раббым, мине бәхетле, тәүфыйклы, укымышлы кыл; Ий Ходаем, ата-анама, мөгаллимемә сәламәтлек бир, гомерләрен озын кыл; Илаһым, киң ризыкларыңны бир, килер җирләрен киң кыл; Ий Раббым, малларыбызга бәрәкәт бир, бәла-казаларыңнан, афәтләреңнән сакла», – дисең.

Аллаһы Тәгалә безне дөньядагы бөтен нәрсәләрдән файдаланырга ирекле кылган, аларны безгә биргән, дигән идек. Бу нәрсәләрне Ул безгә бушлай биргәнме, әллә берәр нәрсә биргәнгә каршымы?

Шәкерт: Бушлай биргән.

Мөгаллим: Менә берәү сиңа бушлай бернәрсә бирсә, син аңа ни әйтәсең?

Шәкерт: Рәхмәт әйтәм.

Мөгаллим: Әлбәттә, рәхмәт әйтәсең, аңа шөкерана кыласың. Яхшылык кылган кешегә һәрвакыт шулай рәхмәт әйтергә, шөкерана кылырга бурычлыбыз. Шулай булгач, без Аллаһы Тәгаләгә мондый бушлай биргән нигъмәтләре өчен ни эшләргә тиеш?

Шәкерт: Аллаһы Тәгаләнең биргәненә шөкер итәргә, Аңа рәхмәт әйтергә кирәк.

Мөгаллим: Әлбәттә, шөкерана кылырга. Тик Аллаһы Тәгаләгә шөкерана кылу инсаннарга шөкерана кылу төсле булмый, башкача була. Аңа Үзе ничек шөкерана кылырга кушкан булса, шулай шөкерана кылырга тиешбез. Аңарга шөкерана кылуга гыйбадәт дип әйтәләр. Без Аллаһы Тәгаләгә нинди гыйбадәт кылабыз, кем белә?

Шәкертләр кул күтәрәләр.

Мөгаллим: Йә, Габдуллаһ, сөйлә: нинди гыйбадәт кылабыз?

Шәкерт: Намаз укыйбыз.

Мөгаллим: Бик дөрес әйттең. Без намаз укыйбыз. Намаз ул – гыйбадәт. Без Аллаһы Тәгаләнең биргән нигъмәтләренә шөкерана йөзеннән ошбу гыйбадәтне үтибез.

Мөгаллим: Без тагы нинди гыйбадәт кылабыз?

Шәкерт: Руза тотабыз.

Мөгаллим: Бик дөрес әйттең. Руза тоту да – шулай ук бер гыйбадәт. Әле болардан башка да гыйбадәтләр бар. Киләчәк дәресләрдә сезгә аларның барысын да сөйләрмен әле.

*Текстны басмага **Мәдинә Әбделганиева** әзерләде.* ■

Гамьле затлар онытылмый

Тәлгать Галиуллин, филология фәннәре докторы

Мирза Мәхмүтов

Уртак илебезнең бәйсезлеге, мөстәкыйльлеге өчен үзләрен аямыйча, Муса Җәлил һәм аның иңдәшләре кебек, җәллад балтасы баш очларында эленеп торганда да антларына хилафлык итмәгән, беришесенең кылган гамәлләре билгесезлектә калган шәхесләребезнең бихисап булуы мәгълүм. Сугыш батырларын даими искә алып торабыз. Күптән түгел янә бер мактанычыбыз – Исхак Әхмәровның, Америкада яшерен резиденция башлыгы буларак, олы серне – Япониянең СССРга һөҗүм итмәвен ачыклап хәбәр итеп, Көнчыгыштагы дивизияләрне башкала ягына күчереп, Мәскәүне саклап калуга үз өлешен кертүе ачыкланды. Якташы турында роман язып, Р.Корбан аның исемен мәңгеләштерүгә үз өлешен кертте.

Татарның төрле төбәкләрдән чыгып, сугыштан соңгы чорда да, чит илләрдә ифрат җаваплы вазыйфалар үтәсә дә, батырлыклары галиҗәнап тарих

төпкелендә калып, серләрен үзләре белән мәңгелеккә алып киткән асыл затларыбыз шактый икән.

Алар чит илләрдә башкарган гамәлләренә табу, телләренә «йозак салып», Татарстанда яшәү чорында да үз-үзләрен тотышлары, милли рухны сакларга омтылулары белән үрнәк-өлге булып, сокландырып яши, эшли алдылар. Ошбу язмаларымда үзем даими аралашкан, яхшы белгән ике олуг шәхес, фән докторлары, профессорлар, әллә ничаклы мактаулы дәрәҗәләргә лаек булган Мирза Мәхмүтов белән Габделҗәмил Зәйнуллиннарны хөрмәт белән искә алып китмәкче булам. Алар – чит-ят илләрдә дә сынатмыйча, татар халкының намусына тап төшермичә яшәп-эшләп кайтып, биредә дә роман-кыйссаларга торырлык хезмәтләр башкарган шәхесләр. Тормыш юлларында ачылып бетмәгән «серле» якынлыклар, тыныч тормыштагы хезмәтләре, үтәгән вазыйфалары арасында уртаклыклар бихисап. Иң әүвәл шуны искәртәсе килә: икесе дә гарәп телен, кем әйтмешли, «су кебек эчеп», фарсы, төрек, инглиз лөгатьләрендә дә аралаша алган зыялы затларыбыз иде. Бу шәхесләр милләт яшәешен кайгыртып, тарихыбызны, мәдәни мирасыбызны, күркәм гореф-гадәтләребезне саклау өчен җан атып яшәделәр.

Кем ул Мирза Мәхмүтов?

Еш кына аларның фани дөньяда яшәве турында бөтенләй белмәгән, ишетмәгән шәхесләр күңелең түрендә урын ала, гомерлеккә рухи юлдашың була.

1956 елның сентябрь ае. Тарих-филология факультетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә керү бәхетенә ирешкән студентлар (ул елларда бу белгечлеккә конкурс зур иде) аудиториядә гарәп теле укытучысын – башка елларда ул дәресләрне алып барган, өлкән яшьтәге, бик мөхтәрәм шәхес Гаяз ага Ишмөхәммәтовны көтеп утырабыз. Менә ишек ачыла һәм аудиториягә аның урынына башка – озын, төз гәүдәле, күперенке коңгырт чәчле, бик пөхтә-ыспай киенгән, кыскасы, ирләрне бизи торган бар сыйфатларга ия, аңлавыбызча, яңа укытучы килеп керә. Кызларыбыз (араларында берничә ел эшләп килгәннәре дә бар иде) нинди хисләр кичергәндер – әйтә алмыйм, без, җилкенчәкләр, бирсә бирә икән Ходай яратканына, дип имәнеп китеп, аһ иттек.

Ул, хәрбиләрчә тигез атлап мөнбәр янына килеп җитеп, күзен безнең өстән йөгерткәч кенә:

– Исәнмесез! Утырыгыз, – диде һәм: – Бүген генә татарча исәнләшәбез, киләсе атнадан, иншәАллаһ, гарәпчәгә күчәрбез, – дип өстәде.

Үзе белән таныштыруы бик кыска, мәгәр истә-ятта, хәтердә калырлык булды.

– Минем исемем Мирза, Әмирзадә дигән укымышлы, зыялы мәгънәсен аңлаткан сүзнең кыскартылган шәкеле. «Шәкел»нең мәгънәсен аңлыйсызмы? Калыбы, формасы дигән сүз. Кыскасы, мин сезнең яңа укытучыгыз Мирза Исмәгыйль улы Мәхмүтов булам.

Безне укыткан өч семестрда үзе турында башка ләм-мим сүз әйтмәде.

Әүвәл ул кыскача гына гарәп теленең дөньякүләм әһәмияте, таралыш даирәсе белән таныштырып үтте дә тактага аңлатмалары белән гарәп әлифбасын яза башлады. Аның дәрес барышында урындыкка утырганын яисә, таләпчән булып кыланып, кайбер укытучылар кебек, вакыт уздыру өчен студентларның дәрестә булу-булмауларын тикшереп, старостаның башын катырганы булмады.

Мөгаллимебезнең тормыш юлы белән ул ТАССР Югары Советына депутат буларак сайланганда гына таныштык*.

Мирза Исмәгыйль улы Мәхмүтов 1926 елда Бакуда дөньяга килсә дә, бала чагыннан ук әти-әнисе белән туган якларында – Мордовиянең Ромодан районының Алтары авылында яшәгән. Ул, шунда мәктәпне тәмамлап, кыска вакытлы курсларда укып алганнан соң, механизатор булып эшли. Ватан сугышында разведчик вазыйфаларын башкара. 1945-1950 нче елларда чит телләр хәрби институтының көнчыгыш факультетын уңышлы гына тәмамлый һәм гарәп илләренә «эш»кә җибәрелә. Мирза Мәхмүтов, шактый вакыт күз алдыннан «югалып» торганнан соң, үткән гасырның илленче еллары уртасында Казанда пәйда була. Җитәкче даирәләр аңа хәерхак булып, торак мәсьәләсендә ярдәм итсәләр дә, аңа тулаем алганда гамәли көнен үзенә күрү «мөмкинлеге» бирелә. Максатчан, әзерлекле егеткә шактый сикәлтәле юллар аша үтәргә туры килә. Мирза Мәхмүтов әүвәл Казан университетының кульъязмалар бүлегендә эшли, шунда гарәп телен камил белүе ачыклангач, аны укыту эшенә тәгаенлиләр һәм ул безнең төркемнең һәм бездән соң килгән берничә буынның гарәп теленә ихтирам уяткан мөгаллиме булып китә.

Аңа татар әдәбияты тарихын рәсми уку йортында өйрәнергә насыйп булмаган икән. Шуны истә тотып, милли классикабызны чын-чынлап, шул ук вакытта үзе алып барган дәресләр белән бәйләп, ныклап үзләштерү әмәлен тапты ул. Без шуның шаһитлары да, катнашучылары да булдык. Бер көнне Тукай, икенче юлы Дәрдемәнд, соңрак Ш.Бабич, С.Сөнчәләй, С.Рәмиев иҗатларындагы гарәп алынмаларын, гаруз шигырь системасы чагылышын өйрәндек. Ул гына да түгел, бергәләп кыска-кыска өзекләрне гарәпчәгә тәрҗемә иттек.

Соңрак үзем дә күп еллар укытучы, ректор, декан, кафедра мөдире булып эшләү чорында аның дәрес алып бару алымнарының (хәтта интуитив рәвештә булса да) шактый камил булуын бәяли алдым.

Шулай берничә ел иренмичә, кимсенмичә (аның шактый саллы хәрби дәрәҗәсе булуы да ачыкланды) гади укытучы булып йөреп, кандидатлык диссертациясен яклады, озак та үтми, мәгариф министры дәрәҗәсенә күтәрелде.

Мирза Мәхмүтовның 18 ел дәвамында министр буларак Татарстанның мәгариф системасы белән шактый уңышлы җитәкчелек итүе генә дә аның һәр яктан әзерлекле шәхес булуына бер дәлил иде. Мин белгән министрлар арасында шулай озак еллар эшләгән, аның кебек зыялы, мәгърифәтле, милләт мәнфәгатьләрен яклауда кыю, әзерлекле, Мәскәү түрәләре белән аяк терәп сөйләшү дәрәҗәсенә күтәрелгән шәхесне хәтерләмим. Шуның өстенә, Мирза Мәхмүтов административ эшне һәрдаим фәнни эзләнүләр, яшь алмаш әзерләү белән бәйләп алып барды. Педагогика, методика үсешен өйрәнү, яңа анализ алымнарын гамәлгә кертү юнәлешен үзәккә куйган фәнни-гамәли институт ачып, түрәлектән киткәч, аның директоры булып эшләде. «Проблемалы укыту» нәзарияте аны Бөтенсоюз аренасына чыгарды, иң күренекле педагоглар белән бер сафка куйды, иң мәртәбәле дәрәҗәләр алып килде. Саный башласаң, исең-акылың китәр. Ул – СССР педагогика фәннәре академиясе, Татарстан һәм Нью-Йорк Фәннәр академияләре әгъзасы, гомуми һәм тарихи педагогика һәм укыту методикасы буенча 500дән артык фәнни хезмәтләр, шул исәптән монографияләр, сүзлекләр авторы, бик күп фән докторларының,

* М.Мәхмүтовның биографиясе турында Әгъзам Фәйзрахманов «Ике министр» мәкаләсендә шактый мәгълүмат бирә. («Безнең Мирас». – 2020. – №1. – Б.91-93.)

кандидатларның җитәкчесе. Нинди генә җаваплы урыннар биләсә дә, Мирза Мәхмүтовны якыннан белмәгән кешеләргә эрерәк, тәкәллефлерәк күренсә дә, ул чынлыкта ярдәмчел, бөеклегендә гади кеше булып кала алды.

Университеттан киткәч тә, үзе укыткан шәкертләрен онытмады, һәрдаим игътибар үзәгендә тотты, үсешебезгә ярдәм итәргә тырышты. Аерым алганда, миңа, хәзер инде күренекле тел галиме Фәрит Юсуповка, педагогика фәне, тарихы буенча Мәскәүгә аспирантурага барырга тәкъдим итте. Без, рәхмәт әйтеп, баш тарттык (бәлки, ашыкканбыздыр?). Мөгаллимебез үпкәләмәде, артык кыстамады (анысы да зыялылык билгесе). Мәгәр барыбер бүлмәсенә (ул заманда Министрлык Кремльдә урнашкан иде) чәй керттереп, «сапыйлар»ны сыйлап җибәрде.

Алдагы елларда да, үзе укыткан студентларына яхшы мөгамәләсен саклады, мөмкин булган кадәр ярдәмен күрсәтеп яшәде. Җөмһүриятебезнең күренекле шәхесләренең берсе буларак, Мирза Мәхмүтовның ярдәм итү мөмкинлекләре зур, киңәш-табыш бирердәй акылы камил иде. Алабуга пединститутында эшләгән чорда мәктәпләр, район, шәһәр мәгариф бүлекләре мәшәкатьләре белән килгәндә, ул «безләр»не дә чакырттыра һәм җирле түрәләргә «минем шәкертем», дип, абруемны күтәреп җибәрә торган булды. Яңа белгечлекләр, факультетлар ачканда аның белән киңәшә торган идем. Мин ректор буларак эшли башлаганда институтта өч классик факультет булса, аларны сигезгә җиткерергә насыйп әйләде. Яр Чаллы шәһәре үсеп киткәч, укытучы кадрларга ихтыяҗ тууны истә тотып, балалар бакчалары тәрбиячеләрен, башлангыч сыйныф укытучыларын әзерләүче факультетларны шунда күчерү идеясен дә министр хуплады. Хәзер ул мөстәкыйль югары уку йорты буларак тернәкләнеп китте.

Алдагы елларда да, инде мин Казанга әйләнеп кайткач та, Мирза Исмәгыйль улы белән күрешкәләп тордык, аерым алганда, 1994 елда хаҗга баручылар арасында бергә туры килдек. Ул инде ике елдан җитмешенә аяк басарга әзерләнсә дә, изге кәгъбә ташы тирәсендә әйләнгәндә бер ботинкасын гарип кешеләрне күтәреп йөгергән таза негрлар таптап үтсә дә, бирешмәде, үз бурычын намус белән үтәде.

Кичләрен төрле төбәкләрдән җыелган татарлар белән шактый сөйләшеп утырдык. Мирза Мәхмүтовны яхшы белгән, аның белән аралашасы килгән кешеләр дә җитәрлек иде. Бер әрсезе (идәнгә ташланган матраста аунап ятканда барыбызның да хокуклары тигез) аның кем икәнен танып, чит илләрдә яшәвенә, эшләвенә бәйле сорау бирде. Ул үзен совет фильмнарында күрсәтелгән «партизаннарча» тотты, ягъни әүвәл ишетмәмешкә салышты, аннары әңгәмәне акыллы гына икенче ерганакка борып җибәрде (хәтерем ялгышмаса, көндез югалткан туфли сыңары турында бугай). Кыскасы, чит мәмләкәтләрдә кылган гамәлләренең күбесен (әлбәттә, тиешле оешмалар барысын да белгәндер, ил куйган бурычларны җиренә җиткереп үтәмәсә, болай үстермәсләр иде) 2008 елның 16 мартында мәңгелеккә үзе белән алып китте. Әмма аның татар мәгърифәте, мәгарифе үсешенә керткән хезмәте, фәнни, гыйльми мирасы казанышларга бай, табышларга ифрат күпкырлы. Аларына «йозак салынмаган» һәм алар безнең рухи кыйммәтләребезнең күренекле өлешен тәшкил итәләр.

Ахыры киләсе санда ■

Нәсел

Локман Закиров

Вагыйзь Гарифуллин (сулда) авылдашы белән

Бик рәхәтләнеп Ринат Хәйруллинның «Безнең мирас» журналының 2021 елгы 7 санындагы Вагыйзь Гарифуллин һәм Хәлим Сәлаховка багышланган «Мамадышның мәшһүр рәисләре» дигән мәкаләсен укып чыктым. Хәлим әле яшь, шуңа күрә аның турында ишетеп кенә беләм, ә менә Вагыйзь белән сугышка кадәр үк Түбән Ушмы җидееллык мәктәбен, соңрак Мамадыш педагогика училищесын тәмамладык. Аннан соң безнең юллар аерылды: мин, хәрби училище тәмамлап, озак еллар Совет Армиясе офицеры булып хезмәт итеп, Татарстанга пенсионер булып кайттым, ә шул елларда Вагыйзь Гарифуллин танылган рәис булып җиткән.

Ринат Хәйруллин мәкаләсендәге теманы дәвам итеп, атаклы керәстиян Гарифуллиннар нәселе хакында берничә сүз әйтәсем килә. Әтиемнең сөйләве буенча, Гарифуллиннар нәселеннән булган Вагыйзьнең ерак абыйсы Түбән Ушмының бай керәстияны буларак, Николай II патша заманында тау битенең 3 гектар җирендә зур алма бакчасы үстерә. Соңрак Совет хакимияте елларында ул бакча колхозныкы булып китте. Кулакларга каршы көрәш башлангач, Вагыйзьнең ерак абыйсы гаиләсе белән бөтенләйгә туган авылыннан китә һәм читтә вафат була. Вагыйзьнең өлкән апасы Зөләйха дәһшәтле сугыш елларында (1941-1945) Түбән Ушмының Авыл Советы рәисе булып эшләде һәм бөек юлбашчы Сталинның «Барысы да фронт өчен!» дигән законы белән колхозда җыелган уңышны соңгы бөртегенә кадәр хөкүмәткә тапшырып барды. Әмма сугыш бетүгә үк ул, шул ук Сталинның «Урыннардагы өзеклекләр өчен» законы белән, төрмәгә озатылды.

Бу күптәнге вакыйгалар шуның белән дә истә калды: педучилищеда укыган елларда мин җәйге каникуллар вакытында колхозның алма бакчасына каравылчы булып урнашып, үземә хезмәт көннәре эшләдем. Пенсионер булгач та, Түбән Ушмыда яшәүче үземнең өлкән яшьтәге әти-әниләремнең хәлен белергә еш кайта идем, моның өчен Горький автомобиль заводында чикләнгән күләмдә генә генераллар һәм авыл хуҗалыгы чиновниклары өчен чыгарылган иске вездеход М-72 («Победа») сатып алдым. Бу могҗизада авылның юлсыз урамнары буйлап «йөзеп» үткәндә, бөтен авыл халкы мине кызыксынып күзәтә иде: әти-әни йортына «йөзеп» җитә аламмы-юкмы.

Вагыйзьнең кече энеләренең берсе – Салих Гарифуллин, Алабуга укытучылар институтын тәмамлагач, армиядә гади солдат булып хезмәт итте, аннан, нишләптер, Казанның атаклы психиатрия хастаханәсенә кайтарылды. Имеш-

Түбән Ушмы зиратындагы кабер ташлары

Вагыйзь Гарифулла улы Гарифуллин (1927-1975)

Зиннәтулла Гарифулла улы (1930-1975)

Салих Гарифулла улы Гобәйдуллин (1929-1975)

Илсур Аппаков фотолары

мимешләргә караганда, армиядә ул кырыс хөкем ителеп, озак елларга күз уңыннан югала. Аны күпләр хәбәрсез югалган дип санаган иде, әмма Салих 1970 нче елларда Казан шәһәре урамнарында сукбай рәвешендәрәк күренә. Хәтта җәй көне дә җылы мамык чалбардан, брезент плащтан һәм бүректән йөри Салих. Милиционерларны ул кулын тузган бүрегенә куеп сәламли, һәм шәһәр транспортына комачаулап, юл аша ярамаган урыннан чыкканда да алар аңа кагылмыйлар иде. Хакимият өчен куркынычсыз булгач, аны каникулларга җибәргәннәрдер инде. Һәм бервакытны, чираттагы каникул вакытында үз туган абыйсы Вагыйзьләрдә кунакта чакта, психиатрия хастаханәсенә кайту турында повестка алгач, Салих төнлә мунчада асылынып үлә.

Бәхетсезлеккә каршы, икенче көнне үк Салихны күмү өчен кабер такталары әзерләгәндә, колхоз столяркасында Вагыйзь үзе дә үлеп китте. Шул ук айда берьюлы ике абыйсының үлемен кичерә алмыйча, башына кан савып Вагыйзьнең иң кече энесе, колхоз ветеринары Зиннәтулла да вафат булды. Алар барысы да Түбән Ушмы зиратында янәшә җирләнгәннәр.

Бу вакыйгалардан соң берничә ел үткәч, Вагыйзьнең бердәнбер улы – Чаллының 48 яшьлек уңышлы эшмәкәре Шамил Гарифуллин үлеп китте. Вагыйзьнең хатыны Асия Гарифуллина, Лаешта өлкән яшькә җитеп, күптән түгел генә вафат булды. Аллага шөкер, Гарифуллиннар нәселеннән Вагыйзьнең кызы бүген исән-сау. ■

Безнең мирас №9 сентябрь 2021

КАРА ТӘКЪДИР

(Ачы язмышлы шәхесләр)

КАДЫЙР ЫРГАТ (1905-1945)

Чын исеме – Хәлил Җәмил улы Кадыйров. Кырымтатар шагыйре. Таврия губернасының Акмәчет өязендәге Ускут авылында туган. 1934 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы. 1939 елда, хаксызга гаепләнеп, кулга алына. 1939 елда аклана.

1945 елның 26 гыйнварында Зорино авылы (1946 елга кадәр – Поппендорф, Кенигсбергтан 50 чакрым ераклыкта) янындагы сугышта һәлак була. Шунда туганнар каберлегенә дәфен ителгән.

КАМАЛОВА ГӨЛСЕМ (1889-1957)

Өммегөлсем Камалова-Акчурина. Шәфкать туташы. Татарстанның Чистай шәһәрендә Закир ишан Габделваһапов-Камалов гаиләсендә туган. 1912 елда Балкан сугышы вакытында Төркия ягыннан шәфкать туташы («Һиляле Әхмәр» («Кызыл ай») хәрби лазаретында) буларак катнаша.

Ире Габдулла Акчурин 1933 елда вафат була. Гөлсем Камалова совет власте тарафыннан «чит элемент» буларак эзәрлекләнә, аны пантюркистлыкта гаеплиләр. Г.Камалова 1957 елда Казанда вафат була һәм татар зиратында җирләнә.

Өммегөлсем Камалованың язмышы турында Роза Туфитуллова «Язмыш җиле» дигән роман язды. Әлеге роман Төркиядә «Гөлсем» исеме белән төрек телендә басылып чыкты.

Дәвамы. Башы журналның 10 нчы (2020) санында.

Безнен мирас №9 сентябрь 2021

КАМАЛ ХИСАМ (1926-2016)

Татар язучысы. 1926 елның 14 апрелендә Татарстанның Әлмәт төбәгендәге Кама-Исмәгыйль авылында колхозчылар гаиләсендә туган. 1943 елның җәендә яралана, өч айдан кабат сугышка китә, 1945 елның 26 февралендә тагын яралана. Госпитальдән 1946 елда бер аягын төптән кистереп кайта. 2016 елның 2 ноябрендә Казанда вафат була һәм Киндерле зиратында җирләнә.

КАМАЛ ӘГЪЗАМ (1918-1943)

Татар шагыйре. 1918 елның 21 гыйнварында Татарстанның Апас төбәгендәге Үтәмеш авылында ярлы игенче гаиләсендә туган. 1939 елда армиягә алына.

1943 елның 16 маенда Сталинград өчен барган сугышларда һәлак була.

КАМАЛИ ЗЫЯ (1873-1939)

Зыяэддин әл-Камали (Зыяэддин Җамалетдин улы Камалетдинов) 1873 елның 21 декабрендә Уфа губернасының Кара Якуп волостендагы Келәш авылында фәкыйрь игенче гаиләсендә туган.

1936 елда советларга каршы эш йөртә дип ялган гаеп ташлап, бер төркем руханилар белән бергә аны да кулга алалар һәм җиде елга зинданга ябалар. Җәзалауларга түзә алмыйча, ул 1939 елда (кайбер чыганакларда – 1942 елда) Самара төрмәсендә һәлак була. Каберенең кайдалыгы билгесез.

КАМСКАЯ ГӨЛСЕМ (1901-1975)

Гөлсем Сәйфулла кызы Ильясова. Татар артисткасы. 1901 елның 25 мартында Казанда туган.

Гөлсем ханымның ирен – режиссер Гали Ильясовны, ялган гаеп тагып, төрмәгә ябалар. «Халык дошманы»ның хатыны буларак, Гөлсем ханым да бер ел зинданда утырып чыга. Язмышның ачысын-төчесен күп татыган актриса 1975 елның 8 декабрендә вафат була.

*Текстны басмага **Рабит Батулла** әзерләде.* ■

Истә, һаман да истә!

Биохимик
Диләвәр Зөбәеровның
туууына 90 ел

Биохимик, медицина фәннәре докторы (1965), академик (1992), ТАССРның (1976) һәм РФнең атказанган фән эшлеклесе (1997) Диләвәр Мирза-Габдулла улы Зөбәеров 1931 елның 5 сентябрендә табиб гаиләсендә туган.

1955 елда ул Казан медицина институтын тәмамлый. 256 фәнни хезмәт, 6 монография һәм 1 дәреслек (өч мәртәбә басылган) авторы. 36 ел «Казанский медицинский журнал»ның баш редакторы (1961 елдан 1974 елга кадәр әлеге басмада җаваплы сәркатип вазыйфасын башкара) була.

Д.Зөбәеров 2010 елның 22 сентябрендә вафат булды.

Язучы
Хәниф Хәйруллинның
туууына 90 ел

Язучы, ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1981), 1974 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы Хәниф Хәйруллин 1931 елның 12 сентябрендә ТАССРның Сарман районы үзәге Сарман авылында туган.

Сарман урта мәктәбен (1950), Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген (1956) тәмамлый. Урта мәктәпне тәмамлагач, бер ел Сарман районының Азалак авылы мәктәбендә укыта.

1956-1993 нче елларда ул Сарман районы газетасында (башта «Югары уңыш өчен», соңрак «Ленинчы» (хәзерге «Сарман» газетасы), район газеталары бетерелгәч, Буа авыл хуҗалыгы производство идарәсенең фирка комитеты газетасында хатлар бүлеге мөдире, җаваплы сәркатип, мөхәррир булып, «Социалистик Татарстан» газетасының үз хәбәрчесе булып эшли.

Х.Хәйруллин 1998 елның 18 июнендә Казанда вафат булды.

Шагыйрь
Исхак Закировның
туууына 110 ел

Шагыйрь Исхак Кадыйр улы Закиров 1911 елның 14 сентябрендә Казан шәһәрендә туган. М.Вахитов исемендәге татар урта мәктәбендә җиде класс белем алганнан соң, хисапчылар курсын, аннары, читтән торып укып, Казан финанс-экономика институтын тәмамлый. Шигырьләре көндәлек матбугатта 1929 елдан басыла башлый. 1934-1941 нче елларда башта Татарстан дәүләт нәшриятында, соңыннан Татарстан язучылар союзында хисапчы булып эшли. Бөек Ватан сугышы башлану белән, фронтка китә, Белоруссия җирләренә кадәр барып җитә. 1944 елның 14 июлендә Витебск өлкәсенең Городилово авылы тирәсендә барган каты сугышта каһарманнарча һәлак була.

И.Закиров иҗатының аерым үрнәкләре «Татар поэзиясе антологиясе» (1956), «Җыр һаман яңгырый» (1956), «Алар сафта» (1961) һәм «Утлы еллар поэзиясе» (1972) исемле җыентыкларга кертелгән.

Артист
Хәлил Әбҗәлиловның
туына 125 ел

Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты, Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләге лауреаты (1958), СССРның халык артисты (1957) Хәлил Гали улы Әбҗәлилов 1896 елның 29 сентябрендә Оренбург губернасының Шарлык өязендәге Мостафа авылында туа. Шагыйрь М.Җәлилнең туганнан туган абыйсы.

1918 елда Х.Әбҗәлилов «Ширкәт» труппасында уйный башлый. Гражданнар сугышы елларында фронт театр бригадаларында эшли. 1920-1922 нче елларда – Хивә һәм Бохара татар театрларында, 1923-1924 нче елларда Әстерхан дәүләт татар театрында иҗат итә.

1924-1928 нче елларда Бохара дәүләт киностудиясе (хәзер – «Үзбәкфильм») фильмнарында уйный. «Үлем манарасы астында» (Корбашы-атаман), «Рәвәт чүл бүреләре» (1928, Абдулнәби бай ролендә), «Икенче хатын», «Кемдә хакимият», «Махау авырулылар» фильмнарында рольләр башкара. Титрларда ул Х.Джалилов дип языла.

Х.Әбҗәлилов 1963 елның 18 мартында Казан шәһәрендә вафат була.

Артистка
Зөләйха Богданованың
туына 135 ел

Артистка Зөләйха Гыйззәтулла кызы Богданова 1886 елның 18 сентябрендә Казан губернасы Казан өязенең (хәзерге Арча районы) Әрнәшбаш авылында туа. Ул сәхнә эшчәнлеген 1910 елда Габдулла Кариев һәм Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская җитәкләгән «Сәйяр» труппасында башлап җибәрә.

Зөләйха Богданова 1912-1918 нче елларда Уфа шәһәренең «Нур» труппасында эшли. Гражданнар сугышы вакытында ул фронт театр группаларында уйный. Ә 1920 елдан ул – Уфа шәһәрендә «Үрнәк» татар театр труппасында һәм 1923-1924 нче елларда Казанда – булачак Татар дәүләт академия театрында хезмәт итә. 1924 елдан исә – Г.Кариев исемендәге Буа татар театры артисткасы, 1926-1949 нчы елларда, Буа театрына нигез салучы һәм беренче җитәкчесе Барый Тарханов Казанга киткәннән башлап, Буа колхоз-совхоз театрының сәнгать җитәкчесе һәм директоры, 1949 елда театр ябылгач, 1949-1950 нче елларда Буа районы мәдәният йортында үзешчән театр җитәкчесе булып эшли. 1926 елда аңа татар театрын үстерүдәге хезмәтләре өчен ТАССРның Хезмәт Батыры исеме бирелә.

Балалар шагыйре
Хәсән Шабановның
туына 120 ел

Балалар шагыйре Хәсән Габдрахман улы Шабанов хәзерге Пенза өлкәсенең Мәчәли авылында 1901 елда туган. Әтисе үлгәч, ул 1916 елда Әстерханга китә, пристаньдә йөк ташучы булып эшли. Гражданнар сугышында катнаша.

1932 елда Хәсән Казан педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты факультетына укырга керә. Диплом алгач, Казандагы 80 нче татар мәктәбен җитәкли. 1939-1941 нче елларда ул – Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры. Балалар өчен берничә китап авторы. Кайбер китаплары: «Күңелле балалар» (1951), «Идел акчарлаклары» (1953).

Х.Шабанов 1956 елда вафат була.

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Арчада «Җыр бәйрәме»

Клара Филиппова

Арчада «Җыр бәйрәме»

Моннан берничә ел элегрәк Казандагы радиодан шалтыратып:

– Сезне чыгыш ясарга чакырабыз, килә алсагыз, бик тә әйбәт булыр иде, – дигәч, ике арада бераз гына тынлык урнашты.

«Халкыбызны куандырырлык, аларга хуш килә алырлык нинди эш майтардым соң мин?» – дигән фикерем кылт итеп исемә төште.

Уйлаганымны радио журналистына әйткәч:

– Сез бит узган гасырның 60-70 нче елларында безнең мәдәниятебезне халыкка якынайтуда тиңнәре булмаган эш башкардыгыз, Сезне оныту мөмкин булмаган хәл бит, – диде дә, тыныч кына тыңлап торуымны үтенеп, сүзен дәвам итте: – Мин үзем Арча районында туып-үстем. Сез оештырган һәм район күләмендә ел саен үткәрелә торган «Җыр бәйрәме»ндә катнашкан мәктәп укучысы буларак, ул матур чордан күп вакыт узса да, сагынып искә алабыз. Ә без шул «Җыр бәйрәме»нә хәзерлек уңаеннан оештырылган «Күркәм эшләр эстафетасы», «Тукай һәм без», «Колхоз Г.Тукайга һәм Ильичка отчет бирә», «Җиргә тамган тир – гәүһәр» һ.б исемнәрдәге иҗади отчетлар, Арча тавындагы ике мең кешедән торган район үзешчәннәренең хор баскычлары – яшьлекнең матур хатирәләрен бүгенгедәй яңартып җибәрә, – дигәч, мин әле һаман шундый илтифатлы искә алуның җылысыннандырмы, күңелем тулып, ямансулап, җирсенеп куйдым да, уйларымны дәвам итеп, республика халкы бу турыда белми бит, минем чыгышым алар өчен бер дә күңелле һәм аңлаешлы булмастыр, дип каршы килдем.

Шушы сөйләшүгә чакырып, җанны җылытырдай, матур-матур фикерләр тагын да дәвам иткәнгәдерме, чыбыкның икенче башындагы кардәш-милләттәшемне мин, чынлап та, ишетә үк башладым.

– Сез эшләгәндә үзешчән сәнгатьтә катнашучылар, рухи, җан җылыгызны тоеп, күңел күтәренкелеге һәм чыныгу алып, зур профессиональ, үз эшенең остасы булып әверелгән шәхесләребезне республикада гына түгел, дөнья күләмендә танылганнарын да дистәләп санарга була бит. Мәсәлән, Татарстан Республикасы Г.Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясенең сәнгать һәм Татар дәүләт фольклор ансамбле җитәкчесе, профессор, җырчы, музыкант һәм янып-көеп ихластан иҗади хезмәт куючы, Арча районының Урта Бирәзә авылында туып-үскән, Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты **Айдар Фәйзрахманов**ны бик тә хөрмәт итәбез. Ә бит ул Арчаның «Җыр бәйрәме»ндә матур һәм моңлы тавышы белән якташ-милләттәшләребезне һәм республика, район җитәкчеләрен шаккатырып, танылу алды. Шушы зур шәхесебезнең булуы гына да чын йөрәктән куелган ихлас хезмәтегезнең нәтиҗәсе һәм милли-мәдәни өлкәдәге чагыштыргысыз матур күренеш дип аңлыйбыз. Сезнең «Җыр бәйрәме» шаукымында үзенең моңнары, иҗади хезмәте аша тәҗрибә алган, Татарстанның һәм Кырым татарларының иң хөрмәт иткән җырчысы, милли-мәдәниятне, телне, гореф-гадәтләребезне үстерү һәм саклауда армый-талмый хезмәт куючы күренекле шәхесебез, Татарстанның халык артисткасы **Гөлзадә Сафиуллина** үзе генә дә ни тора!

Аннары әңгәмәдәшем болай дип дәвам итте:

– Үз иҗатында тиңнәре булмаган «Сорнай» фольклор-этнографик ансамбленең алыштыргысыз җитәкчесе **Ринат Гыйләҗев** һәм **Әлфия Гыйлаҗи** егерме алты ел буена бергә күпме моңнар, күпме тарихи һәм халкыбыз оныта башлаган җәүһәрләрен безгә кире кайтарып, бүген дә яңартылган составта милләттәшләребезгә шатлык өләшәләр.

Менә, Арча районының Симетбаш авылында туып-үскән, Татарстанның халык артисты **Габделфәт Сафин** халкыбызны милли җанлы булуга өнди торган концерт программалары белән сөендереп кенә калмый, ә йөрәк түрендә яткан җылы рухи хисләребезне йокыдан уятып, күзләргә яшь китерә.

Телефон элемтәсенең теге башындагы журналист, тагын дәвам итеп:

– Аннары, узган гасырның 80-90 нчы елларында ургылып аккан чишмәдәй, «Бер тауда ун чишмә» җыры белән халык күңеленә кереп, бүген дә бик матур җырлавы белән милли моңнарыбызны халыкка ирештерүдә зур иҗади хезмәт куючы, Татарстанның халык артисткасы **Рабига Сибгатуллина** да Арча районының Иске Иябаш авылында үскәндә «Җыр бәйрәме»нең моңлы дулкыннары аша иҗади көч алган. Аның иҗатташ тормыш иптәше – Саба егете, бик күп матур җырлар авторы, танылган баянчы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе **Фәрит Хатыйпов** та арчалыларның моң чишмәсенә килеп кушылды.

Шулай ук Арча районының Урта Пошалым авылы егете, Татарстанның халык артисты **Рөстәм Закиров** та узган гасырның 90 нчы елларында республика күләмендә гран-при алуга иреште һәм бүгенге көндә татар халкының иң абруйлы җыр остасы булып танылды.

Шунысын да онытмыйк: Татарстанда танылган, Арчада гармунчылар ансамблен озак еллар җитәкләгән, үзе үк гармун ясау остасы Салих ага Вәлиевнең оныгы **Мөршидә** һәм аның тормыш иптәше, Урта Саба егете, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе **Нәҗип Бәдретдинов**ның уртак хезмәте – «Җырлыйк әле» тап-

шыруы бөтен дөньядагы милләттәшләребезгә рухи азык чыганагы булып хезмәт итә, – дип, әңгәмәдәшем сүзен тәмамлады.

Мин, озак вакыт узуга да карамастан, бик игътибар белән тыңладым.

Әйе, Арчада мин культура бүлеге мөдире булып эшләгән вакытта 1967, 1968, 1969, 1970, 1972 нче елларда уздырылган «Җыр бәйрәме» эш сөючән авыл халкының хезмәт җитештерүчәнлеген арттыруда, күңел күтәренкелегенең югары дәрәҗәдә булуына, актив яшәү рәвешенә ышанычлы юнәлеш, юллар күрсәтте. Арча тавында, ямьле Кузансу буенда уза иде әлеге бәйрәм. Ул чорның нәтиҗәсе буларак, Арча районы игенчелек һәм терлекчелектә республикада беренче урынны алуында мәдәниятнең югары булуы да роль уйнамадымы икән диясе килә. Иң әһәмиятлесе – гаилә, урам, мәктәп тәрбиясе яшьләрне һәм өлкәннәрне дә клубка туплады. Эчү, наркомания, урам сугышлары Арча ягында булды дип әйтмәс идем. Авылда яшьләр күбәйде, укуга, белемгә омтылу көчле булды. Монда яшьләребезне җырлату, күңел ачтыру гына түгел, ә авылдагы тормыш гармониясен саклау, авылны шәһәр тормышына якынайту да төп бурычларның иң кирәклесе иде.

Архивымда әлеге җыр бәйрәмнәренә бәйле берничә язма саклана. Шуларны кыскартып сезгә дә җиткерергә телим. Әлеге хорда милли җырлар белән бергә партия, «бөек юлбашчыбыз» Ленинга багышланган җырлар да яңгырады, табигый, газета хәбәрчесе дә игътибарын шуңа юнәлткән. Бу вакытта шуннан башка мөмкин дә түгел иде, укучыларыбыз аңлап кабул итәрләр дип ышанам.

Арчада сәнгать бәйрәме

[...] Составында меңнән дә артык кешене берләштергән хор Ленин һәм партия турында, Туган ил һәм совет халкы турында җырлар башкара. Кинәт җыр тынып кала, «Известия» колхозының тынлы оркестры башкаруында Советлар Союзы Гимнының мәһабәт һәм куәтле көе яңгырый. СССРның Дәүләт флагы күтәрелә, тынычлык символы булып, һавага дистәләрчә күгәрченнәр оча.

Мәдәният көне уңаеннан истәлегем. Арча районының «Искра» колхозындагы вокаль-уен кораллары ансамбле. 1972 ел

Сәхнә хезмәтен үтәүче мәйданчык өстенә Куйбышев исемендәге колхозның җыр һәм бию ансамбле күтәрелә. Ул үзенә 53 һәвәскәр җырчыны, биючене һәм музыкантларны берләштерә. Ансамбль музыкаль инструментлар һәм киемнәр белән бик мул тәэмин ителгән. Механизаторлар, терлекчеләр белән янәшә басып, хор составында колхоз председателе Фәйзерахманов үзе дә җырлый.

Бәйрәм дәвам итә, репродукторлар аша концертны алып баручы, Арча Культура йорты директоры Нургаян Имаметдиновның тантаналы тавышы яңгырый: «Варшавянка»!

Берләштерелгән хор революцион җырлар башкара. «Тукай-Кырлай урта мәктәбе укучысы Рәшит Сибгатуллин башкаруында «Көзге ачы җилләрдә» җыры яңгырый. Аны «Ракета» колхозы савымчысы Кафия Шәңгәрәева алыштыра. Ул РСФСРның

атказанган мәдәният хезмәткәре, һәвәскәр композитор, Кенәр культура йорты директоры Салих Хисмәтуллин тарафыннан иҗат ителгән җырларны башкара. Аннан соң сәхнәгә Габдрахмановлар семьясы («Октябрь» колхозы) күтәрелә. Рушания апа кызы Гүзәл белән татар халык җыры «Туган тел»не башкаралар. Аларга Әдһәм ага һәм аның улы Камил – баянда, ә кызлары Гөлнур мандолинада аккомпанировать итәләр.

Биюдән соң нәфис сүз, җыр, акробатик чыгышлар, тагын җыр, тагын бию... Өч сәгатькә сузылган зур концерт барышында нинди генә җырлар, биюләр булмады. Ә концерт, чынлап та, зур иде, анда 21 колхоздан һәм 4 совхоздан, 3 культура йортыннан һәм мәктәпләрдән килгән үзешчән сәнгать коллективлары – барлыгы мең ярымлап кеше катнашты. Ул чын мәгънәсендә сәнгать бәйрәме булды һәм Арчада сәнгать сөюче, талантлы халык яшәгәнлеген күрсәтте. [...]

Татарстан яшьләре. – 1967 ел. – 13 июнь.

Җыр бәйрәме

[...] ...Казанка буендагы ямь-яшел болында да музыка һәм җыр яңгырый бүген. Биредә районыбызның һәвәскәр артистлары – үзешчән сәнгать коллективлары чыгыш ясаячак. Хор өчен әзерләнгән урын матур итеп бизәлгән. Әнә, союздаш республикаларның герблары, дәүләт флаглары, даһи Ленинның мәһабәт портреты. Гүя, ул бәйрәмгә ашыгучыларны сәламләп каршы ала. Бәйрәм эмблемасы. Зур хәрефләр белән «СССР-50» дип язылган сүзләр. Әйе, бүгенге бәйрәм СССР төзелүгә 50 ел тулуга әзерлек барган көннәрдә үткәрелә һәм шушы тарихи датага багышлана.

Күпсанлы тамашачыларның карашы хорга төбәлгән. Ике меңгә якын кешене берләштергән хорда колхоз, совхоз, предприятие һәм педагогия училищесы коллективлары.

[...] Хезмәт ияләре депутатлары район Советы башкарма комитеты председателе Т.Б.Борһанов кереш сүз белән бәйрәмне ачып җибәрә. [...] Бәйрәм байрагы күтәрелә. Аны Социалстик Хезмәт Герое, «Ватан» совхозы дуңгыз караучысы Дания Галимова, СССР Верховный Советы депутаты, «Известия» колхозының кукуруз игү буенча механикалаштырылган звено җитәкчесе Равил Мәрданов, Арча икенче урта мәктәбе укытучысы Фатыйма Нуретдинова иптәшләр күтәрәләр.

Микрофон алдында – бәйрәмне алып баручылар. Хор «Гасырлар кешесе Ленинга», «Нинди иркен минем туган илем» җырларын башкара. Тамашачылар арасында зур җанлану. Чөнки хор алдына союздаш республика халыкларының милли киемдәге һәвәскәр артистлары чыгып баса. Алар Тельман исемендәге колхоз үзешчән сәнгать коллективы членнары һәм бәйрәмдә катнашучыларны һәр союздаш республика телендә сәламлиләр. Хор «Дуслык турында җыр», «Туган җирем Татарстан» җырларын башкара. [...]

Ренат Таҗиев.
Коммунизмга. – 1972 ел. – №69. – 6 июнь.

***

Нәтиҗә ясап, узган гасырның 60-70 нче елларында Арча төбәгеннән чыгып дөньяви танылу алган милли шәхесләр республикабызның данын күтәрәләр, бүген дә халкыбызны куандырып, тормыштан ямь табып иҗат итәләр һәм, олыгаеп барсалар да, матурлык тудырып, шунда кайнап яшиләр дип әйтәсем килә.

Хәтер яңартканы өчен радио хезмәткәрләренә бик тә рәхмәтлемен. Узган эшкә салават әйтеп, иҗатка юл тотыйк, күңел ачкычын табарга омтылып яшик. ■

ТАТАР ҖЫРЧЫЛАРЫ.
КАДЕРЛЕ МИЗГЕЛЛӘР

Исән чагында ук легенда дип атадылар Татарстанның халык артисты Хәмдүнә Тимергалиеваны. Ягъни язмышы каһарманлыкка тиң вакыйгалар белән ныгытылып, шулар аша онытылмас, үрнәк шәхескә әверелгән кеше!

Нинди соң алар тыныч заманның каһарманнары? Шәп җырчылар, музыкантлар, артистлар, әдипләр күп, халык яратып кушкан ул исемгә исә сирәкләр генә лаек була.

Минем Хәмдүнә апа белән күп тапкырлар сөйләшеп утырганым, аның хакында мәкаләләр язганым булды. Кыю иде ул, кискен сүзгә дә шактый һәвәс иде. Әлеге әңгәмәләр вакытында нинди генә җүнсез чиновникларны кәнәфиләре-ниләре белән бергә «себереп түкмәдек» без. Ләкин мәкалә чыкканчы ул шактый кешеләргә, ихлас күңеле белән: «Журналистка интервью бирдем, фәлән дидем, төгән дидем», – дип сөйләп куя, акыллылары аңа система һәм аңа каршы сөйләгән кешеләр үтә торган авырлыклар турында кисәтеп, мәкаләләрне чыгармаска киңәш бирәләр иде. Дөресрәге, аның кискен сүзләрен үзем дә язмый идем. Нигә ул, аннан ни үзгәрә? Журналист «вәт артистны шәп ачкан» дигән мактау ала, респондент алга таба кимсетелүгә юлыга. Бары шул!

Хәмдүнә апа беренче тапкыр телевизордан күренгәндә мин үсмер генә идем әле. Җәй иде, мин авылда каникулда, аклы-каралы телевизор эшләп тора. Шул ике каналлы телевизорда нечкә буйлы җырчы кыз сиптерә генә бер тиз көйне. Ул чакта телевизорда җитез, такмакка охшаш җырлар бик яңгырамый да иде әле. Мин, никтер, туктый алмый көлә башладым. Мин сүзләрен дә ишетеп өлгерә алмаган ул җырны кемдер җырлап та өлгерүен күр әле! Соңыннан берничә әңгәмәсендә Хәмдүнә апаның: «Мине такмакчы дип шактый мыскыл иттеләр инде», – дигәне булды. Әйткәннәрдер. Озын, моңлы көйләр белән аның тиз җырлары арасында шактый җете аерма бар иде.

Илһам абый Шакировның Хәмдүнә апаны җырчы буларак ничек югары бәяләве хакында билгеле. Илһам абыйга барлык җырчыларның, әлбәттә, Хәмдүнә апаның да, җыр атасы итеп караулары да мәгълүм. Бу фотоларга күз саласың да, күңелгә ниндидер тынычлык, татар җырының саклаучы, яклаучылары бар, ул югары кимәлдә дигән ышаныч иңә. Гәрчә икесе дә бакыйлыкта булсалар да. Җырлары мәңгелек шул.

Татар дәүләт филармониясендә эшләү чорында бүген сәхнәдә булган һәм инде ветеран җырчылар белән күпме кызыклы проектлар ясадым. Шуларның берсе «Минем Филармониям» иде. Язмышларына әверелгән Филармония турында күпме матур сүзләр сөйләделәр ул чакта артистлар. Бу фото шул проектны язу вакытында төшереп алынган. Хәмдүнә апа ул көнне алкасын тагарга онытып килгән иде. Бик борчылды. Шуннан соң Филармония музееның мөдире Алсу аңа үз алкасын салып бирде...

Карап торышка өен туктаусыз җыеп, юып торучыга охшамаган иде Хәмдүнә апа. Бер тапкыр өенә әңгәмә корырга баргач, андагы операция ясый торган бүлмәдәгедәй чисталыкны күреп шаккаттым. Купшылык, артык байлык, алтын йөгертелгән кашыклар юк. Ләкин бары да ялт иткән, тузанның бөртеген дә күрмәссең. Бакчасын да шулай караган ул. Агачтан өзелеп төшкән көзге яфракларга кадәр җыеп торган. Шул бакчасында бакыйлыкка да күчте. Капыл, көтелмәгәндә... Дөрес, бер генә үлем дә көтелгән түгел. Бер генә югалту да ярасыз булмый.

Тормыш бара, кемдер килә, кемдер китә. Килгәннәр яңа язмыш яза, киткәннәрдән исә зур мәгънә кала...

Журналга
Зимфира Гыйльметдинова
әзерләде.

Җуелмас хәзинә

«Көзге ачы җилләрдә» җыры

«Халык җырлары безнең киләчәктә мәйданга киләчәк әдәбиятымызга, бер дә шөбһәсез, нигез булачактыр».

Габдулла Тукай

Көзге ачы җилләрдә

(Татар халык җыры,
И.Шәмсетдинов эшкәртүендә)

Бардым күлгә, салдым кармак,
Безгә балык эләкми шул.
Йөгереп китәрдәй булам ла,
Кайтып җитәрдәй булам
Көзге ачы җилләрдә ләй,
Туган-үскән илләргә.

Бетсен патша, янсын тәхет,
Безгә сугыш кирәкми шул.
Йөгереп китәрдәй булам ла,
Кайтып җитәрдәй булам
Көзге ачы җилләрдә ләй,
Туган-үскән илләргә.

Без утырган машинаның
Тоткалары җиз генә шул.
Йөгереп китәрдәй булам ла,
Кайтып җитәрдәй булам
Көзге ачы җилләрдә ләй,
Туган-үскән илләргә.

Бер илләрдән чыгып киткәч,
Кайтып булмый тиз генә шул.
Йөгереп китәрдәй булам ла,
Кайтып җитәрдәй булам
Көзге ачы җилләрдә ләй,
Туган-үскән илләргә.

Җырчы, ТАССРның халык артисты Рәшит Ваһапов (1908-1962)

Фольклорчы галим **Илбарис Надиров** «Татар халык җырлары» китабында «Көзге ачы җилләрдә»не Беренче бөтендөнья сугышы чорында солдатлар чыгарган җыр дип билгеле. *«Әмма революция елларында халык аны үзгәртеп, яңа заманга яраклы яңгыраш бирә»,* – ди.

Композитор **Александр Ключарев** бу җырны «Татар халык көйләре җыентыгы»на (1941) «Окоп көе» исеме белән кертеп, көйнең Рус-япон сугышы чорында ук мәгълүм булганлыгын әйтә. Күп кенә музыка белгечләре, композиторлар да җырны Беренче бөтендөнья сугышы елларында чыккан дигән фикердә.

Композитор *Җәүдәт Фәйзи* «Халык җәүһәрләре» китабында (1987) бу җырның тарихына киңрәк туктала. Ул да иҗат ителү чоры итеп Беренче бөтендөнья сугышы чорын атый. *«Ләкин көй үзенең яңа сүзләре һәм интонацион бизәкләре белән Гражданнар сугышы елларында гына тулы яңгыраш алды»,* – ди. Җырны Гражданнар сугышы чоры җырларының классик үрнәге дип атый.

Язучы **Гомәр Бәширов** та бу җыр турында истәлекләрендә болай дип искә ала: *«Көзге ачы җилләрдә» дигән җырны без, яшь сугышчылар, 1920 елның җәендә Врангельгә каршы сугышка чыгып китәр алдыннан бөтен рота һәм батальоныбыз белән Казан урамнарында җырлап йөрдек. Без аны Октябрь революциясе алдыннан солдатлар чыгарган җыр булырга тиеш дип йөри идек. Хәзер халык бу җырны, яңа бер яңгыраш биреп, бик хаклы рәвештә революцион җырларның берсе итеп җырлый».*

Әлеге җыр Рәшит Ваһапов, Илһам Шакиров, Айдар Галимов (ул башкарган җырның кайбер юллары башкача) репертуарында бар.

Тәртип радиосы

(Сәхифә «Тәртип» радиосында яңгыраган «Саф вә раушан көзге» тапшыруы материаллары нигезендә әзерләнде. Тапшыруның авторы һәм алып баручысы – Гөлфия Мөхәммәтгәрәева.) ■

Көлке куа килә...

Фатих Әмирхан (1986-1926)

Фатих Әмирхан
Зөлфәт Хәйруллин шаржы

Мирзалар авыруы

Гайнетдин Гайнетдинович Сәкыймов, Мәскәүдән съездан кайтып җитеп, йокы урынына яткач та, авыр бер уйланышка бирелде:

– Һә, так. Тәки теге шовинистлар җиңделәр бит. Имеш, татар-башкорт эшче-крестьяннарына үз җөмһүриятләре кирәк. Имеш тә, башкаларныкы шикелле үк аның да җөмһүрияткә хакы бар. Имеш тә, татар-башкорт эшчеләре бөтен эшләрен үз кулларына алырга хаклылар! Черт возьми, иртәгә шул турыда Губкомга доклад ясарга кирәк. Лев Абрамович ни әйтә инде, моны ишеткәч? Иван Иванович ни әйтә? Ә Мария Иосифовна? Ул бөтенләй иронически көлеп җибәрә инде. «Сез соң нинди көч белән җөмһүрият алып бармакчы буласыз?» – ди инде ул, билгеле. Позор! Бөтен Губком алдында көлке. «Сез нинди шовинистлар соң?» – диләр инде. Әле бу көн бюрога әгъзалар кабул итү правасы бирелсен иде, дип просить иткәч тә, Матвей Иваныч, көлеп җибәреп: «Сез һаман иске националистлыгыгызны онытмыйсыз!» – дигән иде.

Гайнетдин Гайнетдиновичның уйлары бер-берсеннән авыр, бер-берсеннән кәефсез иде. Ул үзенең һәм бөтен татар коммунистларының Губком алдында нинди уңайсыз хәлдә калачакларын күзе белән күргән кебек күреп тора, Адам Петровичның: «Сез коммунистлар түгел, сез шовинистлар, больше ничего!» – диячәген колагы белән ишеткән шикелле ишетеп тора иде. Сәкыймов озак йоклый алмады, берничә мәртәбәләр үз-үзенә генә: «Позор, позор! – диенде. – Тфү!» – диде, төкеренде, төн уртасында гына йоклап китте. Ләкин тыныч йоклый алмады: әллә нинди шәүләләр аны мыскыл итеп көләләр, әллә нинди шүрәлеләр аңар яныйлар, әллә нинди өрәкләр аңар: «Ах, гололобый татарин!» – дип, бармак селкиләр иде. Бераздан бу тынычсызлык бөтен бер рәвешкә, куркыныч бастырылуларга әйләнде. Гүяки бик күп кешеләр моның өстенә җикеренеп килгәннәр, имеш, алар моны бик тиргиләр, бик ачуланалар, имеш, алар арасыннан Лев Абрамыч белән Иван Ивановичның тиргәүләре бигрәк аермачык ишетелә, имеш:

– Без сине соң Мәскәүгә Татар-башкорт җөмһүрияте алып кайтырга җибәрдекмени?! Ах, контрреволюционер, ах, шовинист, ах, оятсыз! – диләр, имеш.

Сәкыймов Иван Ивановичка җавап бирә, имеш:

– Товарищ барин, ә, товарищ барин, ей-богу, мин гаепле түгел, мин әйтәм, мин барысын да әйтәм: татар эшче-крестьяннары үз җөмһүриятләрен теләмиләр,

дидем. Татар ярлы халкы үз җирендә һәрбер учреждениеләрдә татарча да сөйләшүне бер дә теләмиләр, без русча белмәсәк тә, безнең белән русча гына сөйләшсәләр иде, дип требовать итәләр иде, дидем. Татар эшчесе властьның үз кулына күчүеннән бик курка, мин баринсыз тора алмыйм, дип әйтә, дидем. Татар эшче-крестьяны кулыннан чүп тә килми, ул бариннан башка харап булачак, дидем. Ей-богу, товарищ барин, мин верноподданный! Мин... 1918 ел маеннан халык комиссарлары тарафыннан җыелган Татар-башкорт җөмһүрияте комиссиясен татарлардан безнең иптәш берүзе демонстративно ташлап чыгып киткән иде...

Сәкыймовның бастырылуы озак сузылды. Йокысыннан уянгач та, ул саташудан айный алмады. Аңар доктор чакырдылар. Доктор карт коммунист икән. Сәкыймовның авыруын тиз таныды:

– Бу авыруны лакейлар тифы дип атыйлар, әүвәл заманда бу авыру белән татар мирзалары гына авырый иде; хәзер простой халык арасына да кергән икән. Шул кадәресе бар: әүвәл заманда мондый авыру белән авырган мирзалар «ваше превосходительство» дип саташалар иде, хәзерге заман халкы «товарищ барин» дип саташа икән. Авыруны татар һәм башкорт ярлылары һавасында озак йөртергә кирәк, – диде.

Авыру һаман саташа иде: «Товарищ барин, барин товарищ, зделай милость...»

Шәүкәт Галиев (1928-2011)

Илдар Юзеевка

Авторның «Яшь наратлар» исемле яңа китабы чыкты, анда укучылар җылы каршылаган «Язылмаган поэма» да бар.

Кем генә поэма язмый,
Төшенәлми җаена...
Ә сиңа уңыш китерде
«Язылмаган поэма»!

Илдар Юзеев
Хәбир Әхмәтҗанов шаржы

Мөхәммәт Мәһдиев (1929-1995)

Балалар турында мәзәкләр

Дурак түгел...

Татар әдәбияты дәресе бара. Керәшен авылы, керәшен балалары. Өйгә эш бирелгән: Тукайның «Китмибез!» шигырен ятлап килергә. Җәгүр (Егор) исемле малай борынын тарта-тарта түшәмгә караштыргалап сөйли:

– Китмибез без, анда китәргә без дуракмыни...

Әни сүзенең урысчасы

Өченче класста рус теле дәресе. Укытучы Наиләдән сорый:

– Әти сүзен русча әйт!

– Отец.

– Яхшы. Хәзер әни сүзен әйт.

Наилә бераз уйлап тора һәм шатланып әйтеп куя:

– Анец.

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Без барыбыз да – балачактан

«Балачак мирасы» сәхифәсе – иң әүвәл сезнең өчен, өлкәннәр. Халкыбызның күңел җәүһәрләрен – такмак-такмазаларны, табышмак-башваткычларны, әкиятләрне, әдипләребезнең хикмәтле һәм гыйбрәтле, мәгънәви һәм тәрбияви әсәрләрен хәтерегезгә сеңдерегез, аларны озын-озакка сузмыйча, балаларыгызга һәм оныкларыгызга җиткерегез, нәниләргә бишек җырларын көйләргә дә онытмагыз. Кыскасы, укыгыз, уйланыгыз һәм бер нәтиҗә ясагыз да... һәрвакыт безнең «Балачак мирасы» белән бергә булыгыз!

Габдулла Тукай (1986-1913)

Ташбака илә куян

(Хикмәтле хикәят)

Ташбака илә куян, узышмакчы булып, бер тауга таба йөгерешә башладылар.
Куян, үзенең зирәклегенә ышанып, юлда ятып йоклады.
Куян берзаман йокысыннан уянып караса, ташбака әллә кайчан тауга барып җиткән!
Инде безнең куян артта калганына үкенде дә, хурланды да, әмма ни файда?!.

Шамил Маннапов (1938-2012)

Ат ник көлә?



Авылга әбиләренә
Кунакка кайткан Ирек.
«Привет, конь!» – дип исәнләшкән,
Җирән кашканы күреп.

Җирән кашка, башын чайкап:
«Миха-ха-хай!» – дип көлгән.
«Зачем көля ул?» – дип, Ирек
Сораган әбиеннән.

Әбисе хәйләкәр генә
Елмаеп болай дигән:
«Үз телен оныткан, диеп
Көләдер, бәбкәм, синнән...»

Өч кыз
(Татар халык әкияте)

Борын-борын заманда булган, ди, бер хатын. Аның булган, ди, өч кызы. Бу хатын, кызларымның өсте-башы бөтен булсын, дия-дия, көне-төне эшләгән, ди.

Менә кызлар буйга җиткән, ди. Алар берсеннән-берсе матур, ди, бер битләре ай, икенчесе кояш, ди, буй-сыннары карлыгачтай сылу, ди. Өч кыз туган бер-бер артлы кияүгә чыгып, берсе артыннан берсе китеп барган, ди.

Менә бер ел үткән, ике ел үткән, өч ел үткән. Шулай матур гына яшәп ятканда, әниләре авырып киткән. Күрше урманда тиен-дус бар икән, шуны дәшеп әйткән, ди, ул:

– Тиен-дустым, барсана, кызларыма әйтсәнә, хәлемне белергә килсеннәрче, – дигән.

Тиен шундук чыгып чапкан. Ул барып тәрәзә какканда, олы кызы җиз ләгән тазартып торадыр иде, ди.

– Һай, – дип әйткән, ди, олы кыз, – бик барыр идем дә бит, аңарчы менә шушы ләгәннәрне тазартып, чистартып бетерәсе бар иде шул, – дигән.

Тиен моңа бик ачуланган да әйткән:

– Алайса син шушы ләгәннәреңнән мәңгегә аерылма! – дигән.

Тиеннең шулай дип әйтүе булган, ике ләгән кызны ике яктан китереп тә кыскан. Олы кыз егылган да шундук ташбакага әверелгән.

Тиен уртанчы кыз янына киткән. Уртанчы кыз, бу кайгылы хәбәрне ишеткәндә, киндер суга икән. Тиенгә әйткән:

– Һай, – дигән, – әнием янына хәзер үк чыгып йөгерер идем дә бит, менә ярминкәгә киндер сугып өлгертәсем бар иде шул, – дигән.

Тиен бик яман ачуланган да әйткән моңа:

– Алайса син гомерең буе киндер сугып кына тор! – дигән.

Уртанчы кыз шундук үрмәкүчкә әверелгән.

Тиен тәрәзәсен какканда, кече кызның камыр баскан чагы икән. Ул бер сүз әйтмәгән, камырлы кулларын да сөртеп тормыйча, әнисе янына йөгергән.

Тиен кече кызга әйткән:

– И сөекле бала! – дигән. – Гомер буе игелек күр, кешеләрне бәхетле ит, аларга куаныч та, юаныч та бул. Кешеләр дә сине сөярләр, синең яхшылыгыңны мәңге онытмаслар, – дигән.

Кече кыз, чыннан да, бик рәхәт гомер кичергән, халык та аны бик яраткан, ди.

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

АВГУСТ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында



● Августта Актаныш районының каләм тибрәтүчеләре – укучылар һәм укытучыларның сайланма әсәрләре тупланган «Илһам иле – Актанышым» дигән китап дөнья күрде. Китапның төзүчесе – Илфак Ибраһимов.

● 3 августта Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (1991), Татарстан Республикасының халык рәссамы (1997), Габдулла Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты (2000) Шамил Мортаза улы Шәйдуллин (1947 елның 1 августында Тәтеш районының Берлек авылында туган) вафат булды.

● 11-14 августта «Мәдәни җомга» газетасы, «Безнең мирас» һәм «Казан утлары» журналларының баш редакторлары – В.Имамов, Л.Лерон, Р.Галиуллин, журналыбыз хезмәткәре Л.Гобәйдуллин Башкортстанның Чакмагыш, Бүздәк, Чишмә, Кырмыскалы, Авыргазы һәм Эстәрлебаш районнарында, аерым алганда, шул районнарга караган Яңа Мортаза, Килем, Карлыман, Шәйморат, Бозаяз, Солтанморат, Турмай авылларында булып кайтты.

● 16 августта икътисад фәннәре докторы (2002), ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1992), Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, агроном, язучы, шагыйрь һәм атаклы бакчачы Фарсель Зыятдинов (1937 елның 1 июнендә Актаныш районының Качкын авылында туган) вафат булды һәм Биектау районындагы Мөселман зиратында җирләнде.

● 19 августта «Безнең мирас» хезмәткәрләре Ләбиб Лерон һәм Ленар Гобәйдуллин Сарман районында, аерым алганда, район үзәгендәге «Бәрәкәт» һәм Җәмигъ мәчетләрендә, районның Төбәк тарихын өйрәнү музеенда, кормашчы-җәлилче Зиннәт Хәсәновның (1915-1944) туган авылы Иске Кәшердә (язучы Рафис Гыйззәтуллин (1955-2011) шушы авыл мәктәбен тәмамлаган) һәм Мортыштамак авылы (әдибә Мәдинә Маликова шушы авыл тумасы) музейларында, шулай ук Сарманда яшәп иҗат итүче прозаик һәм шагыйрь Дамир Гарифуллинда, «Электроника» кибете хуҗасы, эшкуар Рәүф Фатыйховта кунакта булды. Шул ук көнне кичен «Безнең мирас» журналистлары Мөслимгә барып, шунда яшәп иҗат итүче әдипләр – Фоат

Садриев һәм Мөҗәһит Әхмәтҗанов белән очрашты.

● 20 августта Актаныште күптелле «Адымнар» мәктәбе ачылды. Тантаналы чарада ТР Президенты Р.Миңнеханов, ТРның Дәүләт Киңәшчесе М.Шаймиев, Рособрнадзор җитәкчесе А.Музаев, район хакимиятләре башлыклары һәм депутатлар, шулай ук «Мәдәни җомга» газетасы, «Безнең мирас» һәм «Мәгариф» журналларының баш мөхәррирләре – В.Имамов, Л.Лерон, С.Таишева катнашты.

● 20 августта Башкортстанның Мишкә районы үзәгендә рейхстагка беренче булып байрак кадаган Гази Заһитовка (1921-1953) һәйкәл ачу тантанасы булды.

● 21 августта Арча районының Сикертән авылында атаклы драматург Галиәсгар Камал музее ачылды.

● 21 августта Татарстанның халык артисты Рәшит Мирза улы Шамкаев (1940 елның 26 маенда Самара өлкәсендәге Камышлы районының Иске Ярмәк авылында туган) вафат булды. Мәрхүмнең җәсәде мәрхүмә хатынының туган ягында – Арча районының Түбән Оры авылы зиратында җирләнде.

● 25 августта Кукмара районының Мәчкәрә авылында дүртенче тапкыр «Мәчкәрә укулары» төбәкара фәнни-гамәли конференциясе үтте. Быел ул «Шәҗәрә – милләт тамыры» дигән темага багышланган иде.

● 25 августта Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, С.Сөләйманова һәм Р.Төхвәтуллин исемендәге әдәби премияләр лауреаты, шагыйрь һәм прозаик Нур Гариф улы Әхмәдиев вафат булды. Мәрхүмнең җәсәде туган ягында – Азнакай районының Әсәй авылы зиратында җирләнде.



● 29 августта Буа районының Адав-Толымбай авылында ишан Әхмәр бине Юныс әл-Толымбайга нисбәтле (1763-1819) укулар булып узды. ■

МИРАСВОРД

Газинур Моратның 1998 елда чыккан шигырьләр, поэмалар китабы

Хәлил ... (СССРның халык артисты)

Борынгы грек шагыйре

Габдрахман Минскийның 1995 елда чыккан повесть, хикәяләр китабы

Поляк (иск.)

Монгол кылычы

Гурий Тавлин трилогиясе

... сакчысы

IV гасырда Азиядә яшәгән күчмә төрки кабиләләр

Мишәр абзые

Кардәшлек, уртак тел, йолалар белән бәйләнгән кешеләр төркеме

Иртән ...

Мәҗүсиләрдә дин башлыгы

Имән һ.б. агачларның кайрысыннан алына торган матдә

Әрем тәме

Хельсинкида яши

Шагыйрь Мөхәммәт...

Шәһәр тирәли казып ясалган ныгытма, траншея (иск.)

Себер шаманы

Хат, записка (иск.)

Борынгы грекларда тынлы уен коралы

Фаяз ... (татар шагыйре, публицист, драматург)

Гаяз Исхакый хикәясе

Шагыйрь ... Шәех

Италиядә X гасырдан башлап сугылган алтын һәм көмеш тәңкә

Чыңгыз ханның законнар җыелмасы

... Браун

Шагыйрь Харрас ...

Байлык, ризык, мал (иск.)

Кайбер хайваннарның муеныңдагы озын куе йон

Федерико Гарсиа ...

Габдрахман Минскийның чын фамилиясе

Германиядә – Одер, Чехия һәм Польшада – ...

Атлы хәбәрче

Гарәп иле

Су ташкыны ерып үткән урын

«Гаеп ... да, тартадә дә»

Гарәп хәрефе

Винсент ... Гог

... Акопян

8 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:
Сулдан уңга: Зифа, ар, балбал, Мане, чуман, ирәбә, литота, кибар, вирд, силә, Хисам, Мор, өн, сил, вәхи, чал, нәсихәт, шава, һомай, ятим, Кара, «Рәшә», нык, тити.
Өстән аска: Хөснияр, «Аникин», тәй, иш, Зәбәерова, чикмән, тимсах, фал, чуар, илә, арбау, Ким, һади, Колбарисов, шор, Нәбирә, амани, бал, «Вакыт», мәрә, Имай.

Рәис Габдулла төзеде.■

«Безнең мирас»

елъязмасы / сентябрь

Уфадагы «Галия» мәдрәсәсе. ***(Фото zadocs.ru сайтыннан алынды.)***

545 ел элек (1476)

Олы Урда ханы Әхмәтханнан, Мәскәү кенәзе Иван IIIне Сарайга чакырып, хат килә. Ул заманда Мәскәү кенәзләре, Сарайга килеп, үз кенәзлекләрендә идарә итү хокукына ия булу өчен Бөек Ханнан рөхсәт ярлыгы ала торган булганнар.

145 ел элек (1876)

13 сентябрьдә Казанда Татар укытучылар мәктәбе (хәзерге вакытта – Казан педагогия көллияте) ачыла.

115 ел элек (1906)

Уфада «Галия» мәдрәсәсе эшли башлый.

110 ел элек (1911)

Август-сентябрь аенда Баку шәһәрендә «Яңа иршад» дип аталган атналык газета чыга башлый.

95 ел элек (1926)

25 сентябрьдә Казанда яшь язучы Фәхри Әсгать (1901-1926) вафат була.

70 ел элек (1951)

«Совет әдәбияты» журналының сентябрь ае саныннан Габдрахман Әпсәләмовның «Газинур» романы басыла башлый.

65 ел элек (1956)

28 сентябрьдә башкалабыз Казанда Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрының хәзерге бинасы ачыла.

Журналга ***Марат Закир*** *әзерләде.* ■

Содержание. Сентябрь 2021

И останется в мире слово моё...: Ильдар Юзеев.

Историческое наследие: «Родословная Джучи хана»; «Он очень надежный человек...». Г.Ханнанова; «Исламское общество Нарвы». И.Мифтахов; «Страшный голод». Н.Гариф; «История нашей родословной». А.Маликов.

Татарский мир: «Искал я желтые подснежники». М.Валиев; «Хакимов». И.Тагиров.

Религиозное наследие: «Исламский мир». Габдурашит Ибрагимов; «Уроки религии». С.Бикбулат.

В глубинах памяти: «Род». Л.Закиров; «В памяти, до сих пор в памяти!».

Художественное наследие: «Татарские певцы. Дорогие мгновения». З.Гильмутдинова.

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

Алхәбәр:

Атаклы курайчы һәм композитор Ифрат Хисамовның (1930-2000) әтисе Нигъмәт Габдулла улы Хисамов (1904-1988).
(«Кадерле фотоистәлекләр – язучы Дамир Гарифуллин архивыннан»)

- **Алтын Урда тамгалары.** **Дамир Гайнетдинов**
- **Татар корычы: тарих һәм технология.** **Ясуюки Мураками**
- **XIX гасыр хәлегъ документы.** **Назыйм Мәхмүтов**
- **Күлбаш муллалары.** **Ләлә Мортазина**
- **Шәкүрә Юзеева (шагыйрь И.Юзеев һәм әдәбият галиме Н.Юзеевның әнисе)** **көндәлекләре**
- **Аркаимга сәяхәт.** **Лирон Хәмидуллин**
- **Кыр Бикшик авылының (Чуашстан) Татарстанга бәйләнеше.** **Нәкыйп Каштанов**
- **Кадерле фотоистәлекләр** **– язучы Дамир Гарифуллин архивыннан**

Әдип Илдар Юзеев — фотоларда

И.Юзеев Ямадыда якташлары белән

Авылдаш егетләр белән

И.Юзеевның 50 яшьлек гомер бәйрәменнән соң

Якташлары белән очрашу

И.Юзеев туган ягында

Фотолар Башкортстан Республикасының Яңавыл районындагы Ямады авылында урнашкан Илдар Юзеев музее фондыннан алынды.

ИТИЛ СУЫ АКА ТОРУР,
КЫЯ ТӨБЕН КАКА ТОРУР.
БАЛЫК ТӘЛИМ БАКА ТОРУР,
КҮЛЕҢ ТӘКЫЙ КҮШӘРЕР.

Борынгы халык җырыннан

Фотолар Абдулла Дубин коллекциясеннән алынды.

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – П2343
РОССИЯДӘ – П7074
beznenmiras.ru

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
журналына башкача язылу:

- *uslugi.tatarstan.ru* сайты ярдәмендә
- редакциядә
- *podpiska.pochta.ru* сайты ярдәмендә

4 612750 670172

«БЕЗНЕҢ МИРАС» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» кибетеннән (Бауман ур., 19 һәм 51), «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.